Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

# Хатын-кызлар фикхы

Икенче басма

Түбән Кама 2010

## Кереш сүз

إِنَّ الْحَمْدَ لِلهِ نَحْمَدُهُ وَ نَسْتَعِينُهُ وَ نَسْتَغْفِرُهُ وَ نَعُوذُ بِاللهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا وَ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللهُ فَلا مُضِلَّ لَهُ وَ مَنْ يُضْلِلْ فَلا هَادِيَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنْ لا إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لا شَرِيكَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّداً عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ، أَمَّا بَعْد...

Хакыйкатьтә, иң хәерле сүз — Аллаһ тәгаләнең сүзе, вә иң хәерле юл — пәйгамбәребезнең ﷺ юлы. Барча яңалык — бидгать, вә барча бидгать — адашу һәм барча адашу утка илтә.

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ حَقَّ تُقَاتِهِ وَلا تَمُوتُنَّ إِلا وَأَنْتُمْ مُسْلِمُونَ) آل عمران

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Аллаһка хак тәкъвалык белән тәкъваланыгыз. Аңа итагать итегез, каршылык вә гөнаһ кылмагыз. Аны зикер кылыгыз, вә онытмагыз. Аңа шөкер итегез һәм көферлек кылмагыз, Аның хөкемнәрен бозудан бик нык сакланыгыз һәм Коръән белән гамәл кылып, чын мөселман хәлегездә генә үлегез!».**

(يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُمْ مِنْ نَفْسٍ وَاحِدَةٍ وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالا كَثِيرًا وَنِسَاءً وَاتَّقُوا اللَّهَ الَّذِي تَسَاءَلُونَ بِهِ وَالأَرْحَامَ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلَيْكُمْ رَقِيبًا) النساء: ١

Мәгънәсе: **«Әй кешеләр! Сезне бер нәфестән (Адәмнән) халык кылучы Аллаһка тәкъва булыгыз! Ул (Аллаһ), Адәмнең عليه السلام үзеннән хатын (Хәваны) яратты, вә икесеннән күп ирләрне һәм күп хатыннарны дөньяга чәчте. Янә Аллаһка тәкъвалык кылыгыз, Ул — Аллаһ исеме белән бер-берегездән сорыйсыз, ягъни Аллаһ ризалыгы өчен бир, сүземне тыңла, дисез, һәм Аллаһ ризалыгы өчен сорагач кешенең кире какмаганлыгын беләсез. Шулай**

**булгач, Аллаhны зурлагыз вә якын туганлык җепләрен өзүдән сакланыгыз! Аллаh бит сезнең барча эшләрегезне тикшереп күзәтүче».**

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَقُولُوا قَوْلًا سَدِيدًا ! يُصْلِحْ لَكُمْ أَعْمَالَكُمْ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ وَمَنْ يُطِعِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ فَقَدْ فَازَ فَوْزًا عَظِيمًا) الأحزاب: ٧٠-٧١

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Аллаhка тәкъва булыгыз, вә хак булган файдалы, дөрес сүзләрне генә сөйләгез! Аллаh әйткәнчә эш кылсагыз, Аллаh эшләрегезне вә гамәлләрегезне төзәтер, вә гөнаhларыгызны ярлыкар. Берәү чын күңелдән Аллаhка, вә Аның расүленә итагать итсә, ул кеше hичшиксез өстенлеккә вә изге теләгенә иреште».**

Аллаh тәгаләнең рәхмәте илә, хатын-кызлар өчен булган бу кыска гына китапны динебезне, өммәтебезне вә милләтебезне күтәрүгә бер сәбәп булсын дип әзерләдем. Чөнки күп кенә хатын-кызлар үзләренә кагылышлы гади генә хөкемнәрне белеп бетермиләр. Бу хөкемнәрне белмәүләре динебезгә битарафлыктан, яки гыйлемнең кешегә барып җитмәгәнлегеннән килә. Исламда «гыйлем» дип искә алына икән, ул — шәргый гыйлемне күздә тота. Күп кенә мөселманнарга гыйлем алырга кирәк дигәч, алар: «Мин югары уку йорты бетердем инде, шул җитә», — дип уйлыйлар. Әмма үзләре дөрес итеп таhәрат тә ала белмиләр, Аллаhу мүстәган! Аллаh Раббыбызның беренче Коръән аятьләре дә кешегә гыйлем эстәүне таләп итеп иңдерелде, шулай ук расүлебез ﷺ дә гыйлем хакында бик күп хәдисләрендә әйтеп узды. Булсын ул ирләр яки хатыннар, алар җыенысы да шәригать гыйлемен алырга омтылырга тиешләр. Фәкать, кемгәдер ул мөстәхәб булса, икенчеләргә фарыз дип билгеләнде. Галимнәр арасыннан беркем дә, кемгәдер гыйлем алу кирәк түгел дигән фикерне әйтмәде. Чөнки гыйлемсезлек, кешегә тормышта да, ахирәттә дә төрле авырлыклар китерүгә сәбәп була. Аллаh Раббыбыз ошбу эшләребезне Үзенең ризалыгы өчен ихлас кылып, динебезгә файдалы

гамәлләрдән әйләсә иде. Бу китапта булган аз гына тырышлык, хәерлесе вә дөресе Аллаһ тәгаләдән:

(وَعَلَّمَكَ مَا لَمْ تَكُنْ تَعْلَمُ) النساء: ١١٣

Мәгънәсе: **«Аллаһ сиңа белмәгәнеңне өйрәтте».**

(وَلا يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ إِلا بِمَا شَاءَ) البقرة: ٢٥٥

Мәгънәсе: **«Аллаһ гыйлеменнән һичнәрсәне чолгап ала алмаслар, мәгәр Аллаһ теләгәнне генә белерләр».**

Ә инде китапта хата вә кимчелек булса — минем үземнән вә шәйтаннан:

(قُلْ هُوَ مِنْ عِنْدِ أَنْفُسِكُمْ) آل عمران: ١٦٥

Мәгънәсе: **«Әйт: «Бу үзегезнең нәфсегездән», — диген».**

(وَكَانَ الشَّيْطَانُ لِلْإِنْسَانِ خَذُولا) الفرقان: ٢٩

Мәгънәсе: **«Шәйтан кешегә батылны матурлап вә хакны кабахәт кылып, алдап ташлап китәр булды».**

Йә Раббым! Барчабызга да һидәят-тәүфыйк бир! Кушканнарыңны үтәп, тыйганнарыңнан тыелып яшәргә насыйп ит!

Йә Раббым! Безне Үзеңнең туры юлыңнан алып бар, хакны хак итеп белгерт һәм безне хаклыкка якынайт, батылны батыл итеп белгерт һәм безне батылдан ерагайт. Коръән вә сөннәткә тотынучылардан кыл, һәм ихлас-тәкъва бәндәләреңнән әйләп, Үзеңнең рәхмәтең белән Фирдәвес Җәннәтләреңә керт! Әмин!

Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

Хатлар өчен: mullaniyaz@mail.ru

# Гомуми мәсьәләләр

# Хатын-кызларга карата яхшы мөгамәлә

Рәхимлелекнең тышкы галәмәтләреннән — ул, хатын-кызларга карата яхшы мөгамәләдә булу. Чөнки аларны Аллаһ тәгалә башкаларга караганда зәгыйфь итеп халикъ кылды. Шуңа да Ислам, хатын-кызга карата яхшы караш-та, ихсанлы булырга, аларның вакыты белән килеп чыга торган кәкре холыкларына сабыр итәргә, рәхимлелек вә сөйкемлелек белән мөгамәлә итеп, аларга золым кылмаска кушты.

Хатын-кызларга яхшы мөгамәләдә булуны таләп итеп килгән аять вә хәдисләр бихисап.

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ عَنْ النَّبِيِّ ﷺ قَالَ: «وَاسْتَوْصُوا بِالنِّسَاءِ خَيْرًا فَإِنَّهُنَّ خُلِقْنَ مِنْ ضِلَعٍ وَإِنَّ أَعْوَجَ شَيْءٍ فِي الضِّلَعِ أَعْلَاهُ فَإِنْ ذَهَبْتَ تُقِيمُهُ كَسَرْتَهُ وَإِنْ تَرَكْتَهُ لَمْ يَزَلْ أَعْوَجَ فَاسْتَوْصُوا بِالنِّسَاءِ خَيْرًا» [ البخاري ٥١٨٦ ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Һәрвакытта да хатын-кызлар белән яхшы булыгыз, хакыйкатьтә алар кабыргадан халикъ кылындылар, һәм андагы (кабыргадагы) иң кәкре урын — өске өлеше, әгәр дә син ул кабырганы турайтырга уйласаң — сындырырсың, ә инде аны калдырсаң, аңа тимәсәң — ул шулай ук кәкре булып калыр, (шуның өчен дә һәрвакытта да) хатын-кызлар белән яхшы булыгыз!».

Бу хәдистә пәйгамбәребез ﷺ хатын-кызларның кабыргадан яратылганнарын бәян итте. Кабырга үзе кәкре, әмма андагы тагын да кәкрерәк урын — ул, аның өске өлеше. Хатын-кызның өске өлеше — ул, аның башы (теле һәм

фикер йөртүе). Шулай булгач, хатын-кызның яратылуы ошбу рәвештә икән, ир-ат кеше аларның холык-фигыленә һәм үзләрен тотуда булган барча табигый кәкрелекләренә, золым кылмыйча сабыр итәргә тиеш.

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ: «لا يَفْرَكْ مُؤْمِنٌ مُؤْمِنَةً إِنْ كَرِهَ مِنْهَا خُلُقًا رَضِيَ مِنْهَا آخَرَ» [ مسلم ١٤٦٩ ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөэмин ир кеше мөэминәгә нәфрәтле (дошманлы) булмас, әгәр дә аның бер төрле холкын сөймәсә, башка холкыннан риза булыр».***

Бу хәдистә пәйгамбәребез ﷺ кешенең тормышта була торган вакыйгый ягын тасвирлап узды. Һәрбер кешенең риза булырлык һәм күрә алмаслык яклары бар. Әгәр дә аның хатынында ул күрә алмаслык бер төрле холык бар икән, ул аны яхшы мөгамәлә белән тәрбияләп һәм хатынындагы яхшы сыйфатларын гына күздә тотып вә кимчелекләрне күрмәскә тырышып, тормышын матур гына дәвам итәргә тиеш.

«وَاسْتَوْصُوا بِالنِّسَاءِ خَيْرًا فَإِنَّمَا هُنَّ عَوَانٌ عِنْدَكُمْ» [ الترمذي ١١٦٣، حسن ]

Мәгънәсе: ***«...Һәрвакытта да хатын-кызлар белән яхшы булыгыз, хакыйкатьтә алар сездә (сезнең кул астыгызда) әсирләр...»***

Әт-Тирмизидә килгән бу хәдис, пәйгамбәребезнең ﷺ саубуллашу хаҗында кылган хөтбәсенең бер өлеше. Ул монда хатын-кызларны, ирләре кул астында әсирләр кебек икәнлекләрен бәян итте, һәм шуңа да алар белән яхшы булырга кирәклеген белдерде.

Пәйгамбәребезнең ﷺ кешеләрне белер өчен куйган үлчәүләрнең берсе — ул, ир-атның хатын-кызларына (хатыннары, бер туган апа-сеңелләре, кызлары һ.б. туган тиешлеләренә) карата булган мөгамәләсе. Кемнең хатын-кызларына карата мөгамәләсе яхшы булса, ул хәерле кешеләрдән. Ә кемнең мөгамәләсе аларга карата яхшы

булмаса, ул инде яки файдасыз кешеләрдән, яки начарлардан була.

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ: «أَكْمَلُ الْمُؤْمِنِينَ إِيمَانًا أَحْسَنُهُمْ خُلُقًا وَخِيَارُكُمْ خِيَارُكُمْ لِنِسَائِهِمْ خلقا» [ الترمذي ١١٦٢ حَدِيثٌ حَسَنٌ صَحِيحٌ ]

Мәгънәсе: ***«Камил иманлы мөэминнәр шулардыр — кайсыларының холыклары иң яхшысы. Һәм сезнең арагызда иң хәерлеләре шулардыр — кайсылары хатын-кызларына иң яхшы холыклысы».***

Хатын-кыз үзенең зәгыйфьлеге аркасында, башкаларның аның белән рәхимле булуына мохтаҗ. Ир-ат эш урыны яки башка нәрсә өчен кешеләр белән мөлаем булган булып, яки башкаларга яхшы күренергә тырышкан булып, начар холкын яшереп яшәсә дә, әмма гаиләсендә барсы да билгеле була. Әгәр табигатендә начар холыклы булган икән, аның начар холкы гаиләсендә ачыла. Ә инде табигатендә яхшы холыклы икән, ул гаиләсендә дә шулай ук булып кала. Шуңа да пәйгамбәребез ﷺ: ***«Хатын-кызларына иң яхшы холыклы кеше — ул иң хәерле кеше»,*** — диде. Чөнки ул өйдә дә, башка урында да бер төрле генә (яхшы) холыклы була. Без бу хәдистә пәйгамбәребезнең ﷺ кешеләрне бик тә нечкә үлчәү белән үлчәгәнен аңлыйбыз.

Пәйгамбәребезнең ﷺ бу төшенчәләре Коръәндәге "ән-Ниса" сүрәсенең ошбу аятенә аңлатма вә бәян булып килде:

(وَعَاشِرُوهُنَّ بِالْمَعْرُوفِ فَإِنْ كَرِهْتُمُوهُنَّ فَعَسَى أَنْ تَكْرَهُوا شَيْئًا وَيَجْعَلَ اللَّهُ فِيهِ خَيْرًا كَثِيرًا) النساء: ١٩

Мәгънәсе: **«Никахыгызда булган хатыннар белән яхшы мөгамәләдә булыгыз, гәрчә аларны бик яратмасагыз да. Өметледер сез яратмаган нәрсәдә Аллаһның күп яхшылык кылмаклыгы».**

Аларга яхшы мөгамәлә ул — аларның ир белән хатын арасында булган хокукларын үтәүдә, аларга ихсанлы, йомшак күңелле, кәкре холыкларына сабыр булуда билгеләнә. Шулай ук аларны шәригать билгеләгәнчә, за-

манага вә җәмгыятькә карап матди яктан тәэмин итү тиешле. Хатыннар талак сорарлык яки казыйга барып аны таләп итәрлек, аларны тиешсез түбәнсетергә, җәберләргә яки золым кылырга ярамый. Кемнәр хатыннарына карата начар мөгамәләдә булып, аларны авыр вә уңайсыз хәлгә калдыралар икән, ул кешеләр Аллаһка мәгъсыять вә гөнаһ кылучылар. Чөнки алар югарыда искә алынган аятькә каршы баралар, һәм хатыннары белән начар булып аларны үзләреннән качарга мәҗбүр итәләр. Яки үз өсләренә йөкләнгән мәсьүлияттән (җаваплылыктан) качу юлын эзлиләр.

Аллаһ тәгалә (мәгънәсе): **«Гәрчә аларны бик яратмасагыз да. Өметледер сез яратмаган нәрсәдә Аллаһның күп яхшылык кылмаклыгы»,** — дип әйтүендә, бик тә тирән мәгънәләр ята, һәм монда безнең өчен хикмәтләр вә гыйбрәтләр бар. Чөнки кешенең нәфесе нәрсәне дә булса яратып бетерми икән, анда зарар яки бәла бар дигән сүз түгел әле. Бәлки нәфес күп вакыт хискә (һәүәга, хәвәскә) бирелеп беленә торган әйберләргә таяна.

Булсын ул тәмле яки ачы, чибәр яки ямьсез, сөйкемле яки тупас һәм башкалар. Күп вакыт ошбу хәвәскә бирелеп эшләнгән нәрсәләр, тормышта ир белән хатын арасын бозуга сәбәп була. Ләкин ошбу яратмаган нәрсәләрдә дә кеше өчен хәерле нәтиҗәләр бар. Мәсәлән, авыру кешегә әче тәмсез дару бирсәң, ул аны эчәсе килми, ләкин ул даруда Аллаһ теләге белән аңа дәва бар икәнен белеп йөзенчыраен сытып булса да, сабырлык күрсәтеп эчә.

Күпме хатын-кыз холык, оялчанлык, әманәт һәм дин ягыннан күркәм булса да, кияүгә чыккач ирләренең күңелләренә хуш килмичә ошамый башлый. Әмма инде ир-ат үзенең күңелендә булганны тышка чыгармыйча сабырлык белән хатынына яхшы мөгамәлә итсә, Аллаһ тәгалә ул хатында бик күп хәерлелек кыла. Ул хатын иренә хыянәт кылмыйча, җиңеллектә дә, авырлыкта да аңа ярдәмче вә терәк була. Ире өйдә юк вакытта, аның малын саклый, һәм изге-алих балалар үстереп тәрбияләп, ирне бәхетле итә.

Ир-ат өчен бу дөньяда иң хәерле ләззәт — ошбу дөньяда да ахирәттә дә бәхеткә илтүдә сәбәп булган хатыны булу.

١٤٦٩- عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ عَمْرٍو أَنَّ رَسُولَ اللهِ ﷺ قَالَ: «الدُّنْيَا مَتَاعٌ وَخَيْرُ مَتَاعِ الدُّنْيَا الْمَرْأَةُ الصَّالِحَةُ» [ مسلم ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гамр бин әл-Гастан ﷺ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөнья ул — ләззәтлек, һәм андагы иң хәерле ләззәтлек — изге хатын».***

Яки ул шундый хатын ки — динле, күркәм холыклы һәм ирен һәрвакытта да шатландырып вә күңелен күреп торучы.

Әгәр дә изге хатын диндар булса, ире аны яратып бетермәсә дә, аның өчен иң хәерлесе — ул хатынны кимсетмичә аның белән яхшы булуы. Әйе, ул ир-ат хатынын яратырга үзен мәҗбүр итә алмый, ләкин аның белән күркәм булырга, хатынының яхшы якларын гына күрергә булдыра ала. Һәм вакыт узып хатынының ошамаган яклары ошбу яхшы яклар белән каплана, хәтта ул аларны күрми башлый. Шулай ук заманалар үтеп алар арасына өлфәт керә, ә өлфәт кергән йөрәккә мәхәббәтнең керүе озак түгел.

Әйткәнебезчә, ир-атның хатынын яратмавы, хатынында бер төрле холкын ошатмау сәбәпле булырга мөмкин. Ләкин ул аның барча холкына да караса, әлбәттә анда, аңа ошый торган холык тапмый калуы мөмкин түгел.

Билгеле булганча, кабырга — кешедәге иң нечкә вә зәгыйфь сөяк. Шулай ук кабырга кеше күкрәгендә савыт кебек, эчендә булган әйберләрне саклый. Хәдистән аңлашылганча, хатын-кыз кабырга кебек, нечкә һәм зәгыйфь булып яратылды, җитмәсә аның вакыты белән кәкре холкы килеп чыга. Ул кабырга кебек гаиләнең савыты, йорт эчендә булган барча нәрсәне тышка чыгармый саклый. Әгәр дә аны төзәтергә уйласаң, әлбәттә сындырасың һәм гаиләңә зыян китерәсең. Шуңа да хатын-кызның кимчелекле холкына бик игътибар итмичә, аны вәгазьләп, яхшы мөгамәлә кылып, сабыр итәргә кирәк.

Әгәр дә үзара килешү таба алмасалар, ул вакытта әлбәттә, аларга аерылу хәерледер. Шуңа да, шушындый кызганыч хәлләр өчен шәригатебездә талак каралган.

(وَإِنْ يَتَفَرَّقَا يُغْنِ اللَّهُ كُلا مِنْ سَعَتِهِ وَكَانَ اللَّهُ وَاسِعًا حَكِيمًا)
النساء: ١٣٠

Мәгънәсе: «**Әгәр ир белән хатын килешә алмыйча, аерылышсалар, Аллаһ үзенең рәхмәте белән икесен дә баетыр, Аллаһ бит киң рәхмәтле вә хикмәт илә эш кылучы булды».**

Ир-атның берничә хатыны булган очракта, ул әлбәттә аларның барчасына карата да гадел булырга тиеш. Гаделлек көннәрне билгеләүдә, ашату вә киендерүдә, аларга карата яхшы мөгамәлә кылуда билгеләнә. Ә инде мәхәббәт, күңелнең бер хатынына күбрәк авышуы кебек аның теләгеннән тормаган әйберләрдә гаделлек каралмаган. Шуңа да, пәйгамбәребез ﷺ моны үзенең хәдисендә бәян итеп болай диде:

عَنْ عَائِشَةَ قَالَتْ كَانَ رَسُولُ اللهِ ﷺ يَقْسِمُ فَيَعْدِلُ وَيَقُولُ: «اللَّهُمَّ هَذَا قَسْمِي فِيمَا أَمْلِكُ فَلا تَلُمْنِي فِيمَا تَمْلِكُ وَلا أَمْلِكُ» [ ابن ماجه ١٩٧١، تحقيق الألباني: ضعيف، لكن الطرف الأول منه حسن ]

Мәгънәсе: Гаишә رضي الله عنها әйтте: *«Расүл ﷺ хатыннары аралaрын тигез итеп һәм гаделлек белән бүлә иде, вә әйтә иде:* «***Йә Аллаһ! Бу минем көчемнән булган тигезлек вә гаделлек, минем көчемнән булмаган, Үзеңнең кодрәтеңнән булган (йөрәкнең кемгә дә булса авышуы) өчен, мине битәрләмә***».

# Ир яки кыз бала тууы хакында

Баланың ир яки кыз булып тууы — Аллаһ тәгалә теләге белән. Һәм пәйгамбәребез ﷺ үзенең хәдис-шәрифендә ошбу нәрсәнең кайбер сәбәпләрен бәян итеп узды:

... قَالَ جِئْتُ أَسْأَلُكَ عَنِ الْوَلَدِ قَالَ مَاءُ الرَّجُلِ أَبْيَضُ وَمَاءُ الْمَرْأَةِ أَصْفَرُ فَإِذَا اجْتَمَعَا فَعَلَا مَنِيُّ الرَّجُلِ مَنِيَّ الْمَرْأَةِ أَذْكَرَا بِإِذْنِ اللهِ وَإِذَا عَلَا مَنِيُّ الْمَرْأَةِ مَنِيَّ الرَّجُلِ آنَثَا بِإِذْنِ اللهِ... [ مسلم ٣١٥ ]

Мөслимдә килгән бу озын хәдиснең без шушы мәсьәлә белән бәйле булган бер өлешен генә алабыз. Мәгънәсе: Сәүбән رضي الله عنه әйтте: *«Мин пәйгамбәребез ﷺ янында басып торганда яһүдләрнең бер рухание килде, һәм әйтте: «...Мин синнән бала хакында сорарга килдем?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Ир-атның суы (мәние) ак, ә хатын-кызныкы сары. Әгәр дә алар берләшсәләр, һәм ир-атның мәние хатын-кызныкына караганда күбрәк булса, ул вакытта Аллаһ теләге белән малай була. Әгәр дә хатын-кызның мәние ир-атныкына караганда күбрәк булса — Аллаһ теләге белән кыз була».***

حَدَّثَنَا أَنَسٌ أَنَّ عَبْدَ اللهِ بْنَ سَلَامٍ بَلَغَهُ مَقْدَمُ النَّبِيِّ ﷺ الْمَدِينَةَ فَأَتَاهُ يَسْأَلُهُ عَنْ أَشْيَاءَ فَقَالَ إِنِّي سَائِلُكَ عَنْ ثَلَاثٍ لَا يَعْلَمُهُنَّ إِلَّا نَبِيٌّ مَا أَوَّلُ أَشْرَاطِ السَّاعَةِ وَمَا أَوَّلُ طَعَامٍ يَأْكُلُهُ أَهْلُ الْجَنَّةِ وَمَا بَالُ الْوَلَدِ يَنْزِعُ إِلَى أَبِيهِ أَوْ إِلَى أُمِّهِ قَالَ أَخْبَرَنِي بِهِ جِبْرِيلُ آنِفًا قَالَ ابْنُ سَلَامٍ ذَاكَ عَدُوُّ الْيَهُودِ مِنَ الْمَلَائِكَةِ قَالَ أَمَّا أَوَّلُ أَشْرَاطِ السَّاعَةِ فَنَارٌ تَحْشُرُهُمْ مِنَ الْمَشْرِقِ إِلَى الْمَغْرِبِ وَأَمَّا أَوَّلُ طَعَامٍ يَأْكُلُهُ أَهْلُ الْجَنَّةِ فَزِيَادَةُ كَبِدِ الْحُوتِ وَأَمَّا الْوَلَدُ فَإِذَا سَبَقَ مَاءُ الرَّجُلِ مَاءَ الْمَرْأَةِ نَزَعَ الْوَلَدَ وَإِذَا سَبَقَ مَاءُ الْمَرْأَةِ مَاءَ الرَّجُلِ نَزَعَتِ الْوَلَدَ قَالَ أَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَأَنَّكَ رَسُولُ اللهِ قَالَ يَا رَسُولَ اللهِ إِنَّ الْيَهُودَ قَوْمٌ بُهُتٌ فَاسْأَلْهُمْ عَنِّي قَبْلَ أَنْ يَعْلَمُوا بِإِسْلَامِي فَجَاءَتِ الْيَهُودُ فَقَالَ

النَّبِيُّ ﷺ أَيُّ رَجُلٍ عَبْدُ اللهِ بْنُ سَلَامٍ فِيكُمْ قَالُوا خَيْرُنَا وَابْنُ خَيْرِنَا وَأَفْضَلُنَا وَابْنُ أَفْضَلِنَا فَقَالَ النَّبِيُّ ﷺ أَرَأَيْتُمْ إِنْ أَسْلَمَ عَبْدُ اللهِ بْنُ سَلَامٍ قَالُوا أَعَاذَهُ اللهُ مِنْ ذَلِكَ فَأَعَادَ عَلَيْهِمْ فَقَالُوا مِثْلَ ذَلِكَ فَخَرَجَ إِلَيْهِمْ عَبْدُ اللهِ فَقَالَ أَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَأَنَّ مُحَمَّدًا رَسُولُ اللهِ قَالُوا: «شَرُّنَا وَابْنُ شَرِّنَا» وَتَنَقَّصُوهُ قَالَ: «هَذَا كُنْتُ أَخَافُ يَا رَسُولَ اللهِ» [ البخاري ٣٩٣٨ ]

Мәгънәсе: Әнәс ﵁ әйтте: *«Габдуллаһ бин Сәлам пәйгамбәребезнең ﷺ Мәдинәгә килгәнен белгәч аның янына килде һәм әйтте: «Мин синнән, пәйгамбәр генә белә торган өч әйбер хакында сорыйсым килә: Кыямәт сәгатенең беренче галәмәте нинди була? Җәннәт әһелләренең беренче ризыгы нәрсә була? Һәм ни өчен бала әтисенә яки анасына охшый?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Боларның барсы хакында да әле генә миңа Җибрил хәбәр итте». Габдуллаһ бин Сәлам әйтте: «Фәрештәләр арасыннан ул яһүдләрнең бердәнбер дошманы!». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Әмма Кыямәт сәгатенең беренче галәмәте — ул, кешеләрне көнчыгыштан көнбатышка (мәхшәр җиренә) куучы ут булачак. Ә инде Җәннәт әһелләренең беренче ризыгы булып Кит балыгының бавырыннан бер өлеше булачак. Ә балага килгәндә болайдыр: әгәр дә якынлык вакытында ир-атның мәние хатынныкыннан алдарак чыкса, ул вакытта бала аңа охшаячак, ә инде хатын-кызның мәние ир-атныкына караганда алдарак чыкса, ул вакытта анасына охшаячак».*** *Габдуллаһ бин Сәлам әйтте: «Хакыйкатьтә, мин шәһәдәт итәм Лә иләһә иллә Аллаһ үә әннәкә расүл Аллаһ (Аллаһтан башка һич иләһ юк, һәм син Аллаһның илчесе)», шуннан соң әйтте: «Әй расүл Аллаһ! Хакыйкатьтә, яһүдләр ялганчылар, алар минем Исламны кабул иткәнемне белгәнче, син алардан минем хакта сора». Бераздан пәйгамбәребез ﷺ янына яһүдләр килде (ә Габдуллаһ бин Сәлам йортта яшеренгән иде) һәм пәйгамбәребез ﷺ алардан сорады:* ***«Габдуллаһ бин Сәлам сезнең арагызда нинди урын алып тора?».*** *Алар әйттеләр: «Ул — безнең арада иң хәерлесе (гыйлемлесе) һәм безнең арада булган иң хәерле (гыйлемле) кешенең улы. Ул — арабызда иң яхшысы һәм арабыздагы иң яхшы*

*кешенең улы!» Шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ сорады:* ***«Әгәр дә ул Исламны кабул итсә, сез нәрсә әйтер идегез?».*** *Алар әйттеләр: «Аллаһ сакласын аны бу эштән!». Шуннан соң Габдуллаһ бин Сәлам алар янына чыкты һәм әйтте: «Хакыйкатьтә, мин шәһәдәт итәм — Аллаһтан башка иләһ юк һәм Мөхәммәд Аның илчесе!». Яһүдләр моны ишеткәч әйттеләр: «Ул — безнең арабызда иң яманы вә арабыздагы иң яман кеше улы». Һәм алга таба да аның хакында яман сөйләүләрен дәвам иттеләр. Габдуллаһ бин Сәлам әйтте: «Мин шушыннан курка идем, йә расүл Аллаһ!».* (Бохари)

Бу хәдисләр хакында галимнәр бик күп фикерләр әйтте һәм шуларны кыскача гына бәян итеп узарбыз:

Ибен Хәҗәр әйтте: «*Мәнинең алдан чыгуы ир яки кыз булуның галәмәте булыр, ә мәнинең күплеге баланың әтисенә яки әнисенә охшау билгесе булыр*».

Мустафа әл-Гадавий: «*Дөресрәге, әгәр дә мәни алдан чыкса баланың әтисенә яки әнисенә охшау билгесе булыр, ә мәнинең күплеге ир яки кыз булуның галәмәте булыр*».

Шуннан соң ибен Хәҗәр әйтте: «*Мәнинең күплеге һәм алдан чыгуы белән бәйле мәсьәлә берничәгә бүленә:*

- *Әгәр дә ир-атның мәние алданрак чыкса һәм күбрәк булса, ул вакытта ир бала була һәм аңа охшаган була.*
- *Әгәр дә хатын-кызның мәние алданрак чыкса һәм күбрәк булса, ул вакытта кыз бала була һәм аңа охшаган була.*
- *Әгәр дә ир-атның мәние алданрак чыкса, ә хатын-кызның мәние күбрәк булса, ул вакытта ир бала була ләкин әнисенә охшаган була.*
- *Әгәр дә хатын-кызның мәние алданрак чыкса, ә ир-атның мәние күбрәк булса, ул вакытта кыз бала була, ләкин әтисенә охшаган була.*
- *Әгәр дә ир-атның мәние алданрак чыкса һәм күплектә икесенеке дә тигез булса, ул вакытта ир бала була, ә охшашлыкта икесенең берсе дә тәгаенләнми, мөмкин әтисенә охшарга, мөмкин әнисенә.*

• *Әгәр дә хатын-кызның мәние алданрак чыкса һәм күплектә икесенеке дә тигез булса, ул вакытта кыз бала була, ә охшашлыкта икесенең берсе дә тәгаенләнми, мөмкин әнисенә охшарга, мөмкин әтисенә.*

*Болар һәммәсе дә Аллаһ тәгаләнең теләге белән».*

## Хатын-кызларны сөннәтләү (хитән яки хафд)

Шәригатебездә сөннәтләү (хитәнләү) ирләр өчен дә, хатыннар өчен дә каралган мәсьәлә. Ләкин ирләргә ул вәҗиб булса, хатын-кызга килгәндә галимнәр төрле фикерләргә бүленделәр. Кемнәрдер аны вәҗиб дисәләр, икенчеләре сөннәт гамәл диделәр, ә өченчеләре яшәү урыннарына бүлделәр (эссе илләрдә хатын-кыз сөннәтләнә дисәләр, суык илләрдә сөннәтләнми диделәр). Бу хакта пәйгамбәребездән ﷺ ирләргә дә, хатыннарга да гомуми бәян кылган түбәндәге хәдис-шәриф килә:

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ ﵁ سَمِعْتُ النَّبِيَّ ﷺ يَقولُ: «الْفِطْرَةُ خَمْسٌ الْخِتَانُ وَالاسْتِحْدَادُ وَقَصُّ الشَّارِبِ وَتَقْلِيمُ الأَظْفَارِ وَنَتْفُ الآبَاطِ» [ البخاري ٥٨٩١ ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: *«Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: **«Биш әйбер фитрадан: хитән (сөннәткә утырту), истихдәд (җенес әгъзаның тирә ягында үскән чәч бөртекләрен кыру), мыек кыскарту, тырнакларны кисү һәм култык астындагы чәч бөртекләрен йолку».***

Әйтүебезчә, бу хәдис хатын-кызларны сөннәтләүдә вәҗиб дигәнгә аерым махсус булып килми, бәлки ул аларга да кагыла торганга әйләнә, әгәр дә бу хәдискә икенче, ошбу хәдисне кушып аңлатсак кына:

«...إِنَّ النِّسَاء شَقَائِق الرِّجَال...» [ الترمذي ١١٣ تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: ***«Хакыйкатьтә, хатыннар ирләрнең туганнары».***

Ләкин, ул вәҗиб дигән сүз түгел, чөнки вәҗиблегенә ишарә иткән бер генә сахих һәм ачык дәлил дә юк. Әгәр дә хатын-кызлардан кемдер бу гамәлне кылса, иншәАллаһ әҗерен алыр, ә кем кылмый икән, иншәАллаһ аңа бер нәрсә дә юк. Аллаһу әгъләм.

# ТАҺӘРАТ китабы

## Хатын-кыз кулы белән җенес әгъзасына тиеп китсә таһарате бозыламы?

Бу мәсьәләдә галимнәр икегә бүленде һәм ике як та сахих хәдисләр кулландылар.

**1) Таһәрат бозылмый диючеләрдән:** Гали, Гаммәр бин Йәсир, Габдуллаһ бин Мәсгуд, Габдуллаһ бин Габбас (бер риваятендә), Хүзәйфә бин әл-Йәмән, Гыймран бин Хусайн, Әбү Дәрдә, Сәгъд бин Әби Уаккас (бер риваятендә), Сәгыйд бин әл-Мүсәйб (бер риваятендә), Сәгыйд бин әл-Җүбәйр, Ибраһим әл-Нәхәгый, Рабийга бин Габдуррахман, Суфиян әс-Сәүрий, Габдуллаһ бин әл-Мүбәрак, Әбү Хәнифә һәм аның сахибләре (иярченнәре), Яхъя бин Мәгыйн, һәм кайбер Шәм вә барча Күфә әһелләре дип әйтелде. Алар ошбу хәдискә таяндылар:

٨٥ - حَدَّثَنَا هَنَّادٌ حَدَّثَنَا مُلاَزِمُ بْنُ عَمْرٍو عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ بَدْرٍ عَنْ قَيْسِ بْنِ طَلْقِ بْنِ عَلِيٍّ هُوَ الْحَنَفِيُّ عَنْ أَبِيهِ عَنْ النَّبِيِّ ﷺ قَالَ: «وَهَلْ هُوَ إِلاَّ مُضْغَةٌ مِنْهُ أَوْ بَضْعَةٌ مِنْهُ» [ الترمذي، تحقيق الألباني: صحيح ]

Кыскача мәгънәсе: Талк бин Гали әтисеннән риваять итүе буенча, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ул (җенес әгъза) тәннең бер кисәге генә».***

Шулай ук, ошбу мәгънәдәге сахих хәдис Әбү Давыдта, Ибен Мәҗәһ, ән-Нәсәидә килде. Һәм без инде ошбу фикерне алабыз. Аллаһу әгъләм.

**2) Ә инде таһәрат бозыла диючеләрдән**: Гомәр бин әл-Хәттаб, Габдуллаһ бин Гомәр, Әбү Әюб әл-Әнсарий, Зәйд бин Халид, Әбү Һурайра, Габдуллаһ бин Гамр бин әл-Гас, Җәбир, Гаишә, Үммү Хәбибә, Бүсра бинт Сафуан, Сәгъд бин Әби Уаккас (бер риваятендә), Габдуллаһ бин Габбас (бер риваятендә), Гур'уа бин Зүбәйр, Сөләймән бин Йәсәр, Гата бин Әби Рабәх, Әбән бин Госман, Җәбир бин Зәйд, әз-Зүһрий, Мусгаб бин Сәгъд, Яхъя бин Әбий

Кәсийр, Сәгыйд бин әл-Мүсәйб (бер риваятендә), Һишәм бин Гур'уа, әл-Әузәгый, Шәм әһелләренең күпчелеге, Шәфигый, Әхмәд һәм Исхак дип әйтелде, һәм алар ошбу хәдискә таяндылар:

١٨١ - عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ أَبِي بَكْرٍ أَنَّهُ سَمِعَ عُرْوَةَ يَقُولُ دَخَلْتُ عَلَى مَرْوَانَ بْنِ الْحَكَمِ فَذَكَرْنَا مَا يَكُونُ مِنْهُ الْوُضُوءُ فَقَالَ مَرْوَانُ وَمِنْ مَسِّ الذَّكَرِ فَقَالَ عُرْوَةُ مَا عَلِمْتُ ذَلِكَ فَقَالَ مَرْوَانُ أَخْبَرَتْنِي بُسْرَةُ بِنْتُ صَفْوَانَ أَنَّهَا سَمِعَتْ رَسُولَ اللهِ ﷺ يَقُولُ: «مَنْ مَسَّ ذَكَرَهُ فَلْيَتَوَضَّأْ» [ أبو داود تحقيق الألباني: صحيح ]

Кыскача мәгънәсе: Бүсра бинт Сафуаннан, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем дә кем җенес әгъзасына тия икән, таһәрат алсын».***

Шулай ук, таһәрат алырга диючеләр хатын-кызларга гына кагылган башка хәдисләр китерделәр, әмма ләкин ул хәдисләрнең дөреслегендә галимнәр арасында кайбер каршылыклы фикерләр бар. Шуңа да карамастан, хәдис гыйлемендә булган башка юллар белән чагыштырганда, икенчеләрнеке дөресрәк дип әйтелде. Аллаһу әгъләм.

Имам Мәлик бу мәсьәләдә берничә фикердә:

1) «Әгәр дә җенес әгъзасына шәһвәт белән тисә, ул вакытта таһәрате бозыла, шәһвәтсез тисә бозылмый».

2) «Әгәр дә кулның эчке ягы белән тисә бозыла, ә тышкы ягы белән тисә бозылмый».

3) «Әгәр дә юри тисә бозыла, ялгыш тисә бозылмый». Ләкин имам Мәлик мәзһәбендә тупланган фикер, ул — җенес әгъзага кул белән тиелсә таһәрат алу сөннәт, вәҗиб түгел.

**Бу мәсьәләдә хатын-кызлар белергә тиеш булган тагын берничә нокта:**

**1)** Бу мәсьәләләрдә җенес әгъзага ялан кул белән тию күздә тотыла.

**2)** Хатын-кызның кулы иренең җенес әгъзасына тисә берсенең дә таһәрате бозылмый, чөнки моңа бернинди ачык дәлил дә юк.

**3)** Шулай ук, хатын-кыз үзенең арткы ягына кулы белән тисә, таһарате бозылмый. Гыйлем әһелләре арасында моңа карата кайбер каршылыклы фикерләр булса да, әмма ләкин моны ачык кына бәян итеп килгән дәлил юк. Аллаһу әгъләм.

**4)** Хатын-кыз баласын юындырганда, яки башка нинди генә вакытта булса да аның җенес әгъзасына ялан кулы белән тисә, таһарате бозылмый, чөнки моңа бернинди ачык дәлил дә юк.

## Хатын-кызның бизәнүе

Хатын-кыз әгәр дә төрле буяу, яки тырнак баклары кебек нәрсәләр белән бизәнергә тели икән, ул аларны намазга таһарат алыр алдыннан юып төшерергә тиеш.

عَنْ ابْنِ عَبَّاس ﵄ قَالَ: «نِسَاؤُنَا يَخْتَضِبْنَ أَحْسَنَ خِضَاب، يَخْتَضِبْنَ بَعْدَ الْعِشَاءِ وَ يَنْزَعْنَ قَبْلَ الْفَجْرِ» [ مصنف ابن أبي شيبة ١/١٢٠، صحيح ]

Мәгънәсе: Ибен Габбас ﵄ әйтте: ***«Безнең хатыннарыбыз ястүдән соң иң матур бизәнү белән бизәнәләр һәм иртәнге намаз алдыннан бетерәләр (юалар) иде».***

عَنْ عَلْقَمَةَ أَنَّهُ كَانَ يَأمُر نِسَاءَهُ يَخْتَضِبْنَّ فِي أَيَّامِ حَيْضِهِنَّ [ أخرجه البيهقي في السنن الكبرى ١/٧٧، صحيح عن علقمة ]

Мәгънәсе: ***«Галкама хатыннарына күрем вакытында бизәнү буяулары белән бизәнергә әмер итә иде».***

عَنْ إِبْرَاهِيمِ (النَّخَعي) في الْمَرْأَةِ تَخْضِبُ يَدَيْهَا عَلَى غَيْرِ وُضُوءٍ ثُمَّ تَحْضُرُهَا الصَّلاة، قَالَ: «تَنْزَعُ مَا عَلَى يَدَيْهَا إِذَا أَرَادَتْ أَنْ تُصَلِّي» [ أخرجه البيهقي في السنن الكبرى ١/٧٨ ]

Мәгънәсе: Таһәратсез вакытта кулын бизәнү буявы белән буяп, намаз вакыты кергән хатын-кыз хакында Ибраһим ән-Нәхәгыйдан сорадылар, әйтте: ***«Намаз укырга җыенса, кулында булган барча нәрсәне бетерә (юа)».***

## Күкрәк сөте имә торган кыз бала сидегенә кагылышлы мәсьәлә

Бу мәсьәләдә шулай ук галимнәр арасында каршылыклы фикерләр булса да, ләкин күпчелек гыйлем ияләре күкрәк сөте имә торган ир бала белән кыз баланың сидеге аерыла диделәр. Кемнәрдер икесенең дә сидек урыны юыла дисәләр, икенчеләре кыз баланыкы гына юыла диделәр. Моңа дәлил итеп түбәндәге хәдисне китерергә мөмкин:

٦١٠- عَنْ عَلِيِّ بْنِ أَبِى طَالِبٍ رَضِىَ الله عَنْهُ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صَلَّى الله عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ فِى بَوْلِ الْغُلاَمِ الرَّضِيعِ «يُنْضَحُ بَوْلُ الْغُلاَمِ وَيُغْسَلُ بَوْلُ الْجَارِيَةِ» [ سنن الترمذي، تحقيق الألباني: صحيح ، ابن ماجة ٥٢٥ ]

Мәгънәсе: Галидән ﷺ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ир бала сидеге урынына су сибелә, ә кыз баланыкы юыла».***

Бу хәдистә ир бала сидеге белән кыз баланыкы аерыла дип килсә дә, Галидән килгән икенче сахих әсәрдә күкрәк сөте имә торган бала хакында сүз барганлыгы аңлашыла:

٣٧٧- عَنْ عَلِيٍّ رَضِى الله عَنْهُ قَالَ يُغْسَلُ مِنْ بَوْلِ الْجَارِيَةِ وَيُنْضَحُ مِنْ بَوْلِ الْغُلاَمِ مَا لَمْ يَطْعَمْ» [ سنن أبي داود، تحقيق الألباني : صحيح موقوف ]

Мәгънәсе: Гали ﷺ әйтте: ***«Ашамый торган (күкрәк кенә имүче) кыз бала сидеге урыны юыла, ә ир бала сидеге урынына су сибелә».***

Бу мәсьәлә әйткәнебезчә күкрәк сөте имүче бала хакында, ә инде ризык ашый торган баланың, булсын малай яки кыз, икесенең дә сидеге юыла. Аллаһу әгъләм.

## Хатын-кызның киеменә күкрәк сөте тисә?

Әгәр дә хатын-кыз баласын имезгәндә, киеменә күкрәк сөте тисә, моның өчен бернәрсә дә юк, һәм аны юарга да тиешле түгел, чөнки күкрәк сөте нәҗес түгел. Бу хакта Ибраһим ән-Нәхәгый болай диде:

عن إبراهيم قال: «لا بَأسَ بِلَبَنِ الْمَرأةِ أَنْ يُصِيبَ ثَوْبَهَا يَعْنِي لَبَنَهَا» [ مصنف ابن أبي شيبة١/١٧٢ ]

Мәгънәсе: ***«Хатын-кызның киеменә күкрәк сөте тисә, бер зарар да юк».***

## Мәзи

Мәзинең нәҗес булуында галимнәр арасында каршылыклы фикерләр юк. Әгәр дә мәзи чыга икән, ул вакытта җенес әгъзасын юып намазга таһәрат алу тиешле. Һәм моңа дәлил булып ошбу хәдис килә:

عَنْ عَلِيٍّ قَالَ كُنْتُ رَجُلا مَذَّاءً فَأَمَرْتُ رَجُلًا أَنْ يَسْأَلَ النَّبِيَّ ﷺ لِمَكَانِ ابْنَتِهِ فَسَأَلَ فَقَالَ: «تَوَضَّأْ وَاغْسِلْ ذَكَرَكَ» [ البخاري ٢٦٩ ]

Мәгънәсе: Гали ؓ әйтте: *«Мин мәзи күп чыгучы ир идем һәм бер кешедән (әл-Микъдәд бин әл-Әсүәдтән) пәйгамбәребездән ﷺ аның кызы (Фатыйма) хакына сорарга куштым (шушы мәсьәләне). Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Җенес әгъзаңны юу һәм таһәрат ал».***

Бу хөкем хатын-кызларга да кагыла, чөнки әйтелгәнчә:

«...إِنَّ النِّسَاءِ شَقَائِقُ الرِّجَال...» [ الترمذي ١١٣ تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: «***Хакыйкатьтә, хатыннар — ирләрнең туганнары***».

Гомум булган хөкемдә хатыннарга кыгылышлы аерым дәлил булмаса, алар гомуми хөкем астына керәләр.

## Хатын-кызларның җенес әгъзасыннан чыккан сыекчалар

Бу мәсьәләдә галимнәр төрле каршылыклы фикерләргә килделәр. Кемнәрдер алдан да, арттан да чыккан барча нәрсә дә нәҗес дисә, икенчеләре нәҗес түгел диде. Без инде нәҗес дигән белән килешмибез, чөнки сидек, зур хаҗәт, арттан һава чыгу, күрем каны, нифәс каны (бала тапканнан соң килә торган кан), мәни һәм мәзи кебек нәрсәләргә нәҗес яки таһәрат бозыла дип шәригатебездә дәлилләр булса, башкасына дәшми калынды. Шулай ук, пәйгамбәребез ﷺ вакытында, хәзерге замандагы кебек үк, бу нәрсә хатын-кызларда билгеле иде, әмма расүлебез ﷺ аңа карамастан берсен дә таһәрат белән илзәм кылмады. Ә инде кем ошбу түбәндәге аятькә таянып нәҗес дисә:

(أَوْ جَاءَ أَحَدٌ مِنْكُمْ مِنَ الْغَائِطِ) المائدة: ٦

Мәгънәсе: **«Яки берәрегез түбән җирдән (бәдрәфтән, чөнки кеше үзенең зур яки кечкенә хаҗәтен йомышлар өчен түбәнрәк, кеше-фәлән күрмәслек урынга бара торган була) килсәгез».**

Галимнәр әйтүенчә бу аятьтә сүз, кешенең яшеренеп эшли торган зур яки кечкенә хаҗәте турында бара. Аллаһу әгъләм.

## Хатын-кыз мәниенең сыйфаты (төсе) һәм төшләнсә госел коену тиешлеге хакында

أَنَّ أَنَسَ بْنَ مَالِكٍ حَدَّثَهُمْ أَنَّ أُمَّ سُلَيْمٍ حَدَّثَتْ أَنَّهَا سَأَلَتْ نَبِيَّ اللهِ ﷺ عَنِ الْمَرْأَةِ تَرَى فِي مَنَامِهَا مَا يَرَى الرَّجُلُ فَقَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «إِذَا رَأَتْ ذَلِكِ الْمَرْأَةُ فَلْتَغْتَسِلْ»، فَقَالَتْ أُمُّ سُلَيْمٍ وَاسْتَحْيَيْتُ مِنْ ذَلِكَ قَالَتْ وَهَلْ يَكُونُ هَذَا فَقَالَ نَبِيُّ اللهِ ﷺ: «نَعَمْ فَمِنْ

أَيْنَ يَكُونُ الشَّبَهُ إِنَّ مَاءَ الرَّجُلِ غَلِيظٌ أَبْيَضُ وَمَاءَ الْمَرْأَةِ رَقِيقٌ أَصْفَرُ فَمِنْ أَيِّهِمَا عَلَا أَوْ سَبَقَ يَكُونُ مِنْهُ الشَّبَهُ» [ مسلم ٣١١ ]

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәликтән ﷺ, Үммү Сүләйм пәйгамбәребездән ﷺ хатын-кыз төшендә ир кеше кебек үк төш күрүе (төшләнүе) хакында сорады. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә хатын-кыз шундыйны ук күрсә (төшләнсә), госел коенсын».*** Үммү Сүләйм әйтте: *«Мин оялдым ошбу нәрсәдән»,* һәм дәвам итеп әйттем: *«Алай буламы соң (ягъни хатын-кыз төшләнәме соң)?».* Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әйе, алай булмаса, кайдан аның (баланың әтисенә яки әнисенә) охшашлыгы була? Хакыйкатьтә, ир-атның суы (мәние) куе вә ак, ә хатын-кызның суы (мәние) нечкә (сыек) вә сары, кайсысыныкы күбрәк вә өстенрәк булса, яки алданрак чыкса, шуңа охшаган була».***

Ошбу мәгънәдәге хәдисне шулай ук ән-Нәсәи һәм ибен Мәҗәһ риваять итте. Әтисенә яки әнисенә охшау мәсьәләсен без **«Ир яки кыз бала тууы хакында»** дигән бүлектә аңлатып узган идек инде. Шулай ук, бу хәдистән күренгәнчә, хатын-кыз ир-ат кебек үк төшләнә һәм ошбу очракта ул госел коенырга тиешле.

## Ир һәм хатынның бергә госел коенуы

حَدَّثَنَا قَبِيصَةُ قَالَ حَدَّثَنَا سُفْيَانُ عَنْ مَنْصُورٍ عَنْ إِبْرَاهِيمَ عَنْ الأَسْوَدِ عَنْ عَائِشَةَ قَالَتْ: «كُنْتُ أَغْتَسِلُ أَنَا وَالنَّبِيُّ ﷺ مِنْ إِنَاءٍ وَاحِدٍ كلانا جنب» [ البخاري ٢٩٩ ]

Мәгънәсе: Гаишә ﷺ әйтте: ***«Без пәйгамбәр ﷺ белән бергә, җөнеб вакытында, бер савыттан су алып госел коена идек».***

Бу мәсьәләдә мөселман галимнәре арасында ихтиләф (капма-каршы фикерләр) юк. Аллаһу әгъләм.

## Хатын-кыз ире белән якынлык кылганнан соң госел коенгач, бераз вакыттан соң аннан иренең мәние чыкса, нишләргә тиеш?

Бу мәсьәләдә шулай ук галимнәр төрле каршылыклы фикерләргә бүленделәр. Кемнәрдер госел тиешле дисә, икенчеләре госел тиешле түгел, бәлки таһәрат кенә кирәк диделәр. Ә кайберләре госел дә, таһәрат тә тиеш түгел дигән фикерне әйтеп уздылар. Хәнәфи галимнәреннән булган “Фәтх әл-Кадир” китабының хуҗасы Мөхәммәд бин Габдулвахит бин әл-Һүмәм болай диде: «*Әгәр дә хатын-кыз ире белән якынлык кылганнан соң госел коенгач, бераз вакыттан соң аннан иренең мәние чыкса, аңа госел тиеш түгел*». Шулай ук Шәфигый мәзһәбенең галимнәреннән ән-Нәвәвий “әл-Мәҗмугъ” китабында: «*...госел коенмый, бәлки таһәрат кенә ала*», — дип әйтеп узды. Бу хакта башка галимнәрнең дә фикере күп, әмма ләкин без ошбуларны караганнан соң, хатын-кызга бу очракта госел тиешле түгел, бәлки намазга басса, таһәрат ала, дигән фикерне дөрес дип таптык. Һәм моны куәтләп шулай ук түбәндәге әсәрләрне китерергә мөмкин:

عَنْ الزُّهْرِيِّ في الْمَرْأةِ وَ الرَّجُلِ يَخْرُجُ مِنْهُمَا الشَّيء بَعْدَما يَغْتَسِلانِ، قَالَ: «يَغْتسلانِ فَرْجَهُمَا وَ يَتَوَضَّئان» [ مصنف ابن أبي شيبة ١/١٣٩، صحيح من قول الزهري ]

Мәгънәсе: Әз-Зүһрий хатын-кыз һәм ир кеше госел коенганнан соң аларның җенес әгъзаларыннан берәр нәрсә чыгуы хакында соралгач, болай диде: ***«Җенес әгъзаларын юалар һәм таһәратләнәләр».***

عَنْ جَابِرِ بن زَيْد في الْمَرأَةِ يَخْرُجُ مِنْهَا الشَّيء مِنْ مَاءِ الرَّجُلِ بَعْدَ الْغُسْلِ؟ قَالَ: «عَلَيْهَا الْوُضُوء» [ مصنف ابن أبي شيبة ١/١٤٠، صحيح ]

Мәгънәсе: Җәбир бин Зәйдтән ﵁ хатын-кыз (ире белән якынлык кылганнан соң) госел коенгач, аннан иренең суы (мәние) чыкса нишләргә тиеш дип соралгач, ул: ***«Таһәрат алырга тиеш»,*** — диде.

## Әгәр ире хатынын якынлык кылырга чакырса, ә хатыны госел коенырга иренеп, яки су юк дип, аны инкяр итсә, дөрес буламы?

Хатын-кыз су юк дип ире белән якынлык кылуны кире кага алмый, чөнки бу хакта пәйгамбәребезнең ﷺ ачыктан-ачык хәдисләре бар.

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ ﵁ عَنْ النَّبِيِّ ﷺ قَالَ: «إِذَا دَعَا الرَّجُلُ امْرَأَتَهُ إِلَى فِرَاشِهِ فَأَبَتْ أَنْ تَجِيءَ لَعَنَتْهَا الْمَلائِكَةُ حَتَّى تُصْبِحَ» [ البخاري ٥١٩٣ ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә ире хатынын якынлык кылырга чакырса, ә хатыны аны кире какса, фәрештәләр ул хатынны иртәнгә кадәр ләгънәт кылырлар».***

Шулай ук, башка мәгънә белән булган бу мәсьәләгә кагылышлы хәдисләр Мөслимдә дә килә.

Шулай итеп, әгәр дә ире хатынын якынлык кылырга чакыра икән, ул аңа риза булырга тиеш, чөнки су булмаган хәлдә тәяммум алып бу авырлыктан чыгарга мөмкин. Инде су салкын яки кайнар гына булып, чирләүдән сакланып, үзенең сәламәтлегенә зыян китерүдән курыкса, шулай ук тәяммум кылырга рөхсәт ителә.

(فَلَمْ تَجِدُوا مَاءً فَتَيَمَّمُوا صَعِيدًا طَيِّبًا) المائدة: ٦

Мәгънәсе: **«Су тапмасагыз, пакь җиргә сугып тәяммум кылыгыз».**

Инде госел коенырга су булмаганда хатын-кыз ире белән якынлык кылуны кире кага алмый икән, коенырга иренеп аның белән якынлык кылуны инкяр итүдә сүз дә булырга мөмкин түгел.

## Госел коенганда хатын-кыз чәч толымын сүтәргә тиешме?

عَنْ أُمِّ سَلَمَةَ قَالَتْ، قُلْتُ: «يَا رَسُولَ اللهِ إِنِّي امْرَأَةٌ أَشُدُّ ضَفْرَ رَأْسِي فَأَنْقُضُهُ لِغُسْلِ الْجَنَابَةِ» قَالَ: «لَا إِنَّمَا يَكْفِيكِ أَنْ تَحْثِي عَلَى رَأْسِكِ ثَلَاثَ حَثَيَاتٍ ثُمَّ تُفِيضِينَ عَلَيْكِ الْمَاءَ فَتَطْهُرِينَ» [ مسلم ٤٩٧ ]

Мәгънәсе: Үммү Сәләмә әйтте: *«Әй расүл Аллаһ! Мин чәч толымымны тыгыз итеп бәйлим, җөнеб госелен коенганда аны (толымны) чишимме?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Юк, хакыйкатьтә, сиңа баш өстеңә өч уч су сипсәң җитә, шуннан соң өстеңә су кой һәм шулай пакьләнәсең».***

Хәдистән аңлашылганча, хатын-кызга җөнеб госелен коенганда чәч толымын сүтү вәҗиб түгел, ләкин чәч төпләренә су тидерү кирәк. Шулай ук, күрем вакытыннан соң коенган госелдә дә аңа чәч толымын сүтү вәҗиб түгел. Имам Бохари “Сахих”ында (317нче хәдис) күрем вакытыннан соң госел коенганда хатын-кыз чәч толымын сүтәргә тиеш дигән бүлекне билгеләп узса да, әмма ошбу бүлектә китергән хәдис Гаишәнең хайдтан соң түгел, ә бәлки хайд килеш хаҗга госел коенуы хакында. Аллаһу әгъләм.

# Хатын-кыз хайд[1] вакытыннан соң госел коенганда хушбуй куллануы хакында

عَنْ عَائِشَةَ أَنَّ امْرَأَةً سَأَلَتْ النَّبِيَّ ﷺ عَنْ غُسْلِهَا مِنْ الْمَحِيضِ فَأَمَرَهَا كَيْفَ تَغْتَسِلُ قَالَ:» خُذِي فِرْصَةً مِنْ مَسْكٍ فَتَطَهَّرِي بِهَا»، قَالَتْ: كَيْفَ أَتَطَهَّرُ قَالَ: «تَطَهَّرِي بِهَا»، قَالَتْ: كَيْفَ قَالَ: «سُبْحَانَ اللهِ تَطَهَّرِي» فَاجْتَبَذْتُهَا إِلَيَّ فَقُلْتُ: «تَتَبَّعِي بِهَا أَثَرَ الدَّمِ» [ البخاري ٣١٤ ]

Мәгънәсе: Гаишәдән риваять ителә: *«Бер хатын-кыз пәйгамбәребездән ﷺ хайдтан (күремнән) соң госел коену хакында сорады. Пәйгамбәребез ﷺ аңа ничек коенырга кирәклеген аңлатып әйтте:* ***«Миск (хушбуй) белән хушбуйланган йон (яки мамык) кисәге ал һәм шуның белән пакьлән».*** *Ул хатын сорады: «Ничек соң мин аның белән пакьләныйм?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Шуның белән тазарын».*** *Ул хатын әйтте: «Ничек?». Пәйгамбәребез ﷺ гаҗәпләнеп әйтте:* ***«СөбхәнАллаһ! Пакьлән!».*** (Гаишә әйтте:) *Мин ул хатынны үземә тарттым һәм әйттем: «Кан эзе калган урыннарны шуның белән сөрт».*

Бу хакта, шулай ук, башка хәдисләр бар һәм галимнәрнең әйтүенчә, хатын-кыз күрем вакыты узып, госел коенып юынганнан соң, җенес әгъзасын мисклэнгән (хушбуйланган) бер кисәк чүпрәк белән сөртә. Бу сөннәтне хәзерге көндә күп кенә хатыннар белеп бетерми, Аллаһу мүстәган.

Моның хикмәтләрен билгеләп ән-Нәүәуий болай дип әйтеп узды:

**1) *Ул урынны хушбуйландыру андагы начар исләрне бетерә.***

**2) *Бала узуга тизләндерү сәбәбеннән була. Аллаһу әгъләм.***

---

1 Күрем (җенси яктан өлгергән хатын-кызларда аналыктан ай саен кан килү)

## Күремнән соң госел коенуның кыскача тәртибе

Башта таһәрат ала, шуннан соң авыз-борынын чайкый, аннары башына су кoя һәм чәч төпләренә су тисен өчен бармаклары белән ышкый, аннары үзенең өстенә су коя хәтта тәнендә коры урын калмаслык итеп, һәм соңыннан хушбуйланган бер кисәк чүпрәк яки шуңа охшаш әйбер алып кан эзе урынын (җенес әгъзасын) сөртә.

## Хатын-кызның җенес әгъзасыннан чыга торган канның төрләре

Хатын-кызның җенес әгъзасыннан чыга торган канның төрләре өчкә бүленә:

— Хайд (күрем) каны, (куе, кызыл-кара төстәге начар (сасы) исле, аналыктан чыга торган кан).

— Нифәс каны (бала тапканнан соң килә торган кан, ул шулай ук аналыктан килә).

— Истихада каны (гадәттә күрем вакытында булмыйча, аналыктан түгел, ә җенес әгъзасының төбеннән, тамырдан чыга торган сыек-кызыл төстәге, начар исле булмаган кан).

## Хайд (күрем) мәсьәләсе

**Хайдның мәгънәсе:**

Әл-Җүрҗәний үзенең “Тәгърифат” китабында хайдны аңлатып болай диде: *«Хайдның **тел сөйләмендәге** мәгънәсе «агу», «агып тору» дигәнне аңлата. **Шәргый атама мәгънәсе:** Яшь буенча кечкенә булмаган, бәлигъ вә авырулардан сәламат булган хатын-кызның аналыгыннан килә тор-*

*ган кан. Яше кечкенә кызның каны килсә, ул шәригатьтә хайдка саналмый. «Аналыктан» дип әйтү — истихаданы аера, чөнки истихада аналыктан чыкмый. «Сәламәт» дип әйтү — нифәсне аера, чөнки нифәс бала тапканнан соң авыру каны булып чыга».*

Ибн Манзур “Лисән әл-Гараб”тә болай диде: *«Хатын-кыз хайд булуы.... әгәр дә аннан билгеле көннәрдә кан акса».*

Ибен Хәҗәр “Фәтх әл-Бәрий”дә болай дип аңлатты: *«Хайд — хатын-кызның билгеле урыныннан, билгеле көннәрдә агып чыга торган каны».*

Әл-Җәхиз “Хайваннар” китабында: *«Тере булган җан ияләреннән дүртәүнең хайды була; хатын-кыз, куян, сыртлан һәм ярканат»,* — диде.

Ибен әл-Гарабий хайдның сигез исеме бар дип узды: *1- Хайд, 2- Гарик, 3- Фәрик, 4- Тамис, 5- Тамис (сакау-с-хәрефе белән), 6- Дәрис, 7- Кәбир, 8- Дахик.*

## Хайд, Аллаһның Адәм кызларына язган тәкъдире

عن عَائِشَةَ تَقُولُ: خَرَجْنَا لَا نَرَى إِلَّا الْحَجَّ فَلَمَّا كُنَّا بِسَرِفَ حِضْتُ فَدَخَلَ عَلَيَّ رَسُولُ اللهِ ﷺ وَأَنَا أَبْكِي قَالَ: «مَا لَكِ أَنُفِسْتِ؟» قُلْتُ: نَعَمْ قَالَ: «إِنَّ هَذَا أَمْرٌ كَتَبَهُ اللَّهُ عَلَى بَنَاتِ آدَمَ فَاقْضِي مَا يَقْضِي الْحَاجُّ غَيْرَ أَنْ لا تَطُوفِي بِالْبَيْتِ» قَالَتْ: وَضَحَّى رَسُولُ اللهِ ﷺ عَنْ نِسَائِهِ بِالْبَقَرِ [ البخاري ٢٩٤ ]

Мәгънәсе: Гаишә әйтте: *«Без хаҗ нияте белән чыктык, Сәрифкә[2] җиткәч, минем күрем башланды. Пәйгамбәребез ﷺ минем янга кергәч, елап утырганымны күреп сорады:* ***«Нәрсә булды сиңа? Синең хайд (күрем) башландымы?».*** *Мин әйттем: «Әйе». Шуннан соң ул әйтте:* ***«Хакыйкатьтә, бу — Аллаһ тәгаләнең Адәм кызларына язган тәкъдире, хаҗ кылучы эшли торган барча нәрсәләрне***

2 Мәккәнең төньягында 12 чакрым ераклыктагы урын

***дә эшлә, әмма ләкин Кәгъбә тирәли таваф кылма!».*** Әйтте (Гаишә): *«Пәйгамбәребез ﷺ барча хатыннары исеменнән сыер чалдыртты».*

Бу хәдистән аңлашылганча, хайдның беренче килеп чыгуы Адәм кызларыннан башланды. Ибен Хәҗәр “Фәтх әл-Бәрий”дә бу хакта ибен Габбастан ؓ болай дип әйтеп узды: *«Хайд беренче булып Хәва Җәннәттән җиргә төшерелгәч аңарда башланды».* Әйтте (ибен Хәҗәр): *«Әгәр дә шулай икән, Адәмнең кызлары алар Хәваның да кызлары. Аллаһу әгъләм».* Мустафа әл-Гадавий әйтте: *«Бу, хайдның беренче булып Адәм кызларында Хәва белән бергә башланган дигән фикерне генә куәтли».* Ә инде ибен Хәҗәрнең ибен Мәсгудтан: *«Бәнү Исраил кавемендә ирләр һәм хатыннар бергә намаз укыйлар иде, әмма хатын-кыз үзен ирләрдән өстен күрә иде, шуннан соң Аллаһ тәгалә аларга хайдны булдырып, аларны мәчеттән тыйды»,* — дигән сүзе, ул — хайдның беренче булып бәнү Исраил хатын-кызларында барлыкка килүе түгел, ә бәлки аларга гөнаһларына карата җәза булып, гадәттән тыш ешрак килә башлавын аңлата. Чөнки Аллаһ тәгалә Коръәндә туфан хакында ошбу ук мәгънәдә әйтте:

(فَأَرْسَلْنَا عَلَيْهِمُ الطُّوفَانَ وَالْجَرَادَ وَالْقُمَّلَ وَالضَّفَادِعَ وَالدَّمَ آيَاتٍ
مُفَصَّلاتٍ فَاسْتَكْبَرُوا وَكَانُوا قَوْمًا مُجْرِمِينَ) الأعراف: ١٣٣

Мәгънәсе: **«Аларга туфан, саранча, бет, бакаларны һәм кан җибәрдек, боларны аерым-аерым ачык галәмәтләр итеп җибәрдек. Бу галәмәтләрне күргән соңында да тәкәбберләнеп, азган кәфер кавеме булдылар».**

Аллаһ тәгалә бу аятьтә: **«Аларга (бәнү Исраил кавеменә) туфан җибәрдек»,** — дисә дә, ләкин алардан алда туфан Нух ؑ кавеменә җибәрелгән иде инде. Шулай булгач ибен Мәсгудтан ؓ риваять ителгән хайд хакында сүз югарыда аңлаткан мәгънәдә була. Аллаһу әгъләм.

## Ошбу аять белән бәйле кайбер мәсьәләләр

(وَيَسْأَلُونَكَ عَنِ الْمَحِيضِ قُلْ هُوَ أَذًى فَاعْتَزِلُوا النِّسَاءَ فِي الْمَحِيضِ وَلا تَقْرَبُوهُنَّ حَتَّى يَطْهُرْنَ فَإِذَا تَطَهَّرْنَ فَأْتُوهُنَّ مِنْ حَيْثُ أَمَرَكُمُ اللَّهُ إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ التَّوَّابِينَ وَيُحِبُّ الْمُتَطَهِّرِينَ) البقرة: ٢٢٢

Мәгънәсе: **«Янә синнән хатыннарның күрем каны хакында сорыйлар. Әйт: «Ул (күрем каны) иза чиктерә (азаплый, интектерә)», — дип. Күремле вакытларында, күремнәре бетеп пакьләнгәннәренә чаклы хатыннарыгыздан киселеп торыгыз (якынлашмагыз). Күремнәреннән пакьлансалар, Аллаһ әмер иткән урыннан якынлык кылыгыз. Дөреслектә, Аллаһ тәүбә итеп төзәлүчеләрне, һәм күңел вә тән нәҗесләреннән пакьләнүчеләрне сөя».**

***Аятьнең иңү (төшү) сәбәбе:***

وحَدَّثَنِي زُهَيْرُ بْنُ حَرْبٍ حَدَّثَنَا عَبْدُ الرَّحْمَنِ بْنُ مَهْدِيٍّ حَدَّثَنَا حَمَّادُ بْنُ سَلَمَةَ حَدَّثَنَا ثَابِتٌ عَنْ أَنَسٍ أَنَّ الْيَهُودَ كَانُوا إِذَا حَاضَتْ الْمَرْأَةُ فِيهِمْ لَمْ يُؤَاكِلُوهَا وَلَمْ يُجَامِعُوهُنَّ فِي الْبُيُوتِ فَسَأَلَ أَصْحَابُ النَّبِيِّ ﷺ النَّبِيَّ ﷺ فَأَنْزَلَ اللهُ تَعَالَى «وَيَسْأَلُونَكَ عَنْ الْمَحِيضِ قُلْ هُوَ أَذًى فَاعْتَزِلُوا النِّسَاءَ فِي الْمَحِيضِ» إِلَى آخِرِ الْآيَةِ فَقَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ «اصْنَعُوا كُلَّ شَيْءٍ إِلَّا النِّكَاحَ» فَبَلَغَ ذَلِكَ الْيَهُودَ فَقَالُوا مَا يُرِيدُ هَذَا الرَّجُلُ أَنْ يَدَعَ مِنْ أَمْرِنَا شَيْئًا إِلَّا خَالَفَنَا فِيهِ فَجَاءَ أُسَيْدُ بْنُ حُضَيْرٍ وَعَبَّادُ بْنُ بِشْرٍ فَقَالَا يَا رَسُولَ اللهِ إِنَّ الْيَهُودَ تَقُولُ كَذَا وَكَذَا فَلَا نُجَامِعُهُنَّ فَتَغَيَّرَ وَجْهُ رَسُولِ اللهِ ﷺ حَتَّى ظَنَنَّا أَنْ قَدْ وَجَدَ عَلَيْهِمَا فَخَرَجَا فَاسْتَقْبَلَهُمَا هَدِيَّةٌ مِنْ لَبَنٍ إِلَى النَّبِيِّ ﷺ فَأَرْسَلَ فِي آثَارِهِمَا فَسَقَاهُمَا فَعَرَفَا أَنْ لَمْ يَجِدْ عَلَيْهِمَا [ مسلم ٣٠٢ ]

Мәгънәсе: Әнәстән رضي الله عنه: *Яһүдләр, хатын-кызларының күрем вакыты җитсә, ул (хатын) алар белән бергә ашамый һәм алар да аның белән бергә ашамыйлар иде, шулай ук ул (күремле) хатынны үзләре белән бергә бер өйдә торгызмыйлар вә аның белән аралашмыйлар да иде. Сахәбәләр пәйгамбәребездән ﷺ бу хакта сорашкач, Аллаһ тәгалә ошбу аятьне индерде:*

(وَيَسْأَلُونَكَ عَنِ الْمَحِيضِ قُلْ هُوَ أَذًى فَاعْتَزِلُوا النِّسَاءَ فِي الْمَحِيضِ
وَلا تَقْرَبُوهُنَّ حَتَّى يَطْهُرْنَ فَإِذَا تَطَهَّرْنَ فَأْتُوهُنَّ مِنْ حَيْثُ أَمَرَكُمُ
اللَّهُ إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ التَّوَّابِينَ وَيُحِبُّ الْمُتَطَهِّرِينَ) البقرة: ٢٢٢

Мәгънәсе: **«Янә синнән хатыннарның күрем каны хакында сорыйлар. Әйт: «Ул (күрем каны) иза чиктерә (азаплый, интектерә)», — дип. Күремле вакытларында, күремнәре бетеп пакьләнгәннәренә чаклы хатыннарыгыздан киселеп торыгыз (якынлашмагыз). Күремнәреннән пакьлансалар, Аллаһ әмер иткән урыннан якынлык кылыгыз. Дөреслектә, Аллаһ тәүбә итеп төзәлүчеләрне, һәм күңел вә тән нәҗесләреннән пакьләнүчеләрне сөя».** *Һәм пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«(Хатыннарыгыз белән) якынлык кылудан башка, барча нәрсәне дә эшләгез».*** *Бу хәбәр яһүдләргә барып җитте һәм алар әйттеләр: «Бу кеше (ягъни пәйгамбәребез ﷺ) безнең бер эшебезгә дә кысылмыйча калырга теләми, кысыла икән, безгә гел тискәресен эшли». Шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ янына Үсәйд бин Худайр белән Габбәд бин Бишр килделәр һәм әйттеләр: «Йә Расүл Аллаһ! Чынлыкта, яһүдләр шулай-шулай дип әйтәләр, бәлки безгә (яһүдләргә тулысы белән кире булсын өчен) хатыннарыбыз белән якынлык та кылырга?». Бу сүзләрдән соң пәйгамбәребезнең ﷺ йөзе үзгәрде, хәтта без: «Расүлебез бу икесенә ачуланды», — дип уйладык. Алар чыгып киттеләр һәм каршыларына пәйгамбәребезгә ﷺ сөт бүләк итәргә кереп баручы (бер кеше) очрады. Расүлебез ﷺ ул кешене теге икесенең артыннан җибәрде һәм ул аларга сөт эчертте. Шунан соң алар пәйгамбәребезнең ﷺ аларга ачуланмаганын белделәр.*

### *Бу аятьтә «Әйт: Ул (күрем каны) иза чиктерә» — дигәннең мәгънәсе*

Әбү Бәкр әл-Җассас “Әхкәм әл-Куръән”дә моны аңлатып болай диде: «Ул (күрем каны) иза чиктерә — ягъни ул нәҗес һәм пычрак».

Әл-Куртубый тәфсирендә: «Әйт: Ул (күрем каны) иза чиктерә — ягъни ул шундый әйбер, хатын-кыз да аннан (күрем канынннан, исеннән) иза (авырлык, азап) күреп интегә һәм башкалар да...»

### ***Хайд хәлендә булган хатын-кыз белән якынлык кылуның хәрамлыгы***

Аллаһ тәгалә әйтте:

(فَاعْتَزِلُوا النِّسَاءَ فِي الْمَحِيضِ)

Мәгънәсе: **«Күремле вакытларында хатыннарыгыздан киселеп торыгыз».**

Шулай ук, бу хакта пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисен дә искә алып узган идек:

«اصْنَعُوا كُلَّ شَيْءٍ إِلا النِّكَاحَ»

Мәгънәсе: ***«(Хатыннарыгыз белән) якынлык кылудан башка, барча нәрсәне дә эшләгез».***

Күрем вакытында хатын-кыз белән якынлык кылу хәрам икәнлегендә галимнәр арасында бер каршылык та юк. Әл-Нәүәүий «Сахих Мөслим шәрхендә» болай дип әйтеп узды: *«Бел! Күремле хатын-кыз белән якынлык кылу берничәгә бүленә, шуларның берсе: хатынының җенес әгъзасына якынлык кылу, бу инде Коръәннән вә пәйгамбәребез ﷺ сөннәтеннән билгеле булганча, барча мөселман галимнәре да хәрам икәнлегенә килештеләр. Шәфигый галимнәре әйтте: «Әгәр дә мөселман кешесе, хатын-кыз күрем вакытында аның белән җенес әгъзасына якынлык кылуны хәләл кылса, ул мөртәд вә кәфер була. Ә инде әгәр кеше аның хәрам икәнлеген белеп, ләкин онытылып, яки күрем вакыты башланганын белмичә, яки хәрам икәнлеген белмичә эшләсә, ул вакытта аңа бер гөнаһ та юк. Ә кем инде хәрам икәнлеген вә хайд вакыты башланганын белә торып үз ихтияры белән эшләсә, ул вакытта ул кеше зур гөнаһ эшләгән була (чөнки Аллаһ*

*хәрам иткән гамәлне кыла). Һәм Шәфигый: ул кеше тәүбә итәргә тиеш — дип әйтеп узды».* Шушындый ук фикерне хәнәфиләрдән Мөхәммәд бин Габдулвахит бин әл-Һүмәм дә үзенең «Фәтх әл-Кадир» китабында әйтеп узды, һәм кем инде хәрам икәнлеген вә хайд вакыты башланганын белә торып үз ихтияры белән эшләсә, ул вакытта ул кеше зур гөнаһ эшләгән була, һәм ул кеше тәүбә итәргә тиешле вә бер динар кыйммәтлегендә садака бирү мөстәхәб була, дип өстәде.

## Хайд вакытында рөхсәт ителгән нәрсәләр хакында

Аллаһ тәгалә әйтте:

(فَاعْتَزِلُوا النِّسَاءَ فِي الْمَحِيضِ)

Мәгънәсе: **«Күремле вакытларында, хатыннарыгыздан киселеп торыгыз».**

Гыйлем әһелләре бу аятьне тәфсир кылып, өч төрле фикерне әйтеп уздылар. Шуларның икесе дөрес дип табылды. Ә инде өченчесе, ул шәз яки дөрес түгел фикер.

**1) <u>Киселеп торыгыз дигән сүзнең максаты, ул</u> — <u>хатыннарыгызның фәкать җенес әгъзасына якынлык кылмагыз, — дигәнне аңлата.</u>**

Бу фикерне әйтүчеләр, алар: Гаишә (бер риваятендә), ибен Кәсир тәфсирендә, әс-Сәүрий, Әхмәд, Исхак, Хәнәфиләрдән Мөхәммәд бин әл-Хәсән, әт-Тахауий, Мәлики мәзһәбенең һәм Шәфигыйларның бер риваяте, ибен әл-Мүнзир, ибен Хәзм һәм ән-Нәвәвий. Алар әйттеләр: «Ир кеше хатыны күрем вакытында, аның белән барча ысул белән дә ләззәтләнә ала, иллә-мәгәр хатынының җенес әгъзасына һәм арт ягына гына якынлык кылмый» — , диделәр. Ошбу сүзләренә түбәндәге дәлилләрне китерделәр:

«اصْنَعُوا كُلَّ شَيْءٍ إِلا النِّكَاحَ» [ مسلم ٣٠٢ ]

Мәгънәсе: ***«(Хатыннарыгыз белән) якынлык кылудан башка, барча нәрсәне дә эшләгез».***

حدثنا أيوب عن كتاب أبي قلابة أن مسروقا جاء إلى عائشة فقال: السلام على النبي و على أهل بيته، فقالت عائشة: أبو عائشة! مرحبا! فأذنوا له فدخل فقال: «إني أريد أن أسألك عن شيء و أنا أستحيى! فقالت: إنما أنا أمك، و أنت ابني! فقال: ما للرجل من امرأته و هي حائض؟ قالت: له كل شيء إلا فرجها» (صحيح)

Мәгънәсе: Мәсрук Гаишәгә ﵂ әйтте: *«Хакыйкатьтә, мин синнән бер нәрсә хакында сорыйсым килә, әмма ләкин мин оялам!».* Гаишә ﵂ әйтте: *«Сора, хакыйкатьтә, мин синең анаң! Ә син минем улым!».* (Чөнки пәйгамбәребезнең ﷺ хатыннары мөминнәрнең аналары дип атала, һәм аларга карата аерым хөкемнәр). Мәсрук әйтте: *«Әгәр дә хатыны күрем булса, ир кеше нәрсә эшли ала?».* Гаишә әйтте: *«Ул (ир) хатыны белән җенес әгъзасына якынлык кылудан башка, барча нәрсәне дә эшли ала».*

Бу фикердәгеләр ошбу һәм башка сахих хәдисләрдән чыгып болай әйттеләр: *«Гаишә бу мәсьәләдә иң яхшы белүче кеше, чөнки ул — пәйгамбәребезнең ﷺ хатыны...».*

**2) <u>Киселеп торыгыз дигән сүзнең максаты ул — хатыннарыгызның кендектән алып тезгә кадәр урыныннан, яки изар (кендектән аскы өлешкә ябыла торган кием) астыннан ераклашу, — дигәнне аңлата</u>.**

Бу фикерне әйтүчеләр, алар: Гаишә ﵂ (бер риваятендә), Мәймүнә ﵂ (пәйгамбәребезнең ﷺ хатыны), Гомәр, ибен Габбас, Сәгыйд бин әл-Мүсәйб, Шүрайх әл-Кадый, Әбү Хәнифә, Әбү Юсуф (Әбү Хәнифәнең шәкерте), Мәлики мәзһәбенең һәм Шәфигыйларның фикере. Һәм ошбу сүзләренә түбәндәге дәлилләрне китерделәр:

حَدَّثَنَا أَبُو النُّعْمَانِ قَالَ حَدَّثَنَا عَبْدُ الْوَاحِدِ قَالَ حَدَّثَنَا الشَّيْبَانِيُّ قَالَ حَدَّثَنَا عَبْدُ اللهِ بْنُ شَدَّادٍ قَالَ سَمِعْتُ مَيْمُونَةَ تَقُولُ: «كَانَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى الله عَلَيْهِ وَسَلَّمَ إِذَا أَرَادَ أَنْ يُبَاشِرَ امْرَأَةً مِنْ نِسَائِهِ أَمَرَهَا فَاتَّزَرَتْ وَهِيَ حَائِضٌ» [ البخاري ٣٠٣ ]

Мәгънәсе: Мәймүнә ﷺ (пәйгамбәребезнең ﷺ хатыны) әйтте: *«Әгәр дә пәйгамбәребез ﷺ хатыннарының берәрсен иркәлисе (назлыйсы) килсә, ул аңа изар (тәннең аскы өлешенә урый торган чүпрәк, шулай ук аны ихрамда вакытта ир-хаҗилар урый) кияргә куша иде, һәм (хатыны) хайд килеш изарлана иде».*

حَدَّثَنَا قَبِيصَةُ قَالَ حَدَّثَنَا سُفْيَانُ عَنْ مَنْصُورٍ عَنْ إِبْرَاهِيمَ عَنْ الأَسْوَدِ عَنْ عَائِشَةَ قَالَتْ: «كُنْتُ أَغْتَسِلُ أَنَا وَالنَّبِيُّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ مِنْ إِنَاءٍ وَاحِدٍ كِلاَنَا جُنُبٌ وَكَانَ يَأْمُرُنِي فَأَتَّزِرُ فَيُبَاشِرُنِي وَأَنَا حَائِضٌ» [ البخاري ٣٠٠ ]

Мәгънәсе: Гаишә ﷺ әйтте: *«Без пәйгамбәр ﷺ белән бергә, җөнеб вакытында, бер савыттан су алып госел коена идек, һәм ул миңа изар кияргә кушкач, мин изарлана идем, вә мин хайд килеш ул мине иркәли иде».*

Шушыңа охшаш хәдисләр Бохарида, Мөслимдә, ән-Нәсәидә вә Әбү Давыдта килә.

Ибен Җәрир әт-Табарий үзенең тәфсир китабында галимнәрнең ошбу мәсьәләгә кагылышлы барча фикерләрен дә бәян итеп узгач ошбу карашны куәтләде.

Мустафа әл-Гадавий бу ике карашны да бергә җыерга мөмкинлеген белдерде, һәм: *«Ир кеше хатыны белән җенес әгъзасына якынлык кылудан башка, барча нәрсәне дә эшли ала, әмма ләкин кендектән алып тезгә кадәр изар белән саклану аның өчен күпкә яхшырак вә хәерлерәк, Аллаһу әгъләм»,* — дигән фикерне әйтеп узды.

**3) <u>Киселеп торыгыз дигән сүзнең максаты ул — хатыннарыгызны иркәләүдән (назлаудан), тәннәренә кагылудан тулысы белән ераклашыгыз, яки бер ятакта йокласагыз да, ләкин бер юрган белән ябынмый аерым юрганнар белән ябынып ятарга, — дигәнне аңлата.</u>**

Бу фикерне әйтүчеләр, үзләренең сүзләрен ибен Габбаска ﷺ ялгасалар да, әмма ләкин бу сүз ибен Габбаска кагылмый, чөнки бу риваятьне тапшыручылар арасында зәгыйфьлекләре белән билгеле булган һәм сүзләре кабул

ителмәгән кешеләр бар. Шулай ук, галимнәр бу фикернең кабул түгеллеге хакында әйтеп уздылар.

## Әгәр мөселман китап әһеленә (яһүд яки насарага) өйләнсә, ул хатыны белән якынлык кылыр өчен, аны госел коенырга мәҗбүр итәргә тиешме?

Бу бездә, кәфер илендә яшәүчеләр арасында, бик тә көнүзәк мәсьәлә. Чөнки күп кенә Исламга кадәр өйләнгән мөселманнарның хатыннары урыс. Алар үзләре Исламны кабул итсә дә, хатыннары үзләренең диннәрендә кала бирәләр, Аллаһу мүстәган.

Галимнәр бу мәсьәләдә каршылыклы фикерләргә килделәр. Кемдер госелгә мәҗбүр ителә дисә, икенчеләре мәҗбүр ителми диделәр.

Әл-Куртубый үзенең тәфсирендә бу хакта болай диде: *«Ибен әл-Касим риваятендә Мәлик әйтте: «Әйе, хәтта иргә хатыны белән якынлык кылу хәләл булсын өчен (мәҗбүр ителә)».*

*Аллаһ тәгалә әйтте:*

(وَلا تَقْرَبُوهُنَّ حَتَّى يَطْهُرْنَ فَإِذَا تَطَهَّرْنَ) البقرة: ٢٢٢

Мәгънәсе: **«Күремле вакытларында, күремнәре бетеп, пакьланганнарына чаклы хатыннарыгыздан киселеп торыгыз (аларга якынлашмагыз). Күремнәреннән пакьләнсәләр...».**

*Яки су белән (пакьләнсәләр) — диде. Һәм мөслимә белән китап әһеленнән булган хатынны аерым билгеләмәде (шуңа да гомуми булып икесенә дә кагыла)».*

Әл-Куртубый дәвам итеп әйтте: *«Әшһәб Мәликтән риваять итүе буенча: Китап әһеленнән булган хатын-кыз госел коенуга мәҗбүр ителми, чөнки аның динендә вә игътикадында (инануында) (күремнән соң яки җөнеб булганнан соң) госел коену каралмаган. Аллаһ тәгалә Коръәндә ошбу аятьтә күрем һәм балага авырлы булу хакында мөэминә хатыннарына әйтте:*

(وَلا يَحِلُّ لَهُنَّ أَنْ يَكْتُمْنَ مَا خَلَقَ اللَّهُ فِي أَرْحَامِهِنَّ إِنْ
كُنَّ يُؤْمِنَّ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الآخِرِ) البقرة: ٢٢٨

Мәгънәсе: **«Хәләл булмас ул хатыннарга, Аллаһ халикъ кылган карыннарындагы баланы һәм күремне яшермәкләре, әгәр Аллаһка һәм ахирәт көненә ышансалар».**

*Шулай ук Аллаһ тәгалә диндә көчләү юк диде:*

(لَا إِكْرَاهَ فِي الدِّينِ) البقرة: ٢٥٦

Мәгънәсе: **«Диндә көчләү юк...».**

Шушы ук фикерне Мәхмүд бин Габдулхәкәм әйтте.

Мустафа әл-Гадавий: *«Миңа дөресрәк күренгәне, Аллаһу әгъләм, аятьтә әйтелгән:* **«Пакьләнгәннәренә чаклы хатыннарыгыздан киселеп торыгыз (якынлашмагыз)»,** *— дигән сүз, ул барча мөселман ирләргә кагыла (булсын аның хатыны мөслимә яки китап әһеленнән). Шуңа да, ир-ат хатыны госел коенып пакьләнгәнчегә кадәр, аның белән якынлык кылудан читләшергә тиеш, Аллаһу әгъләм».*

Шушындый ук фикерне ибен Кайим әл-Җәүзиийә үзенең «Әхкәм Әһлү әз-Зиммә» китабында: *«Әгәр дә ир үзенең хатынын госел коенырга мәҗбүр итә ала икән, мәҗбүр итәргә тырышырга тиеш, ә инде мәҗбүр итә алмаса — бер гөнаһ та юк»,* — дигән мәгънәдә әйтеп узды.

## Әгәр хатын-кыз хайд башланыр алдыннан сары яки болганчык сыекчаны күрсә, нишләргә тиеш?

Бу мәсьәләдә гыйлем әһелләре берничәгә бүленде:

Хәнәфи, Хәнбәли һәм Мәлики (мәшһүр карашы) мәзһәбләрендә, әгәр дә сары яки болганчык төстәге сыекча, гадәттә билгеле булган күрем вакыты көннәреннән алдарак килә икән, ул очракта күрем саналмый, һәм хатын-кыз намазларын шулай ук дәвам итә. Ә инде ул сыекча гадәттә билгеле булган күрем вакыты көннәрендә күренсә, ул очракта күрем дип санала. Моңа дәлил итеп алар Гаишәдән килгән ошбу риваятьне алдылар:

عَنْ عَلْقَمَةَ بْنِ أَبِي عَلْقَمَةَ عَنْ أُمِّهِ مَوْلَاةِ عَائِشَةَ أُمِّ الْمُؤْمِنِينَ أَنَّهَا قَالَتْ: «كَانَ النِّسَاءُ يَبْعَثْنَ إِلَى عَائِشَةَ أُمِّ الْمُؤْمِنِينَ بِالدِّرَجَةِ فِيهَا الْكُرْسُفُ فِيهِ الصُّفْرَةُ مِنْ دَمِ الْحَيْضَةِ يَسْأَلْنَهَا عَنْ الصَّلَاةِ فَتَقُولُ لَهُنَّ لَا تَعْجَلْنَ حَتَّى تَرَيْنَ الْقَصَّةَ الْبَيْضَاءَ تُرِيدُ بِذَلِكَ الطُّهْرَ مِنْ الْحَيْضَةِ» [ الموطاء، إسناده حسن ]

Мәгънәсе: Галкама бин Әбий Галкаманың әнисеннән, әйтте: *Хатын-кызларга (сары яки болганчык сыекча килгәндә) намаз укырга ярыймы әллә юкмы икәнен белер өчен, Гаишәдән сорарга дип, аңа бер төргәк эчендә хайд вакытында килгән канның сары төстәге сыекчасы буялган мамык җибәрделәр, ул аларга әйтте:* ***«Ак (пакь) әсәрен күргәнчегә кадәр (намаз уку белән) ашыкмагыз».***

Бу әсәрдән аңлашылганча, хайд вакытында килгән сары яки болганчык сыекча, ул хайд хөкеменә керә. Шулай ук, ак яки пакь әсәре дигәнен галимнәр болай аңлатып узды: *«Яки ул ак су (сидекнең охшашы), яки инде хатын-кыз җенес әгъзасына коры вә ак чүпрәк кертеп карый, әгәр дә ул коры яки ак су белән чыкса, хатын-кыз күремнән арынган була».*

Моңа тагын шулай ук башка дәлилләр китерделәр, без инде аларга тукталып тормыйбыз.

Хәнәфиләрдән булган Әбү Юсуф, әгәр дә сары яки болганчык сыекча хайд башланганчы күренсә, ул сыекча хайдка керми, ә инде хайд азагында күренсә — хайд була, диде.

Шәфигый мәзһәбендә мәшһүр булган караш — сары яки болганчык сыекча барсы да хайдка керә. Ә ибен Хәзм алар берсе дә хайдка керми дип әйтеп узды. Без инде беренче карашны (Хәнәфи, Хәнбәли мәзһәбләре һ.б.) дөрес дип уйлыйбыз, Аллаһу әгъләм.

## Хатын-кыз ифада (хаҗ) тавафын кылган булса, һәм соңыннан хайд башланса, аңа саубуллашу тавафы кирәк түгел

عَنْ عَائِشَةَ زَوْجِ النَّبِيِّ ﷺ أَنَّهَا قَالَتْ لِرَسُولِ اللهِ ﷺ: «يَا رَسُولَ اللهِ إِنَّ صَفِيَّةَ بِنْتَ حُيَيٍّ قَدْ حَاضَتْ» قَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «لَعَلَّهَا تَحْبِسُنَا أَلَمْ تَكُنْ طَافَتْ مَعَكُنَّ؟» فَقَالُوا: «بَلَى» قَالَ: «فَاخْرُجِي» [ البخاري ٣٢٨ ]

Мәгънәсе: Гаишә пәйгамбәребезгә ﷺ әйтте: *«Йә Расүл Аллаһ! Сафиянең (пәйгамбәребезнең хатыны) күрем вакыты башланды».* Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Шаять ул безне тоткарлар, ләкин ул сезнең белән таваф (ифада) кылмадымени?».*** Әйттеләр: *«Әйе, кылды».* Пәйгамбәребез ﷺ әйтте (Сафияга): ***«Алайса китсәң була».***

## Хайд вакытында хатын-кыз намаз укыймы һәм ураза тотамы?

Әһле-сүннә галимнәренең сәләфләре вә хәләфләре әйтүенчә, хатын-кызга хайд вакытында намаз уку һәм ураза тоту хәрам. Күрем вакыты узгач намазны каза кыл-

мый, әмма ләкин уразаны каза кылу фарыз. Намазны каза кылу мәсьәләсендә кайбер Хавариҗлар әһле-сүннәгә каршы килделәр, һәм намазны да каза кылу фарыз дип өстәделәр. Ләкин бу аларның адашуда икәнлекләренә тагын бер дәлил булып өстәлде.

Хатын-кыз күрем вакытында намаз да укымый, ураза да тотмый дигәненә, түбәндәге бер дәлилне генә китереп узарбыз. Ә кем инде бу мәсьәләдә гыйлемен арттырасы килсә хәдис вә фикх китапларына кайтсын.

عَنْ أَبِي سَعِيدٍ ﷺ قَالَ: قَالَ النَّبِيُّ ﷺ: «أَلَيْسَ إِذَا حَاضَتْ لَمْ تُصَلِّ وَلَمْ تَصُمْ؟ فَذَلِكَ نُقْصَانُ دِينِهَا» [ البخاري١٩٥١ ]

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә хатын-кызның күрем вакыты булса намаз укымый вә ураза тотмый түгелме? Менә шушы аның диненең кимчелеге».***

Күрем вакытында калган намазын каза кылмау хакында ошбу дәлил килә:

أَنَّ امْرَأَةً قَالَتْ لِعَائِشَةَ: أَتَجْزِي إِحْدَانَا صَلاتَهَا إِذَا طَهُرَتْ؟ فَقَالَتْ: «أَحَرُورِيَّةٌ أَنْتِ؟! كُنَّا نَحِيضُ مَعَ النَّبِيِّ ﷺ فَلَا يَأْمُرُنَا بِهِ» أَوْ قَالَتْ «فَلا نَفْعَلُهُ» [ البخاري٣٢١ ]

Мәгънәсе: Бер хатын Гаишәдән ﷺ сорады: *«Әгәр дә берәребез (күрем вакыты бетеп) пакьләнсә, калган намазларын каза кылырга тиешме?».* Гаишә әйтте: *«Син әллә Хәрурияме?*[3] *Пәйгамбәребез ﷺ вакытында безнең күрем була иде, әмма ләкин ул безгә каза кылырга кушмый торган иде, яки каза кылмый идек»,* — дип әйтте.

Ә инде уразаны каза кылу хакында ошбу дәлилне китерергә мөмкин:

عَنْ مُعَاذَةَ قَالَتْ: سَأَلْتُ عَائِشَةَ فَقُلْتُ: مَا بَالُ الْحَائِضِ تَقْضِي الصَّوْمَ وَلا تَقْضِي الصَّلاةَ؟ فَقَالَتْ: «أَحَرُورِيَّةٌ أَنْتِ؟» قُلْتُ: لَسْتُ بِحَرُورِيَّةٍ وَلَكِنِّي أَسْأَلُ. قَالَتْ: «كَانَ

3 Хәрура — Ирактагы Күфә шәһәреннән 4-5 км ераклыктагы авыл. Галидән аерылып чыккан беренче төркем дә шулардан. Алар Хавариҗларның беренче нигезен салучылар һәм Коръәнне генә кабул итеп, хәдисләрне инкяр итүчеләр булдылар. Шулай ук алар хатын-кызга күрем вакытында калдырган намазларын каза кылу фарыз дип әйттеләр

يُصِيبُنَا ذَلِكَ فَنُؤْمَرُ بِقَضَاءِ الصَّوْمِ وَلا نُؤْمَرُ بِقَضَاءِ الصَّلاةِ» [ مسلم ٣٣٥ ]

Мәгънәсе: Мүгәзә ﷺ әйтте: *«Мин Гаишәдән ﷺ сорадым: «Ни өчен хатын-кыз хайд вакытында калдырган уразасын каза кыла, ә намазын каза кылмый?». Гаишә әйтте: «Син әллә Хәруриямы?». Мин әйттем: «Юк, мин Хәрурия түгелмен, ләкин беләсем килеп сорыймын». Ул әйтте: «Безгә күрем ирешә иде, һәм уразаны каза кылырга дип боерылдык, ә намазны каза кылырга дип боерылмадык».*

## Әгәр дә ире хатынын күрем вакытында (җенес әгъзасына) якынлык кылырга чакырса?

Бел! Әгәр дә ире хатынын күрем вакытында (җенес әгъзасына) якынлык кылырга чакырса, хатыны аңа буйсынмаска тиеш. Чөнки Аллаһ тәгалә әйтте:

(فَاعْتَزِلُوا النِّسَاءَ فِي الْمَحِيضِ)

Мәгънәсе: **«Күремле вакытларында, хатыннарыгыздан киселеп торыгыз (якынлашмагыз)».**

Без моны аңлатып узган идек инде.

(وَلا تَعَاوَنُوا عَلَى الإِثْمِ وَالْعُدْوَانِ) المائدة: ٢

Мәгънәсе: **«Гөнаһлы эшләрдә һәм дошманлашуда яки золым эшләрендә һич тә ярдәмләшмәгез!».**

Пәйгамбәребез ﷺ хәдисләреннән:

عَنْ عَلِيٍّ أَنَّ رَسُولَ اللهِ ﷺ بَعَثَ جَيْشًا وَأَمَّرَ عَلَيْهِمْ رَجُلا فَأَوْقَدَ نَارًا وَقَالَ ادْخُلُوهَا فَأَرَادَ نَاسٌ أَنْ يَدْخُلُوهَا وَقَالَ الآخَرُونَ إِنَّا قَدْ فَرَرْنَا مِنْهَا فَذَكَرَ ذَلِكَ لِرَسُولِ اللهِ ﷺ فَقَالَ لِلَّذِينَ أَرَادُوا أَنْ يَدْخُلُوهَا لَوْ دَخَلْتُمُوهَا لَمْ تَزَالُوا فِيهَا إِلَى يَوْمِ الْقِيَامَةِ وَقَالَ لِلآخَرِينَ قَوْلا حَسَنًا وَقَالَ: «لا طَاعَةَ فِي مَعْصِيَةِ اللهِ إِنَّمَا الطَّاعَةُ فِي الْمَعْرُوفِ» [ مسلم ١٨٤٠ ]

Мәгънәсе (кыскача): Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«...Аллаһ тәгаләгә гөнаһ кылуда буйсыну юк! Буйсыну, изгелектә генә каралган».*** (озын хәдис)

Шулай ук моңа кагылышлы башка хәдисләр вә әсәрләр бар.

## Коръән китабын тотмыйча яки яттан, хайд яки җөнеб вакытында хатын-кызга Коръән укырга ярыймы?

Бу мәсьәләдә галимнәр өч мәшһүр карашка бүленделәр:

**Хатын-кыз хайд вакытында Коръәннән бернәрсә дә укымый.** Әйтелүенчә бу Гомәр, Гали вә Җәбир, Хәнәфи, Шәфигый, Хәнбәли мәзһәбләренең карашы. Шулай ук, моны Сүфиян әс-Сәүрий, әз-Зүһрий, Катәдә, ибен әл-Мүбәрәк һәм Исхак кебек билгеле булган тәбигыйннар әйтеп узды. Алар ошбу карашка хәдисләрдән вә әсәрләрдән дәлилләр китерделәр, әмма ләкин алар китергән хәдисләр зәгыйфь, иллә-мәгәр Исмәгыйль бин Гыйәштән килгән хәдистә генә каршылыклы фикерләр туды. Без ул дәлилләргә туктап тормыйбыз, ә кем инде бу караш та гыйлемен арттырасы килсә, Әбү Гомәр әд-Дүбйәннең «Мәүсуга әхкәм әт-Таһәра» китабына, яки Гомәр әл-Әшкарның «Мәсәил мин фикх әл-китәб вә әс-сүннә» китабына, яки башка хәдис вә фикх китапларына кайтсын.

**Хайдка да, җөнебкә дә укырга ярый** дигән карашны Бохари үзенең «Сахихында» әйтте, һәм анда ук ул Ибраһим ән-Нәхәгыйнең вә ибен Габбаснең рөхсәт иткән карашларын әйтеп узды. Шулай ук, моны Сәгыйд бин әл-Мүсәйб, Дауыд әз-Заһирий, әт-Табарий, ибен әл-Мүнзир, әл-Кадый Әбү әт-Таийб вә ибен әс-Сыйбагъ кебек гыйлем әһелләре хуплады.

**Җөнеб хәлендә булганнарга ярамыйча, хайд хәлендә булганнарга рөхсәт ителә** дип имам Мәлик вә ибен Тәймия әйтеп уздылар. Дәлилләрен әйтеп узгач, моның берничә сәбәбен әйттеләр һәм шуларның берсе: Җөнеб кеше кайсы вакытта да госел коена ала, ә күрем хәлендә булган хатын-кыз вакыты узмыйча госел коена алмый, шуңа да ятлаганын онытмас өчен яки Коръәннән аерылмас өчен аңа рөхсәт ителә диделәр. Бу карашны Гомәр әл-Әшкар «Мәсәил мин фикх әл-китәб вә әс-сүннә» китабында дөресрәк дип тапты. Аллаһу әгъләм.

## Хайд хәлендә хатын-кызга яки таһәратсез булган кешегә Коръән тотса ярыймы?

Бу мәсьәләдә гыйлем әһелләренең карашлары:

– **Әбү Хәнифә, Мәлик, Шәфигый, Әхмәд, ибен Тәймия хатын-кызга күрем хәлендә, яки таһәратсез кешегә Коръәнне тотырга ярамый (яки хәрам) дигән фикерне әйттеләр.** Ибен Тәймия шулай ук бу карашны Сәлмән әл-Фәрисий, Габдуллаһ бин Гомәр һәм башкаларныкы дип әйтеп узды, һәм аларның карашы бу мәсьәләдә барча сахәбәләрнеке белән дә туры килә диде. Ярамый диючеләрнең кайбер дәлилләрен әйтеп узабыз:

(لا يَمَسُّهُ إِلا الْمُطَهَّرُونَ) الواقعة: ٧٩

Мәгънәсе: **«Аны пакь булмаган тотмас, мәгәр пакьләр генә тотар».**

Ләкин, бу аять белән дәлилләнү дөрес булмас, чөнки **«мәгәр пакьләр генә тотар»** дигән сүзнең максатында өч караш бәян булды. Кемнәрдер таһәратне вә госелне боза торган кечкенә һәм зур хәдәсләрдән пакь (чиста) булганнар дисә, икенчеләре ширек һәм көфердән пакь булган мөэминнәр турында әйтелде дип уздылар. Шулай ук, **«аны**

**тотмас»** дигән сүзнең мәгънәсендә алар үзләре үк капма-каршы фикерләргә килделәр. Әмма күпчелек гыйлем әһелләре моның максаты Коръәнгә түгел, бәлки Ләүхүл-Мәхфузга кайта диделәр. Һәм шуннан чыгып **«пакьләр генә тота»** дигән сүзнең максаты өченче карашны, яки Аллаһ тәгалә барча пычрактан пакь вә саф кылган фәрештәләр, дигәнне куәтли булып чыкты. Аллаһу әгъләм.

Шулай ук, үзләренең карашларына алар пәйгамбәребезнең ﷺ Гамр бин әл-Хәзмга язган хәдисе белән дәлил китерделәр:

حَدَّثَنِي يَحْيَى عَنْ مَالِك عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ أَبِي بَكْرِ بْنِ حَزْمٍ أَنَّ فِي الْكِتَابِ الَّذِي كَتَبَهُ رَسُولُ اللهِ ﷺ لِعَمْرِو بْنِ حَزْمٍ أَنْ لَا يَمَسَّ الْقُرْآنَ إِلَّا طَاهِرٌ

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ Гамр бин әл-Хәзмга язып җибәрде: ***«Коръәнне пакь булган гына тотар».***

Әхмәд Шәкир бу язуны тулысы белән Хәкимнең «әл-Мүстәдрәк» җыентыгында таптым диде. Һәм өстәп: *«Аның иснәде сахих икәнлеге ачыктан-ачык бәян булды»,* — диде. Шулай ук, әл-Әлбәний «Ирүә әл-Галил»дә моны тикшереп узганнан соң: *«Бу хәдиснең дөреслегенә җан тынычлана»,* — диде. Инде, әгәр дә бу хәдистә **«пакь булган гына тота»** дигәннең максаты, таһәратлеләргә вә госелллеләргә кайта икән дип алынса, ул вакытта хайд, җөнеб хәлендә яки таһәратсез килеш Коръәнне тотырга ярамый дигән караш өстен чыга. Аллаһу әгъләм.

**– Давыд әз-Заһирий, ибен Хәзм һәм аларның карашларын алучылар таһәратсез яки госелсез булган кешегә Коръәнне тотырга рөхсәт ителә диделәр**. Һәм алар Бохарида ибен Габбастан килгән пәйгамбәребезнең ﷺ Рум патшасы Һиракылга җибәргән Коръән аяте белән булган хатын дәлил итеп китерделәр. Чөнки Һиракыл кәфер булуына карамастан, пәйгамбәребез ﷺ аңа әли-Гыймран сүрәсенең 64 аяте язылган хатны җибәрде. Ярамый дип әйтүчеләр инде моңа: «Ул хат иде, һәм анда бер аять булуы аны Коръән мусхафы хөкеменә кертми, чөнки бер аять булган хатны гына түгел, бәлки тәфсир вә фикх китапла-

рын да таһәратсез яки госелсез тотырга ярый», — диделәр. Шулай ук, имам Әхмәд бин Хәнбәл моңа өстәп: *«Тәблигъ яки дагъват файдасы өчен мондый язулар рөхсәт ителә»,* — дип әйтеп узды. Аллаһу әгъләм.

**– Хайд вә җөнеб вакытында ярамыйча, кечкенә таһәратсез булганда рөхсәт ителә диючеләр.** Бу карашны әш-Шәүкәний әйтте, һәм үзенең карашын ибен Габбас, әш-Шәгъбий, әд-Даххәк, Зәйд бин Гали, Әбү Хәнифәнең остазы Хәммәд бин Әбий Сөләймәнгә һәм башкаларга юллады.

## Йөкле (балага узган) хатын-кызның күреме буламы?

Бу мәсьәләдә гыйлем әһелләре ике карашка бүленделәр:

**1)** Хәнәфи, Хәнбәли һәм Шәфигыйнең бер риваяте буенча (кадимдә), йөкле хатын-кызның күреме булмый. Әгәр дә йөкле вакытында кан килә икән, ул күрем каны түгел, бәлки бозылган начар кан чыга, яки инде баланың төшүе була. Бу карашны әйтүчеләр түбәндәге дәлилне китерделәр:

عَنْ أَبِي سَعِيدٍ الْخُدْرِيِّ وَرَفَعَهُ أَنَّهُ قَالَ فِي سَبَايَا أَوْطَاسَ: «لا تُوطَأُ حَامِلٌ حَتَّى تَضَعَ وَلا غَيْرُ ذَاتِ حَمْلٍ حَتَّى تَحِيضَ حَيْضَةً» [ أبو داود ٢١٥٧، تحقيق الألباني صحيح: ]

Мәгънәсе: Әбү Сәгыйд әл-Худрийдән, пәйгамбәребез ﷺ сәбиләр[4] хакында әйтте: ***«Йөкле хатын-кызлар бала тапканчыга кадәр һәм йөкле булмаганнар бер күрем вакыты узмыйча якынлык кылынмыйлар».***

Чөнки, хатын-кызның аналыгының пакьләнүе (йөкле түгел икәненең билгесе) ул күрем килүе, әгәр дә йөкле хатын-кызның күреме була икән, ул вакытта аның аналы-

4 Сугышта әсирлеккә алынган хатын-кызлар

гының пакь булуы беленми. Һәм бу караш әһелләре шулай ук башка дәлилләр китерделәр. Мустафа әл-Гадавий шулай ук бу карашны хуплады, әмма ләкин күрем каныны яки түгелме икәнлеге гореф-гадәт белән беленә диде. Әгәр дә төсендә, исендә күрем каны сыйфаты булса — бу күрем, ә инде төсе вә исенең сыйфатлары башка икән — бу күрем түгел, дип әйтеп узды. Бу мәсьәлә хакында Гомәр әл-Әшкар карамагында Яхъя әл-Хатыйбның "Әхкәм әл-Марәа әл-Хәмил" дигән бик яхшы китабы бар, һәм ул анда бу мәсьәләдә белгечләр булган табиблар белән тикшеренүләр кылганнан соң, йөкле хатын-кызның күреме килми, ә ул вакытта килгән кан башка сәбәп белән чыккан кан, дигән карашны дөрес дип таба. Һәм без дә бу карашны яхшырак вә дөресрәк дип кабул итәбез. Аллаһу әгъләм.

**2)** Мәлики вә Шәфигый (Шәфигыйның яңасында) мәзһәбләре, йөкле хатын-кызның күреме була дигән карашны алдылар. Алар шулай ук бу карашка дәлилләр китерделәр, әмма ләкин без аларга туктап тормыйбыз.

## Истихада мәсьәләсе

**Истихаданың мәгънәсе:**

Ибен Манзур "Лисән әл-Гараб"тә истихаданың **тел сөйләмендәге мәгънәсен** аңлатып болай диде: *«Истихада — хатын-кызның гадәти билгеле булган күрем вакыты узганнан соң агып тора торган каны».* **Шәргый мәгънәсен** Хәнәфиләрдән әл-Җүрҗәний болай дип аңлатты: *«Хатын-кызда өч көннән азрак һәм ун көннән күбрәк күренгән кан»*[5]. Мәликиләр "әл-Мукаддимәт"тә истихаданы болай дип аңлаттылар: *«Хайд һәм нифәс каны вакытыннан артып киткән, чир каны».* Шәфигыйләрнең "Мугъний әл-Мухтәҗ"дә аңлатмасы болай: *«Истихада, ул — чир каны, һәм ул күремнең соңындамы яки башка вакыттамы*

5 Чөнки хәнәфиләрдә күрем вакыты өч көннән алып ун көнгә кадәр, ә инде өч көнгә җитмәсә яки ун көннән артып китсә, ул истихада була

*аналыкның иң төбеннән, тамырдан чыга. Шулай ук аңа “әл-газил” — дип тә әйтелә».* Хәнбәлиләр “Кәшшәф әл-Каннәгъ”та мондый төшенчә бирделәр: *«Гадәттә билгеле булмаган вакытында, чир белән бәйле булган аналыкның иң төбеннән, тамырдан агып чыгучы кан».*

*«Чир белән бәйләнгән»* — дигәннең мәгънәсе — ул, күрем каны кебек түгел, чөнки күрем каны ул сәламәт хатын-кызның бәлигъ булуын аңлата торган аналыктан айлык агып чыгучы табигый кан.

Шулай ук, гыйлем әһелләре **истихада белән күрем канының кайбер аермаларын** әйтеп уздылар:

**1)** Төсе. Күрем каны кара-кызыл төстә, ә истихада каны сарыракка охшаган кызыл төстә.

**2)** Исе. Күрем каны сасы исле, ә инде истихада канының андый сасы исе юк.

**3)** Күрем каны куе, ә истихада каны сыек.

**4)** Күрем каны оемый, ә истихада каны оеша, чөнки ул кан тамырыннан чыга. Аллаһу әгъләм.

حَدَّثَنَا مُحَمَّدٌ هُوَ ابْنُ سَلَام قَالَ حَدَّثَنَا أَبُو مُعَاوِيَةَ حَدَّثَنَا هِشَامُ بْنُ عُرْوَةَ عَنْ أَبِيهِ عَنْ عَائِشَةَ قَالَتْ: جَاءَتْ فَاطِمَةُ بِنْتُ أَبِي حُبَيْشٍ إِلَى النَّبِيِّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فَقَالَتْ: «يَا رَسُولَ اللهِ إِنِّي امْرَأَةٌ أُسْتَحَاضُ فَلَا أَطْهُرُ أَفَأَدَعُ الصَّلَاةَ؟» فَقَالَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: «لَا إِنَّمَا ذَلِكِ عِرْقٌ وَلَيْسَ بِحَيْضٍ فَإِذَا أَقْبَلَتْ حَيْضَتُكِ فَدَعِي الصَّلَاةَ وَإِذَا أَدْبَرَتْ فَاغْسِلِي عَنْكِ الدَّمَ ثُمَّ صَلِّي» قَالَ: وَقَالَ أَبِي: «ثُمَّ تَوَضَّئِي لِكُلِّ صَلَاةٍ حَتَّى يَجِيءَ ذَلِكَ الْوَقْتُ» [ البخاري ٢٢٨ ]

Мәгънәсе: Һишәм бин Гур’уа ﵁ әтисеннән, Гаишәдән риваять кылды, Гаишә ﵂ әйтте: *«Фатыйма бинт Әбий Хубәйш ﵂ пәйгамбәребез ﷺ янына килде һәм әйтте: Йә Расүл Аллаһ! Мин каны туктамый торган хатын-кыз (истихада), һәм берничек тә пакьләнә алмыйм. Миңа намаз укуны калдырыргамы әллә? Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: **«Юк, Чөнки ул күрем түгел, ә кан тамырыннан килә торган кан. Әгәр дә (гадәттә билгеле булган) күрем вакытың җитсә, намазны калдыр. Ә инде күрем вакытың узса, госел коен һәм***

***намаз укы».*** Әйтте (Һишәм): әтием әйтте (Гур'уа бин әз-Зүбәйр): *«Шуннан соң (икенче) күрем вакыты җиткәнчегә кадәр, һәрбер намазга таһәратлән».*

Бу инде әгәр дә истихада булган хатын-кыз үзенең күрем вакытын белә торган булса, госел коена һәм намаз укый. Ә инде әгәр дә хатын-кыз үзенең күрем вакытын белмәсә, ләкин күрем канын истихада каныннан төсе вә исе һәм башка сыйфатларын аера ала торган булса, ул вакытта күремне истихададан шулай аерып гамәл итә. Болар барсы да элек күрем күреп, вакытын белгән яки күрем канының сыйфатларын белгән хатын-кыз хакында. Әмма инде әгәр дә хатын-кызның иң беренче күрем каны килгән чакта истихада каны белән дәвам итсә, ул вакытта, әгәр ул күремнең сыйфатын белә торган булса, шуның буенча гамәл итә, яки хайд канының төсе яки исе үзгәреп истихада башланганын белә икән, госел коенып намаз укый башлый. Ә инде беренче күреме башланып, шулай ук истихада белән дәвам итсә, һәм ул хатын-кыз күремнең сыйфатын белми торган булса, ул вакытта инде ул башка хатыннар күременең гадәттә булган көннәрен исәпкә алып эш итә. Мәсәлән, аның тирә янында булган хатыннарның гадәттә булган күрем көннәре алты яки җиде көн икән, ул да шушы алты яки җиде көнне күздә тотып эш итә. Аллаһу әгъләм.

Әйткәнебезчә, Әбү Хәнифә мәзһәбендә күрем өч көннән алып ун көнгә кадәр. Аннан узып китсә, истихада була, һәм хатын-кыз госел коенып һәр намазга таһәрат алып намазларын дәвам итә. Һәр намазга таһәрат алу вәҗиб (фарыз) дигәнне шулай ук Хәнбәлиләр әйтте. Шәфигыйләр бу мәсьәләдә, истихада булган хатын-кызга фарыз намазларына таһәрат алу вәҗиб (фарыз), ә инде нәфел намазларын фарызга алган таһәрат белән укый, дигән караашта булдылар. Мәликиләр бу мәсьәләдә истихада каны таһәратне бозмый, шуңа да ул кан чыкканга гына һәрбер намазга таһәрат алу фарыз түгел, бәлки мөстәхәб диделәр.

## Истихада булган хатын-кызның мәчеттә игътикәф кылуы?

Хатын-кызга мәчеттә игътикәф кылырга яраганлыгы хакында гыйлем әһелләре арасында каршылык юк. Чөнки пәйгамбәребез ﷺ вакытында да, аннан соң да хатын-кызлар мәчеттә игътикәф кылалар иде. Бу мәсьәләгә кагылышлы хәдисләрне «Ураза» китабының «Игътикәф» бүлегендә әйтеп узарбыз, иншәАллаһ. Ә инде истихада булган хатын-кызның мәчеттә игътикәф кылуы хакында ошбу дәлилне китереп узарбыз:

عَنْ عَائِشَةَ قَالَتْ: «اعْتَكَفَتْ مَعَ رَسُولِ اللهِ ﷺ امْرَأَةٌ مِنْ أَزْوَاجِهِ فَكَانَتْ تَرَى الدَّمَ وَالصُّفْرَةَ وَالطَّسْتُ تَحْتَهَا وَهِيَ تُصَلِّي» [ البخاري ٣١٠ ]

Мәгънәсе: Гаишә ﵂ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ белән хатыннарының берсе игътикәф кылганда истихада канын күргәч, үзенең астына тас куя иде, һәм намаз укый иде».***

Шулай ук, истихада булган хатын-кызга ире белән якынлык кылырга, ураза тотарга, Коръәнне кулына алып укырга һәм башка барча гыйбадәтләрне кылырга рөхсәт ителә. Чөнки ул истихада хәлендә таза вә пакь хатын-кызлар хөкемендә.

## Нифәс мәсьәләсе

**Нифәснең мәгънәсе:**

Нифәснең **тел сөйләмендәге мәгънәсе** “Тәҗ әл-Гурус”-та: *«Хатын-кызның бала табуы»,* — дип аңлатылды. “Әл-Мисбах әл-Мунир”да: *«Ул нәфс дигән сүздән алынган, ягъни кан дигән мәгънәдә»,* — диелде.

**Шәргый мәгънәсен** Хәнәфиләр: *«Бала тапканнан соң җенес әгъзадан килә торган кан, һәм иң күбе кырык көн»,* — дип аңлаттылар. Мәликиләр нифәсне аңлатып: *«Бала тапканда һәм аннан соң килә торган кан»,* — диделәр.

Шәфигыйләр болай дип аңлаттылар: *«Нифәс — ул, аналык бала йөгеннән бушаганнан соң килә торган кан».* Хәнбәлиләр моңа мондый төшенчә бирделәр: *«Бала тапканда аналыктан чыга торган кан, һәм ул кырык көнгә кадәр сузыла. Шулай ук, бала тапканчы галәмәтләре (сыйфатлары) туры килсә, ике-өч көн алдан да чыгарга мөмкин»,* — диделәр.

Нифәс булган хатын-кызның хөкемнәре хәләлдә дә хәрамда да, мәкруһта да мәндубтә дә, күремле хатын-кызныкы кебек үк. Һәм аның иң күп вакыты кырык көн булганлыгына күпчелек гыйлем әһелләре килеште, вә «Сүнән әл-Дәримий»дә сахих сәнәд белән килгән ибен Габбастан булган әсәрне китерделәр. Ибен Габбас ﵁ әйтте: ***«Нифәс булган хатын-кыз кырык көн, яки шул чама көтә»,*** — диде. Ә инде иң аз вакытын билгеләүдә бер дәлил дә билгеле түгел, шуңа да кайчан аның нифәс каны кырык көнгә кадәрле туктаса, шул вакытта госел коена һәм таза вә пакь хатын-кыз хөкеменә керә.

# НАМАЗ
# китабы

## Пәйгамбәребез ﷺ вакытында мәчеттә хатын-кызларның җәмәгать намазында булуы хакында

حَدَّثَنَا أَبُو الْيَمَانِ قَالَ أَخْبَرَنَا شُعَيْبٌ عَنِ الزُّهْرِيِّ قَالَ أَخْبَرَنِي عُرْوَةُ أَنَّ عَائِشَةَ قَالَتْ: «لَقَدْ كَانَ رَسُولُ اللهِ ﷺ يُصَلِّي الْفَجْرَ فَيَشْهَدُ مَعَهُ نِسَاءٌ مِنَ الْمُؤْمِنَاتِ مُتَلَفِّعَاتٍ فِي مُرُوطِهِنَّ ثُمَّ يَرْجِعْنَ إِلَى بُيُوتِهِنَّ مَا يَعْرِفُهُنَّ أَحَدٌ» [ البخاري ٣٧٢ ]

Мәгънәсе: Гаишә ﵂ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ иртәнге намазны укыганда, аның белән шулай ук мөэминә хатын-кызлар үзләренең киемнәренә төренеп укыйлар, һәм шуннан соң өйләренә кайтып китәләр иде, вә аларны беркем дә таный алмый иде».***

Бу хәдистә күренгәнчә, хатын-кызлар ирләр белән бергә мәчеттә җәмәгать булып намаз укый алалар, һәм намаз беткәч тә ир-атлар белән буталу булмасын өчен, мәчеттән тиз генә чыгып өйләренә юнәләләр. Хатын-кызлар намазны укыгач, тиз рәвештә мәчеттән чыгып китүләре хакында имам Бохари үзенең «Сахихында» аерым бүлек билгеләде. Хатын-кызларның мәчеттә намаз укуы хакында шулай ук башка хәдисләр бар, без инде аларның барсына да тукталып тормыйбыз.

## Хатын-кызларга мәчеткә барырга рөхсәт итү хакында

Без инде бу мәсьәләгә кагылышлы барча хәдискә дә кагылмыйча, берничәсен генә әйтеп узарбыз.

حَدَّثَنَا عَلِيُّ بْنُ عَبْدِ اللهِ حَدَّثَنَا سُفْيَانُ حَدَّثَنَا الزُّهْرِيُّ عَنْ سَالِمٍ عَنْ أَبِيهِ عَنِ النَّبِيِّ ﷺ: «إِذَا اسْتَأْذَنَتْ امْرَأَةُ أَحَدِكُمْ إِلَى الْمَسْجِدِ فَلَا يَمْنَعْهَا» [ البخاري ٥٢٣٨ ]

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәрегездән хатын-кызы мәчеткә барырга рөхсәт сораса, аны тыймагыз».***

عَنْ عَبْدِ اللهِ ابْنِ عُمَرَ أَنَّ رَسُولَ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ قَالَ: «لَا تَمْنَعُوا إِمَاءَ اللهِ مَسَاجِدَ اللهِ» [ مسلم ٤٤٢ ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гомәрдән ﵁ риваять ителүенчә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хатын-кызларны Аллаһның мәчет-ләреннән тыймагыз!».***

Бу хәдистә аңлашылганча, хатын-кызларны мәчеткә намаз укырга барудан тыю дөрес булмас. Ләкин башка хәдисләрдә килгән һәм гыйлем әһелләре билгеләп узган шартлар белән: Хатын-кыз хушбуйланган, бизәнгән булмаска, шулай ук җәлеп итәрлек матур киемнәр һәм биек үкчәле аяк киеме киеп йөрешендә яки тавышында фетнә күренмәскә тиеш. Әгәр дә, хатын-кыз мәчеткә барганда-кайтканда яки мәчеттә вакытта чит ирләр белән оятсыз рәвештә аралаша икән, яки намаз беткәч, үзләренә билгеле булган бүлмәдә зикер кылу урынына җыелышып гайбәтләр сөйләшә икән, ул вакытта савап урынына гөнаһ кына җыя. Шуңа да, алда әйткәнебезчә, хатын-кыз җәмәгать намазы бетү белән кайтырга ашыгырга тиеш, Аллаһу әгъләм.

## Хатын-кыз мәчеткә барганда хушбуй кулланмавы хакында

عَنْ زَيْنَبَ امْرَأَةِ عَبْدِ اللّٰهِ قَالَتْ: قَالَ لَنَا رَسُولُ اللهِ ﷺ: «إِذَا شَهِدَتْ إِحْدَاكُنَّ الْمَسْجِدَ فَلا تَمَسَّ طِيبًا» [ مسلم ٤٤٣ ]

Мәгънәсе: Зәйнәб (әл-Сакафия) ﵂ әйтте: *«Безгә пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Әгәр дә берәрегезнең (хатын-кызларның) мәчеткә барасы килсә, хушбуй кулланмасын».***

Әгәр дә хатын-кыз шушыны белә торып, хушбуйланып мәчеткә барса, ул инде үзенә зур гөнаһ ала. Чөнки пәйгамәребез ﷺ аңа мәчеткә барганда хушбуйланмаска кушты, ә ул (хатын) инде: «Юк, йә Расүл Аллаһ! Мин син әйткәнчә эшләмим, сиңа киресен эшлим», — дигән кебек, пәйгамбәребезгә ﷺ карата тәкәбберлек белдерде, Аллаһ сакласын. Әбү Мөхәммәд бин Хәзм бу хакта «әл-Мүхәллә» китабында болай дип әйтеп узды: *«Хатын-кыз мәчеткә барганда хушбуй куллану аңа хәләл булмас, ә инде хушбуйланган килеш мәчеткә барып намаз укыса, намазы батыл була (яки дөрес булмый)».* Әлбәттә инде намазы батыл була дигәнне башка галимнәр тәнкыйтьләп узды. Чөнки хушбуйланып мәчеткә барганы өчен, гөнаһы аерым, намаз белән бәйле түгел, диделәр, Аллаһу әгъләм. Бу хакта шулай ук Әбү Һүрайрадан ؓ риваять ителгән ошбу хәдистә килде:

عن أبي هريرة ﷺ عن النبي ﷺ أنه فال: «لا يقبل الله من امرأة صلاة خرجت إلى المسجد و ريحها تعصف حتى تغتسل غسلها من الجنابة»

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ؓ, Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә хатын-кыз мәчеткә барырга чыкса һәм аннан көчле (хушбуй) исе килеп торса, җөнеб госеле коенып пакьләнгәнчегә кадәр Аллаһ тәгаләә аның намазын кабул итми».***

Бу хәдиснең дөреслегендә каршылыклы фикерләр бар, шуңа карамастан шәйх әл-Әлбәний “Сахих әт-Тәргыйб үә әт-Тәрһийб”тә искә алды. Аллаһу әгъләм.

## Пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисен кабул итмәгән кешегә нәфрәт белдерү хакында

حَدَّثَنِي حَرْمَلَةُ بْنُ يَحْيَى أَخْبَرَنَا ابْنُ وَهْبٍ أَخْبَرَنِي يُونُسُ عَنْ ابْنِ شِهَابٍ قَالَ أَخْبَرَنِي سَالِمُ بْنُ عَبْدِ اللهِ أَنَّ عَبْدَ اللهِ بْنَ عُمَرَ قَالَ: سَمِعْتُ رَسُولَ اللهِ ﷺ يَقُولُ:

«لا تَمْنَعُوا نِسَاءَكُمْ الْمَسَاجِدَ إِذَا اسْتَأْذَنَّكُمْ إِلَيْهَا» قَالَ: فَقَالَ بِلالُ بْنُ عَبْدِ اللهِ: وَاللهِ لَنَمْنَعُهُنَّ، قَالَ: فَأَقْبَلَ عَلَيْهِ عَبْدُ اللهِ فَسَبَّهُ سَبًّا سَيِّئًا مَا سَمِعْتُهُ سَبَّهُ مِثْلَهُ قَطُّ وَقَالَ: «أُخْبِرُكَ عَنْ رَسُولِ اللهِ ﷺ وَتَقُولُ وَاللهِ لَنَمْنَعُهُنَّ» [ مسلم ٤٤٢ ]

Мәгънәсе: Сәлим бин Габдуллаһ риваять итүенчә Габдуллаһ бин Гомәр ﷺ әйтте: *«Мин пәйгамбәребездән ﷺ ишеттем, ул әйтте:* ***«Әгәр дә берәрегездән хатын-кызы мәчеткә барырга рөхсәт сораса, аны тыймагыз».*** *Биләл бин Габдуллаһ (Габдуллаһ бин Гомәрнең малае) әйтте: «ҮәАллаһи, без аларны тыячакбыз!» Әйтте (Сәлим бин Габдуллаһ): Габдуллаһ бин Гомәр (бу сүзләрне ишетеп) аның каршына килде һәм аны мин беркайчан да ишетмәгән бик каты сүгү белән тиргәде, вә шуннан соң әйтте: «Мин сиңа расүлебезнең хәдисен әйтәм, ә син шуңа каршы «ҮәАллаһи тыячакбыз!», — дисеңме?!».*

## Хатын-кызның мәчеттә нәфел намазы укуы, һәм шулай ук гыйбадәттә үз-үзен азапламавы хакында

حَدَّثَنَا أَبُو مَعْمَرٍ حَدَّثَنَا عَبْدُ الْوَارِثِ حَدَّثَنَا عَبْدُ الْعَزِيزِ بْنُ صُهَيْبٍ عَنْ أَنَسِ بْنِ مَالِكٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ قَالَ: دَخَلَ النَّبِيُّ ﷺ فَإِذَا حَبْلٌ مَمْدُودٌ بَيْنَ السَّارِيَتَيْنِ فَقَالَ: «مَا هَذَا الْحَبْلُ؟» قَالُوا: هَذَا حَبْلٌ لِزَيْنَبَ فَإِذَا فَتَرَتْ تَعَلَّقَتْ، فَقَالَ النَّبِيُّ ﷺ: «لا حُلُّوهُ لِيُصَلِّ أَحَدُكُمْ نَشَاطَهُ فَإِذَا فَتَرَ فَلْيَقْعُدْ» [ البخاري ١١٥٠ ]

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәлик ﷺ әйтте: *«Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ мәчеткә кергәч, ике багана арасына бәйләнгән бауны күреп калды һәм сорады:* ***«Бу нинди бау?»*** *Әйттеләр: «Бу Зәйнәбнең бауы, әгәр дә (намаз укып) арыса, шуңа тотына (яки шуңа тотынып укый)». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Юк! Сүтегез аны! Әгәр дә берәрегез намаз укыса, дәртле (хәле булган) килеш укысын, ә инде зәгыйфьләнсә (хәле бетсә), утырсын».***

## Хатын-кызның өйдә намаз укуы хакында

٥٦٧ - عَنِ ابْنِ عُمَرَ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم: « لاَ تَمْنَعُوا نِسَاءَكُمُ الْمَسَاجِدَ وَبُيُوتُهُنَّ خَيْرٌ لَهُنَّ» [ سنن أبي داود تحقيق الألباني : صحيح ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гомәрдән ﷺ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хатын-кызларыгызны мәчеттән тыймагыз, ә инде өйләрендә (намаз укулары) алар өчен хәерлерәк».***

عَنْ أُمِّ سَلَمَةَ عَنْ رَسُولِ اللهِ ﷺ أَنَّهُ قَالَ: «خَيْرُ مَسَاجِدِ النِّسَاءِ قَعْرُ بُيُوتِهِنّ» [ أحمد ٢٩٧/٦ صححه ابن خزيمة (١٦٨٣)، و الحاكم (٢٠٩/١) قال شعيب: حسن بشواهده ]

Мәгънәсе: Үммү Сәләмәдән ﷺ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хатын-кызларга иң хәерле мәчет — ул аларның йорт эче».***

## Хатын-кызлар үзләре генә намаз укыганда араларыннан берсе имам булуы хакында

٥٩١ - عن الْوَلِيدُ بْنُ عَبْدِ اللهِ قَالَ: حَدَّثَتْنِي جَدَّتِي وَعَبْدُ الرَّحْمَنِ بْنُ خَلَّادٍعَنْ أُمِّ وَرَقَةَ بِنْتِ عَبْدِ اللهِ بْنِ نَوْفَلٍ الْأَنْصَارِيَّةِ أَنَّ النَّبِيَّ ﷺ لَمَّا غَزَا بَدْرًا قَالَتْ قُلْتُ لَهُ يَا رَسُولَ اللهِ ائْذَنْ لِي فِي الْغَزْوِ مَعَكَ أُمَرِّضُ مَرْضَاكُمْ لَعَلَّ الله أَنْ يَرْزُقَنِي شَهَادَةً قَالَ قَرِّي فِي بَيْتِكِ فَإِنَّ الله تَعَالَى يَرْزُقُكِ الشَّهَادَةَ قَالَ فَكَانَتْ تُسَمَّى الشَّهِيدَةُ قَالَ وَكَانَتْ قَدْ قَرَأَتْ الْقُرْآنَ فَاسْتَأْذَنَتْ النَّبِيَّ ﷺ أَنْ تَتَّخِذَ فِي دَارِهَا مُؤَذِّنًا فَأَذِنَ لَهَا قَالَ وَكَانَتْ قَدْ دَبَّرَتْ غُلَامًا لَهَا وَجَارِيَةً فَقَامَا إِلَيْهَا بِاللَّيْلِ فَغَمَّاهَا بِقَطِيفَةٍ لَهَا حَتَّى مَاتَتْ وَذَهَبَا فَأَصْبَحَ عُمَرُ فَقَامَ فِي النَّاسِ فَقَالَ مَنْ كَانَ عِنْدَهُ مِنْ هَذَيْنِ عِلْمٌ أَوْ مَنْ رَآهُمَا فَلْيَجِئْ بِهِمَا فَأَمَرَ بِهِمَا فَصُلِبَا فَكَانَا أَوَّلَ مَصْلُوبٍ بِالْمَدِينَةِ حَدَّثَنَا الْحَسَنُ بْنُ حَمَّادٍ الْحَضْرَمِيُّ حَدَّثَنَا مُحَمَّدُ بْنُ فُضَيْلٍ عَنْ الْوَلِيدِ بْنِ جُمَيْعٍ عَنْ عَبْدِ الرَّحْمَنِ بْنِ خَلَّادٍ عَنْ أُمِّ وَرَقَةَ بِنْتِ عَبْدِ اللهِ بْنِ الْحَارِثِ بِهَذَا الْحَدِيثِ وَالْأَوَّلُ أَتَمُّ قَالَ وَكَانَ رَسُولُ اللهِ ﷺ يَزُورُهَا فِي بَيْتِهَا وَجَعَلَ لَهَا مُؤَذِّنًا يُؤَذِّنُ لَهَا وَأَمَرَهَا أَنْ تَؤُمَّ أَهْلَ دَارِهَا قَالَ عَبْدُ الرَّحْمَنِ فَأَنَا رَأَيْتُ مُؤَذِّنَهَا شَيْخًا كَبِيرًا [ سنن أبي داود، تحقيق الألباني: حسن ]

Мәгънәсе: Әл-Вәлид бин Габдуллаһ бин Җүмайгъ әйтте: *«Миңа әбием (Ләйлә бинт Мәлик) һәм Габдуррахман бин Халләд сөйләделәр: Үммү Уарака бинт Нәүфәл әйтте: Пәйгамбәребез ﷺ Бәдер сугышына җыенганда мин аңа әйттем: «Йә Расүл Аллаһ! Миңа синең белән сугышка чыгырга рөхсәт ит, анда мин яралыларны дәваларммын, шулай ук бәлки Аллаһ тәгалә мине шәһидлек үлеме белән ризыкландырыр!». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Өеңдә кал, хакыйкатьтә Аллаһ тәгалә сине шәһидлек үлеме белән ризыкландырыр!».*** *Әйтте (Габдуррахман): «Һәм ул (Үммү Уарака) «Шәһид», дип атала иде». Һәм дәвам итеп әйтте (Габдуррахман): «Һәм ул (Үммү Уарака) Коръән укый иде, вә пәйгамбәребездән ﷺ үзенең йортына мөәзин алырга рөхсәт сорагач, ул рөхсәт итте», һәм дәвам итте: «Аның (Үммү Уараканың) бер егет вә бер кыз колы бар иде, һәм ул аларны үзе вафат булгач, азат булулары хакында белгертте. Төнлә белән бу икесе Үммү Уараканың битен аның киеме белән үк каплап, буып үтерделәр, һәм чыгып качтылар. Иртә белән Гомәр ؓ кешеләргә игълан кылып әйтте: «Кем бу икесен кайда икәнлекләрен белсә, яки аларны күргән булса, аларны тотып алып килсен!». Аларны алып килгәч, икесен дә баганага кадакладылар. Һәм алар, Мәдинәдә баганага кадакланып үтерелүчеләрдән иң беренчеләр булдылар».*

Әбү Давыдта килгән ошбу хәдиснең (592) икенче риваятендә болай дип өстәлде: Әйтте (Габдуррахман): *«Пәйгамбәребез ﷺ аны (Үммү Уараканы) өенә килеп зиярат итә иде, һәм аңа азан әйтүче мөәзин билгеләде, шулай ук аңа өендә булганнарга имам булып намаз укырга кушты». Шуннан соң Габдуррахман дәвам итеп әйтте: «Мин аның мөәзинен зур яшьтәге карт кеше икәнлеген күрдем».*

Бу ике хәдиснең дөреслеге хакында галимнәр каршылыклы фикерләргә килсәләр дә, әмма инде хатын-кызлар гына намаз укыганда алар арасыннан берсе имам булып укуы билгеле мәсьәлә. Һәм моңа карата түбәндәге берничә сахих әсәрне искә алып узарбыз:

٥٠٨٦ - عبد الرزاق عن الثوري عن ميسرة بن حبيب النهدي عن ريطة الحنفية: «أن عائشة أمتهن وقامت بينهن في صلاة مكتوبة» [ المصنف، صحيح لغيره ]

Мәгънәсе: Рыйта әл-Хәнәфия әйтте: ***«Гаишә фарыз намазында алар арасына имам булып басып намаз укытты».***

٥٠٨٠ - عبد الرزاق عن ابن جريج قال: «تؤم المرأة النساء من غير أن تخرج أمامهن ولكن تحاذي بهن في المكتوبة والتطوع»، قلت: وإن كثرن حتى يكن صفين أو أكثر؟ قال: «وأن تقوم وسطهن» [ المصنف، صحيح عن ابن جريج ]

Мәгънәсе: Ибен Җүрайҗ әйтте: ***«Хатын-кыз башка хатыннарга фарызда яки өстәмә намазларда (таравих кебек) имам булып басса, алларына чыгып басмый (беренче сафның уртасына баса)».*** Әйттем (Абдурраззак): *«Әгәр дә алар күбәеп китсәләр һәм сафлары ике сафка җитсә яки артса?».* Әйтте: ***«Урталарына бассын (алга чыкмыйча, саф уртасына)».***

Инде бу хакта башка риваятьләр дә бар, без аларның барсына да туктап тормабыз, һәм кыскача гына шушыны әйтеп узарбыз: Әбү Хәнифә, Шәфигый, Әхмәд бин Хәнбәл мәзһәбләрендә хатын-кызның башка хатыннарга имам булып намаз укытуы ярый торган хәл, мәгәр Әбү Хәнифә мәкруһ диде, ләкин укытса, намазы дөрес була. Мәлик тыела яки ярамый дип әйтте. Ә инде хатын-кызның ирләр булган җәмәгатькә имам булырга ярамаганлыгы хакында алар арасында каршылык юк. Шулай ук, әгәр дә хатын-кыз башка хатыннарга имам булса, алга чыкмыйча беренче сафның уртасына баса. Намазларны кычкырып укыймы яки эчтән укыймы дигән мәсьәләдә ибен Кудама болай диде: *«Чит ирләр булмыйча мәхрәмнәре генә булса, кычкырып укый торган намазны кычкырып укыса ярый».*

## Намаз укыганда баланы кулга алу хакында

عَنْ أَبِي قَتَادَةَ الْأَنْصَارِيِّ: «أَنَّ رَسُولَ اللهِ ﷺ كَانَ يُصَلِّي وَهُوَ حَامِلٌ أُمَامَةَ بِنْتَ زَيْنَبَ بِنْتِ رَسُولِ اللهِ ﷺ» وَلِأَبِي الْعَاصِ بْنِ رَبِيعَةَ بْنِ عَبْدِ شَمْسٍ: «فَإِذَا سَجَدَ وَضَعَهَا وَإِذَا قَامَ حَمَلَهَا» [ البخاري ٥١٦ ]

Мәгънәсе: Әбү Катада әл-Ансарий ﵁ сүзеннән риваять кылуынча: ***«Пәйгамбәребез ﷺ намаз укыганда кулына үзенең кызы Зәйнәбнең кызы (пәйгамбәребезнең оныгы) Үмәмәне ала иде».*** Ә инде Әбү әл-Гас бин Рабийга бин Габдушшәмс хәбәр итүенчә: ***«Пәйгамбәребез ﷺ сәҗдәгә киткәндә аны җиргә куя иде, ә торганда яңадан кулына ала торган иде».***

## Ир һәм хатын бер-берсен төнге намазга уятулары хакында

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «رَحِمَ اللهُ رَجُلًا قَامَ مِنَ اللَّيْلِ فَصَلَّى وَأَيْقَظَ امْرَأَتَهُ فَإِنْ أَبَتْ نَضَحَ فِي وَجْهِهَا الْمَاءَ رَحِمَ اللهُ امْرَأَةً قَامَتْ مِنَ اللَّيْلِ فَصَلَّتْ وَأَيْقَظَتْ زَوْجَهَا فَإِنْ أَبَى نَضَحَتْ فِي وَجْهِهِ الْمَاءَ» [ أبو داود ١٣٠٨ تحقيق الألباني : حسن صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадән ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгалә рәхимле була шул ир-атка, ул ир-ат төнлә торып намаз укыганнан соң хатынын уята, һәм хатыны да намаз укый, ә инде хатыны тормаса, аның битенә су сибә. Шулай ук, Аллаһ тәгалә рәхимле була шул хатынга, ул хатын төнлә торып намаз укыганнан соң ирен уята, һәм ире дә намаз укый, ә инде ире тормаса, аның битенә су сибә».***

# Җомга намазы хатын-кызларга фарызмы?

Галимнәр җомганың хатын-кызга фарыз түгеллегенә берсүзсез килештеләр. Ә инде җомганы укыса, дөрес була. Без бу хакта кайбер риваятьләрне искә алып үтәрбез:

١٠٦٧- عَنْ طَارِقِ بْنِ شِهَابٍ عَنِ النَّبِيِّ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «الْجُمُعَةُ حَقٌّ وَاجِبٌ عَلَى كُلِّ مُسْلِمٍ فِى جَمَاعَةٍ إِلاَّ أَرْبَعَةً عَبْدٌ مَمْلُوكٌ أَوِ امْرَأَةٌ أَوْ صَبِىٌّ أَوْ مَرِيضٌ» [ سنن أبي داود، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Җомга намазын җәмәгать белән уку, дүрт кешедән башка һәр мөселманга фарыз: колга, хатын-кызга, сабыйга (бәлигъ булганчы) һәм хастага (авыру кешегә)».***

٥١٠٥ - عبد الرزاق عن ابن جريج عن عطاء قال قلت: «أرأيت من تخرج من النساء بالنهار إذا سمعت الاذان أيحق عليها حضور الصلاة؟ قال: إن أحبت ان تأتيها، وإن لم تفعل فلا حرج، قلت: قوله (يا أيها الذين آمنوا إذا نودي للصلاة من يوم الجمعة) أليست للنساء مع الرجال؟ قال: لا» [ المصنف ١٤٦/٣ صحيح إلى عطاء ]

Мәгънәсе: Ибен Җурайҗ Гатадан сорады: ***«Әгәр дә хатын-кыз көндез азан тавышы ишетеп намазга (җәмәгать намазына) юнәлсә, дөрес буламы?».*** Гата әйтте: ***«Әгәр дә барырга теләсә — бара, ә инде теләмәсә — бер гөнаһ та юк».*** Шуннан соң мин әйттем: ***«Ә Коръәндә Аллаһ тәгалә әйткән ошбу аять:***

(يا أيها الذين آمنوا إذا نودي للصلاة من يوم الجمعة)

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Әгәр җомга көн җомга намазына азан әйтелсә...»** ***Хатын-кызларга да ирләргә дә кагылмыймы?».*** Гата әйтте: ***«Юк».***

# Хатын-кыз намаз укучы ир-ат алдыннан узып китсә, намаз укучының намазы бозыламы?

Бу мәсьәләдә гыйлем әһелләре капма-каршылыклы фикерләргә бүленделәр. Берәүләр хатын-кыз ир кеше алдыннан узса, аның намазы бозыла дисә, икенчеләре (алар күпчелек) бозылмый диделәр. Һәм намаз бозыла дигәнне, бәлки алдан узып китүчегә күз карашы төшеп намазда тынычлык һәм диккатьлек бозыла, дип аңлаттылар. Инде без сезгә шушы ике якның да берничә дәлилләрен китереп узарбыз.

***Хатын-кыз узып китсә намаз бозыла диючеләрнең кайбер дәлилләре:***

عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ الصَّامِتِ عَنْ أَبِي ذَرٍّ ﷺ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «إِذَا قَامَ أَحَدُكُمْ يُصَلِّي فَإِنَّهُ يَسْتُرُهُ إِذَا كَانَ بَيْنَ يَدَيْهِ مِثْلُ آخِرَةِ الرَّحْلِ فَإِذَا لَمْ يَكُنْ بَيْنَ يَدَيْهِ مِثْلُ آخِرَةِ الرَّحْلِ فَإِنَّهُ يَقْطَعُ صَلاَتَهُ الْحِمَارُ وَالْمَرْأَةُ وَالْكَلْبُ الأَسْوَدُ» قُلْتُ: «يَا أَبَا ذَرٍّ مَا بَالُ الْكَلْبِ الأَسْوَدِ مِنْ الْكَلْبِ الأَحْمَرِ مِنْ الْكَلْبِ الأَصْفَرِ؟» قَالَ: يَا ابْنَ أَخِي سَأَلْتُ رَسُولَ اللهِ ﷺ كَمَا سَأَلْتَنِي فَقَالَ: «الْكَلْبُ الأَسْوَدُ شَيْطَانٌ» [ مسلم ٥١٠ ]

Мәгънәсе: Әбү Зәрдән ﷺ риваять itelә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәрегез намаз укырга басса, үзенең алдына ияр кашы кадәр берәр нәрсә куйсын. Әгәр дә аның алдында ияр кашы кадәр әйбер булмаса, аның намазын ишәк, хатын-кыз һәм кара эт боза».*** Мин сорадым (Габдуллаһ бин әл-Самит): *«Әй Әбү Зәр! Кара эт башка (төстәге) кызыл яки сары этләрдән нәрсәсе белән аерыла?».* Ул әйтте: *«Әй абыемның улы! Мин син сораган кебек үк пәйгамбәребездән ﷺ сорадым, һәм ул әйтте:* ***«Кара эт, ул — шәйтан».***

٧٠٣ - عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ ﷺ - رَفَعَهُ شُعْبَةُ - قَالَ: «يَقْطَعُ الصَّلاَةَ الْمَرْأَةُ الْحَائِضُ وَالْكَلْبُ» [ سنن أبي داود، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Ибен Габбас ﷺ әйтте: ***«Намазны күрем күрә торган хатын-кыз һәм эт боза».***

Әл-Бәйһәкый бу риваять хакында болай диде: *«Ибен Габбастан дөрес булганы, ул намазны бозмый, бәлки мәкруһтыр...».*

Бу хакта сахәбәләрдән вә тәбигыйннардан килгән башка әсәрләр бар. Бу карашны шулай ук Әхмәд бин Хәнбәл, ибен әл-Каийм, ибен Хәзм, әш-Шәүкәний һәм башкалар хуплады. Без инде аларга тукталып тормыйбыз.

***Хатын-кыз узып китсә намаз бозылмый диючеләрнең кайбер дәлилләре:***

حَدَّثَنَا إِسْحَاقُ بْنُ إِبْرَاهِيمَ قَالَ أَخْبَرَنَا يَعْقُوبُ بْنُ إِبْرَاهِيمَ بْنِ سَعْدٍ قَالَ حَدَّثَنِي ابْنُ أَخِي ابْنِ شِهَابٍ أَنَّهُ سَأَلَ عَمَّهُ عَنْ الصَّلاَةِ يَقْطَعُهَا شَيْءٌ فَقَالَ لاَ يَقْطَعُهَا شَيْءٌ أَخْبَرَنِي عُرْوَةُ بْنُ الزُّبَيْرِ أَنَّ عَائِشَةَ زَوْجَ النَّبِيِّ ﷺ قَالَت لَقَدْ كَانَ رَسُولُ اللهِ ﷺ يَقُومُ فَيُصَلِّي مِنْ اللَّيْلِ وَإِنِّي لَمُعْتَرِضَةٌ بَيْنَهُ وَبَيْنَ الْقِبْلَةِ عَلَى فِرَاشِ أَهْلِهِ [ البخاري ٥١٥ ]

Мәгънәсе: Пәйгамбәребезнең ﷺ хатыны Гаишә ﷺ әйтте: ***«Еш кына пәйгамбәребез ﷺ төнлә торып намаз укый иде, һәм мин шул вакытта кыйбла белән аның арасында ятагында ята идем».***

عَنْ عَائِشَةَ قَالَتْ: «أَعَدَلْتُمُونَا بِالْكَلْبِ وَالْحِمَارِ لَقَدْ رَأَيْتُنِي مُضْطَجِعَةً عَلَى السَّرِيرِ فَيَجِيءُ النَّبِيُّ ﷺ فَيَتَوَسَّطُ السَّرِيرَ فَيُصَلِّي فَأَكْرَهُ أَنْ أَسْنَحَهُ فَأَنْسَلُّ مِنْ قِبَلِ رِجْلَيْ السَّرِيرِ حَتَّى أَنْسَلَّ مِنْ لِحَافِي» [ البخاري ٥٠٨ ]

Мәгънәсе: Гаишә ﷺ әйтте: ***«(Чынлап та) сез безне этләргә һәм ишәкләргә тиңлисезме?! Ә бит мин ятакта ятканда, пәйгамбәребез ﷺ килеп шул ятакның уртасына юнәлеп намаз укый иде. Шундый чакта мин үзем анда (яки пәйгамбәребезнең каршында) булуымнан уңайсызланып, ятакның ике аягы арасыннан, юрганнан шуып чыга идем».***

Шулай ук, бу карашны ныгытып килгән башка хәдисләр вә әсәрләр бар. Бу фикерне Гаишә, Гали, Госман, ибен Габбас һәм ибен Гомәрм ﷺ кебек башка сахәбәләр хупла-

ды. Шулай ук, бу өч имамның: Әбү Хәнифә, Мәлик һәм Шәфигыйларның карашы. Аллаһу әгъләм.

## Кияүгә чыккан хатын-кыз әти-әнисенең өенә кунакка сәфәр кылса, намазын кыскартамы?

Аерым бу мәсьәләне генә бәян итеп узган, ачык кына бер дәлил дә юктыр. Әмма ләкин безгә дөресрәк күренгәне; кияүгә чыгып еракка киткән хатын-кыз әти-әнисенең өенә кунакка кайтса, намазларын кыскартып укый. Чөнки Аллаһ тәгалә Коръәндә, иренең йорты аның да (хатынның да) йорты дип искә алды:

(وَاتَّقُوا اللَّهَ رَبَّكُمْ لا تُخْرِجُوهُنَّ مِنْ بُيُوتِهِنَّ) الطلاق: ١

Мәгънәсе: **«Раббыгыз булган Аллаһка тәкъва булыгыз! Хатыннарыгызны талак кылгач, торган өйләреннән чыгармагыз».**

(...وَاذْكُرْنَ مَا يُتْلَى فِي بُيُوتِكُنَّ...) الأحزاب: ٣٤

Мәгънәсе: **«Әй хатыннар! Өегездә укылган Аллаһның аятьләрен зекер итегез».**

Шулай булгач, әгәр дә ул әти-әнисенең өенә сәфәр кыла икән, ул инде намазларын кыскартып укый, чөнки әти-әнисенең йорты — аның йорты түгел. Аллаһу әгъләм.

# ҖЕНАЗА БҮЛЕГЕ

## Кайгы килгәндә сабыр булу хакында

١٢٨٣- عَنْ أَنَسِ بْنِ مَالِكٍ ﷺ قَالَ: مَرَّ النَّبِيُّ ﷺ بِامْرَأَةٍ تَبْكِي عِنْدَ قَبْرٍ فَقَالَ: «اتَّقِي اللهَ وَاصْبِرِي» قَالَتْ: إِلَيْكَ عَنِّي فَإِنَّكَ لَمْ تُصَبْ بِمُصِيبَتِي وَلَمْ تَعْرِفْهُ، فَقِيلَ لَهَا: إِنَّهُ النَّبِيُّ ﷺ، فَأَتَتْ بَابَ النَّبِيِّ ﷺ فَلَمْ تَجِدْ عِنْدَهُ بَوَّابِينَ فَقَالَتْ: لَمْ أَعْرِفْكَ، فَقَالَ: «إِنَّمَا الصَّبْرُ عِنْدَ الصَّدْمَةِ الأُولَى» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәлик ﷺ риваять итеп әйтте: *«Пәйгамбәребез ﷺ кабер янында елап торган бер хатын-кыз янышнан узып барганда (туктап) аңа әйтте:* ***«Аллаһка тәкъва бул, һәм сабыр ит!».*** *Ул (хатын) аның расүл ﷺ икәнлеген белмичә әйтте: «Калдыр мине, чөнки сиңа минеке кебек кайгы төшкәне юк!». Аңа әйттеләр: «Хакыйкатьтә, ул бит пәйгамбәребез ﷺ!». Шуннан соң ул хатын пәйгамбәребез ﷺ (йорты) янына килде, әмма ләкин аның ишеге янында бер сакчы да күрмәде (чөнки ул, пәйгамбәребез ﷺ патшалар кебек яши дип уйлаган иде) һәм әйтте: «Мин сине белмәдем!». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Хакыйкатьтә, сабырлыкны кайгының иң беренче мизгелендә күрсәтергә кирәк!».***

Әл-Хаттабий әйтте: *«Кеше мактала вә әҗер-савапка лаек була торган сабырлык — ул, кешегә кинәт кенә килгән кайгының, авырлыкның иң беренче мизгелендә күренгән сабырлык...».* Чөнки, кайгыдан соң вакыт узып беленгән сабырлыкта, кеше инде тынычланган була. Шулай ук, кеше кайгы өчен савапка лаек булмый, чөнки кайгы аның теләге белән түгел, ә бәлки ошбу кайгыда ныклы вә күркәм сабырлы булуы өчен әҗер-саваплы була.

٥٦٤٥ ـ عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ ﷺ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ: «مَنْ يُرِدِ اللَّهُ بِهِ خَيْرًا يُصِبْ مِنْهُ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадән ﷺ риваять itелә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгалә бер кешегә***

***хәерлелекне теләсә, Ул аны авырлыклар (кайгы-хәсрәт, бәла-каза) белән сынар».***

## Кемнең дә булса бик нык яраткан кешесе үлеп, ул ошбу авырлыкны ныклы иман вә Аллаһтан әҗер өмет итеп сабырлык күрсәтү хакында

٦٤٢٤ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ أَنَّ رَسُولَ اللهِ ﷺ قال: «يَقُولُ اللَّهُ تَعَالَى مَا لِعَبْدِي الْمُؤْمِنِ عِنْدِي جَزَاءٌ إِذَا قَبَضْتُ صَفِيَّهُ مِنْ أَهْلِ الدُّنْيَا ثُمَّ احْتَسَبَهُ إِلَّا الْجَنَّةُ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадән ﵁ риваять ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгалә әйтә: «Әгәр дә Мин мөэминнең бик тә нык яраткан кешесен алсам, ә ул шул югалтуга каршылык белдерми, буйсынучанлык белән сабыр итеп, әҗерен өмет итсә, ул мөэмин колыма Җәннәт булыр».***

Ягъни, әгәр дә мөэмин кеше үзенең бик тә нык яраткан кешесен (әтисен, әнисен, яки баласын һ.б.) югалтып, аңа килгән шул кайгы-хәсрәткә Аллаһ ризалыгы өчен ныклы сабырлык күрсәтеп, Аннан әҗер-савап өмет итә икән, Раббысы аны Җәннәт белән бүләкләр.

١٢٥٠- عَنْ أَبِي سَعِيدٍ ﵁ أَنَّ النِّسَاءَ قُلْنَ لِلنَّبِيِّ ﷺ: «اجْعَلْ لَنَا يَوْمًا» فَوَعَظَهُنَّ وَقَالَ: «أَيُّمَا امْرَأَةٍ مَاتَ لَهَا ثَلَاثَةٌ مِنْ الْوَلَدِ كَانُوا حِجَابًا مِنْ النَّارِ» قَالَتْ امْرَأَةٌ: وَاثْنَانِ قَالَ: «وَاثْنَانِ» وَقَالَ شَرِيكٌ عَنْ ابْنِ الْأَصْبَهَانِيِّ حَدَّثَنِي أَبُو صَالِحٍ عَنْ أَبِي سَعِيدٍ وَأَبِي هُرَيْرَةَ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمَا عَنْ النَّبِيِّ ﷺ قَالَ أَبُو هُرَيْرَةَ: «لَمْ يَبْلُغُوا الْحِنْثَ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Сәгыйдтән ﵁ риваять ителә: *«Хатын-кызлар пәйгамбәребезгә ﷺ әйттеләр: «Безгә бер көн билгелә». Пәйгамбәребез ﷺ аларны вәгазьләде һәм әйтте:* ***«Әгәр дә берәр хатын-кызның өч баласы вафат булса, ул***

***балалар аңа Җәһәннәмнән пәрдә булырлар».*** Шуннан соң бер хатын-кыз сорады: *«Ә икәү булса?».* Расүлебез ﷺ әйтте: ***«Икәү булса да».*** Әбү Һурайра ؓ әйтте: *«Бәлигъ булганчыга кадәр».*

«Бәлигъ булганчыга кадәр» дигәннең мәгънәсе: Бәлигъ булмаган бала гөнаһлы эшләрдән ерак була, Аллаһу әгъләм.

## Мәетләр өчен кычкырмыйча елауның рөхсәт ителүе хакында

Кычкырмыйча елау мәеткә зыян китерми, һәм моны бәян итеп пәйгамбәребезнең ﷺ һәм сахәбәләрнең елаулары дәлил булып килә. Ә инде кеше мәет өчен кычкырып, иңрәп елый торган булса, ул вакытта инде мәет тагын да катырак газаплана. Без боларны хәзер аңлатып узарбыз, иншәАллаһ.

١٣٠٣ - عَنْ أَنَسِ بْنِ مَالِكٍ ؓ قَالَ: دَخَلْنَا مَعَ رَسُولِ اللهِ ﷺ عَلَى أَبِي سَيْفٍ الْقَيْنِ- وَكَانَ ظِئْرًا لِإِبْرَاهِيمَ عَلَيْهِ السَّلَامِ-فَأَخَذَ رَسُولُ اللهِ ﷺ إِبْرَاهِيمَ فَقَبَّلَهُ وَشَمَّهُ، ثُمَّ دَخَلْنَا عَلَيْهِ بَعْدَ ذَلِكَ وَإِبْرَاهِيمُ يَجُودُ بِنَفْسِهِ، فَجَعَلَتْ عَيْنَا رَسُولِ اللهِ ﷺ تَذْرِفَانِ، فَقَالَ لَهُ عَبْدُ الرَّحْمَنِ بْنُ عَوْفٍ ؓ: وَأَنْتَ يَا رَسُولَ اللهِ؟ فَقَالَ: «يَا ابْنَ عَوْفٍ إِنَّهَا رَحْمَةٌ» ثُمَّ أَتْبَعَهَا بِأُخْرَى فَقَالَ ﷺ: «إِنَّ الْعَيْنَ تَدْمَعُ وَالْقَلْبَ يَحْزَنُ وَلَا نَقُولُ إِلَّا مَا يَرْضَى رَبُّنَا وَإِنَّا بِفِرَاقِكَ يَا إِبْرَاهِيمُ لَمَحْزُونُونَ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәлик ؓ әйтте: *«Бервакыт без пәйгамбәребез ﷺ белән тимерче Әбү Сәйфкә кердек, ул шулай ук пәйгамбәребезнең улы — Ибраһимның — күкрәк анасының ире иде. Пәйгамбәребез ﷺ Ибраһимны кулына алып үпте һәм аның исен тирән итеп сулый башлады. Күпмедер вакыт узгач, без (Әбү Сәйфкә) тагын килдек, Ибраһим ул вакытта үлем хәлендә ята иде, моны күреп, пәйгамбәребезнең ﷺ күзләреннән яшь агып чыкты. Габдуррахман бин Гауф ؓ әйтте: «Син дә (елыйсыңмы), йә Расүл Аллаһ?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Йә ибен Гауф,***

***хакыйкатьтә, бу рәхимлелек (билгесе)!».*** Шуннан соң расүлебез ﷺ (дәвам итеп) әйтте: ***«Хакыйкатьтә, күзләр елый, ә йөрәк кайгыра (сызлый), шуңа карамастан да без Раббыбыз риза булырлык сүзләрне генә әйтәбез! Хакыйкатьтә, без синең белән аерылышуыбызга кайгырабыз йә Ибраһим!».***

١٣٠٤ - عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ عُمَرَ رَضِيَ اللهُ عَنْهُمَا قَالَ: اشْتَكَى سَعْدُ بْنُ عُبَادَةَ شَكْوَى لَهُ فَأَتَاهُ النَّبِيُّ ﷺ يَعُودُهُ مَعَ عَبْدِ الرَّحْمَنِ بْنِ عَوْفٍ وَسَعْدِ بْنِ أَبِي وَقَّاصٍ وَعَبْدِ اللهِ بْنِ مَسْعُودٍ ﷺ، فَلَمَّا دَخَلَ عَلَيْهِ فَوَجَدَهُ فِي غَاشِيَةِ أَهْلِهِ فَقَالَ: «قَدْ قضي؟» قَالُوا: لَا يَا رَسُولَ اللهِ، فَبَكَى النَّبِيُّ ﷺ فَلَمَّا رَأَى الْقَوْمُ بُكَاءَ النَّبِيِّ ﷺ بَكَوْا فَقَالَ: «أَلَا تَسْمَعُونَ؟ إِنَّ اللهَ لَا يُعَذِّبُ بِدَمْعِ الْعَيْنِ وَلَا بِحُزْنِ الْقَلْبِ، وَلَكِنْ يُعَذِّبُ بِهَذَا-وَأَشَارَ إِلَى لِسَانِهِ-أَوْ يَرْحَمُ، وَإِنَّ الْمَيِّتَ يُعَذَّبُ بِبُكَاءِ أَهْلِهِ عَلَيْهِ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гомәр ﷺ әйтте: *«Сагъд бин Губәдәһ бик нык авырып киткәч, пәйгамбәребез ﷺ аның янына Габдуррахман бин Гауф, Сагъд бин Әбий Уаккас һәм Габдуллаһ бин Мәсгудлар белән зиярат итәргә (хәлен беләргә) килде. Аның янына кергәч, янында туганнары җыелганын күреп пәйгамбәребез ﷺ сорады:* ***«Ул вафат булдымы әллә?».*** *Әйттеләр: «Юк, йә Расүл Аллаһ!». Шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ елап җибәрде. Аның елаганын күреп, башкалар да елый башладылар. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Сез әллә ишетмисезме? Хакыйкатьтә, Аллаһ тәгалә күзләрдән аккан яшьләр өчен дә, йөрәкнең кайгыруы өчен дә газапламый, әмма ләкин Ул менә моның өчен газаплый яки рәхимле була»,*** *һәм ул үзенең теленә күрсәтте. (Һәм дәвам итеп әйтте)* ***«Хакыйкатьтә, мәет аның өчен туганнары (кычкырып вә иңрәп) елаганга газаплана».***

١٢٨٩ - حَدَّثَنَا عَبْدُ اللَّهِ بْنُ يُوسُفَ أَخْبَرَنَا مَالِكٌ عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ أَبِي بَكْرٍ عَنْ أَبِيهِ عَنْ عَمْرَةَ بِنْتِ عَبْدِ الرَّحْمَنِ أَنَّهَا أَخْبَرَتْهُ أَنَّهَا سَمِعَتْ عَائِشَةَ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهَا زَوْجَ النَّبِيِّ ﷺ قَالَتْ: إِنَّمَا مَرَّ رَسُولُ اللهِ ﷺ عَلَى يَهُودِيَّةٍ يَبْكِي عَلَيْهَا أَهْلُهَا فَقَالَ: «إِنَّهُمْ لَيَبْكُونَ عَلَيْهَا وَإِنَّهَا لَتُعَذَّبُ فِي قَبْرِهَا» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Гаишә әйтте: *«Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ бер яһүдиянең кабере яныннан узып барганда, аның өчен кычкырып елаган туганнарын күреп әйтте:* ***«Хакыйкатьтә,***

***алар аның өчен бик кычкырып елыйлар, ә ул мәет болай да каберендә газаплана бит».***

## Хатын-кыз үлгәч, аны госел коендыру хакында

١٢٥٤ - عَنْ أُمِّ عَطِيَّةَ رَضِيَ اللهُ عَنْهَا قَالَتْ: دَخَلَ عَلَيْنَا رَسُولُ اللهِ ﷺ وَنَحْنُ نَغْسِلُ ابْنَتَهُ فَقَالَ: «اغْسِلْنَهَا ثَلَاثًا أَوْ خَمْسًا أَوْ أَكْثَرَ مِنْ ذَلِكَ بِمَاءٍ وَسِدْرٍ وَاجْعَلْنَ فِي الْآخِرَةِ كَافُورًا فَإِذَا فَرَغْتُنَّ فَآذِنَّنِي» فَلَمَّا فَرَغْنَا آذَنَّاهُ فَأَلْقَى إِلَيْنَا حِقْوَهُ فَقَالَ: «أَشْعِرْنَهَا إِيَّاهُ» فَقَالَ أَيُّوبُ وَحَدَّثَتْنِي حَفْصَةُ بِمِثْلِ حَدِيثِ مُحَمَّدٍ وَكَانَ فِي حَدِيثِ حَفْصَةَ اغْسِلْنَهَا وِتْرًا وَكَانَ فِيهِ ثَلَاثًا أَوْ خَمْسًا أَوْ سَبْعًا وَكَانَ فِيهِ أَنَّهُ قَالَ: «ابْدَءُوا بِمَيَامِنِهَا وَمَوَاضِعِ الْوُضُوءِ مِنْهَا» وَكَانَ فِيهِ أَنَّ أُمَّ عَطِيَّةَ قَالَتْ: «وَمَشَطْنَاهَا ثَلَاثَةَ قُرُونٍ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Үммү Гатыя әйтте: «Пәйгамбәребезнең ﷺ кызы Зәйнәб вафат булгач, без аны юарга җыенганда, ул яныбызга керде һәм әйтте: ***«Аны (Зәйнәбне) су һәм сидр белән өч, яки биш тапкыр, яки күбрәк юыгыз, һәм иң соңгысында кәфүр (камфара) белән юыгыз. Бетергәч, миңа хәбәр итәрсез».*** *Юып бетергәч, без аңа хәбәр иттек, ул безгә үзенең изарын бирде һәм әйтте:* ***«Аны шушыңа төрегез!».*** Шулай ук, Үммү Гатыя икенче риваятьтә өстәп әйтте: *«Һәм без аның (Зәйнәбнең) чәчләрен тарап өч толым итеп үрдек».*

**Бу хәдистән алырга мөмкин булган мөһим файдалар:**

**1)** Хатын-кызларны, хатыннар гына госел коендыра (иллә-мәгәр кайбер очракларда гына). Чөнки пәйгамбәребезнең ﷺ кызының ире була торып та, аны хатыннар госел коендырды.

**2)** Госел коендыручы хатын-кызлар **изге-салиха** булырга, вә **госелнең тәртибен белергә** тиешләр.

– Ни өчен **салиха** дигәндә, чөнки алар шәригать хөкемнәрен вә Аллаһ тәгалә билгеләгән чикләрне белүчерәк,

һәм мәеттә булган кимчелекләрне башкаларга ачып салмыйча, бәлки яшереп калалар.

«... وَمَنْ سَتَرَ مُسْلِمًا سَتَرَهُ اللهُ يَوْمَ الْقِيَامَةِ»

Без Бохарида килгән бу хәдиснең бер өлешен генә әйтеп үтәрбез, мәгънәсе: ***«...Кем мөселманның (кимчелеген, гөнаһын) яшереп калса, Аллаһ тәгалә ул кешенең (кимчелеген, гөнаһын) Кыямәт көнендә яшерер».***

Шулай ук, изге-салиха кеше, мәетне сүкми вә тиргәми һәм аның хакында гайбәт сөйләми.

قَالَ النَّبِيُّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ: «لا تَسُبُّوا الأَمْوَاتَ فَإِنَّهُمْ قَدْ أَفْضَوْا إِلَى مَا قَدَّمُوا»
[ البخاري ١٣٩٣ ]

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мәетләрне сүкмәгез, чөнки алар үзләренең элек (гөнаһ яки изгелек) эшләгәннәре өчен (җәзасына) ирештеләр».***

**– Госел коендыруның тәртибен белүче кеше,** ул пәйгамбәребез ﷺ өйрәткәнчә мәеткә ихсанлык белән, җиренә җиткереп эшли. Пәйгамбәребезнең ﷺ кызын Үммү Гатыя госел коендыргач, ән-Нәвәвий Мөслимнең шәрехендә әйткәнчә: *«Ул (Үммү Гатыя) соңыннан хатын-кыз мәетләрен юучы белгеч иде»,* — дип әйтте.

**3)** Мәетне киемнәреннән арындырып, гаурәт урынын (кендектән алып тезгә кадәр) чүпрәк белән каплау.

**4)** Мәетнең чәчләрен сүтү. (Бохари 1260)

**5)** Мәетне госел коендырганда йомшаклык вә абайлык белән эш итү.

**6)** Юындыра башлаганның беренчеләрендә сидр яки сабын кебек әйберләр куллану.

**7)** Хаҗәткә карап җылы су һәм башка кирәк-яраклар куллану.

**8)** Уң яктан һәм таһәрат урыннарыннан башлау.

**9)** Мәетнең башын сидр яки сабын белән әйбәтләп юу, һәм шулай ук чәч араларына су үтсен өчен, бармаклар белән йомшак итеп ышку.

**10)** Госел коендырганда барча әгъзаларын да уң яктан башлау.

**11)** Башта сул ягына яткырып, уң ягының барча тәнен, вә алдын-артын юу, шуннан соң уң ягына яткырып, шулай ук эшләү.

**12)** Соңгысында кәфүр (камфара) яки миск кебек хушбуй куллану.

**13)** Юуның иң азы бер тапкыр һәм иң күбе өч, биш яки күбрәк булырга мөмкин, хаҗәткә карап, әмма ләкин так булырга тиеш.

**14)** Чәчләрен тарап, өч толым итеп үрү (башның ике ягыннан ике, һәм түбәсеннән бер толым).

Бу инде ошбу хәдистән алынган иң мөһим файдалар, шулай ук гыйлем әһелләре хаҗәткә карап, башка файдаларын да әйтеп уздылар.

## Хатын-кызларга җеназа артыннан ияргә ярыймы?

١٢٧٨ - عَنْ أُمِّ عَطِيَّةَ رَضِيَ اللهُ عَنْهَا قَالَتْ: «نُهِينَا عَنْ اتِّبَاعِ الْجَنَائِزِ وَلَمْ يُعْزَمْ عَلَيْنَا» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Үммү Гатыя әйтте: ***«Без җеназа артыннан барырга тыелдык, ләкин катгый рәвештә түгел».***

Гыйлем әһелләренең күпчелеге хатын-кызга җеназа артыннан барырга мәкруһ диделәр. Без сезгә галимнәрнең кайбер фикерләрен искә алып узарбыз:

Ибен Хәҗәр “Фәтх әл-Бәрий”дә болай диде: ***«Катгый рәвештә түгел», — дигәне, ягъни безгә башка катгый рәвештә тыелган әйберләр кебек тыймады».***

“Әл-Фәтәвә әл-Һиндия”дә: ***«Хатын-кызга җеназа артыннан бару ярамас, әгәр дә кычкырып вә иңрәп елап баручы (хатын-кыз) булса — тыелыр».***

Ән-Нәвәвий “әл-Мәҗмугъ”та болай дип әйтте: ***«Әмма хатын-кызларга җеназа артыннан бару мәкруһ, хәрам түгел...».***

Шулай ук “Гаун әл-Мәгъбуд”та Шәмсулхак әл-Газыйм Әбәдий болай диде: ***«Катгый рәвештә түгел», — дигәне, билгеле булганча ул — мәкруһ, хәрам түгел».***

Шулай ук, башка сәләфләрдән дә билгеле булганча, алар хатын-кызларны җеназа артыннан баруларын бик катгый рәвештә тыймасалар да, ләкин рөхсәт итмиләр иде.

## Мөселманның китап әһеленнән (яһүд яки насарадан) булган хатыны балага узган килеш үлсә, кайда күмелә?

Әгәр дә насара (христиан) кебек кәфер кешесе Исламны кабул итеп мөселман булып үлә икән, ул вакытта мөселманнар зиярәтында күмелә. Ә инде мөселманның китап әһеленнән булган хатыны үлсә, аны мөселманнар зиярәтына күмү хәрам икәнлеге ачык вә билгеле мәсьәлә, һәм ул үз диненең каберстанында күмелә.

Әмма ләкин ошбу яһүд яки насара булган кәфер хатын мөселман иреннән балага узган килеш үлсә, һәм аның карынындагы баласы билгеле булганча мөселман, ул вакытта кайда күмелергә тиеш?

Әгәр кәферләр белән күмсәң, карынындагы баласы мөселман, һәм ул кәферләрнең газаплануыннан интегәчәк. Әгәр инде мөселманнар белән күмсәң, ул хатын үзе кәфер, аның тирә-янында яткан мөселманнар интегәчәк. Бу мәсьәлә әлбәттә бездә, Рәсәй җирендә, бик тә көнүзәк булып тора. Чөнки яһүдләр вә насаралар — алар кәферләр, бу хакта Аллаһ тәгалә Коръәндә ачыктан-ачык әйтте. Һәм аларның барасы урыннары да — куркыныч Җәһәннәм.

Бер мөселман гомер буе насара (христиан) хатыны белән яшәгәннән соң, ул хатынны мәңгелек Җәһәннәмнең билгесе булган, кәферләр зияратына алып барып күмәләр икән, ул ир-атның хәле ни булыр?!

Инде карындагы бала мәсьәләсенә кайтыйк, һәм бу хакта галимнәрнең кайбер сүзләрен искә алып үтәрбез:

٦٥٨٣ - عبد الرزاق عن معمر عن الزهري قال: «إذا حملت المرأة النصرانية من المسلم فماتت حاملا دفنت مع أهل دينها» [ صحيح عن الزهري ]

Мәгънәсе: Әз-Зүһрий әйтте: ***«Әгәр дә насрания (христиан хатын-кыз) мөселман иреннән балага узган килеш үлеп китсә, үз дининең каберстанында күмелә».***

٦٥٨٤ - أخبرنا عبد الرزاق قال: أخبرنا ابن جريج عن عطاء قال: «يليها أهل دينها وتدفن معهم» [ صحيح عن عطاء ]

Мәгънәсе: Гата әйтте: ***«Ул (насара) хатынны үз дине әһелләре (насаралар) ала, һәм алар каберстанында күмелә».***

Шулай ук, бу хакта башка әсәрләр бар, һәм насаралар (христианнар) зиярат ында күмелә диючеләр, алар күпчелек. Китап әһеленнән булган һәм мөселман иреннән балага узган хатын-кыз кыйблага арты белән сул ягына яткырыла диделәр. Чөнки, аның карынындагы бала (мөселман), бу хәлдә йөзе белән кыйблага таба юнәлеп, уң ягына яткан була.

Кемнәрдер андый хатын-кыз мөселманнар зиярат ында күмелә дип, сүзләрен Гомәр бин әл-Хәттабтан ﵁ килгән әсәргә юлласалар да, ибен әл-Мүнзир бу әсәр дөрес түгел диде.

Ибен Кудама "әл-Мугъний"да: *«Имам Әхмәд бу мәсьәләдә, мөселманның насара булган хатыны балага узган килеш үлсә, мөселманнар зиярат ында да, кәферләрнекендә дә күмелми, бәлки аерым урында күмелә»,* — дигән фикерне әйтте.

Безнең илдә әлбәттә аерым җирдә күмеп булмый, шуның өчен дә беренче карашны, яшәгән урыныбызга уңайрак дип табабыз, Аллаһу әгъләм.

## Хатын-кызларга каберләрне зиярат кылырга ярыймы?

Бу мәсьәләдә гыйлем әһелләре өчкә бүленделәр. Берәүләр хәрам дисә, икенчеләр мәкруһ диделәр, ә инде өченчеләр рөхсәт ителә яки мөбах диделәр.

**Хатын-кызларга каберләргә зиярат кылуны тыючыларның кайбер дәлилләре:**

١٠٥٦ - عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ ﵁: «أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ لَعَنَ زَوَّارَاتِ الْقُبُورِ» [ الترمذي، تحقيق الألباني: حسن ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайра ﵁ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ каберләрне күп зиярат кылучы хатын-кызларны ләгънәтләде».***

Ибен Хәҗәр "Фәтх әл-Бәрий"дә: *«Бу ләгънәт күп зиярат кылучы хатыннарга кагыла»,* — диде.

Әт-Тирмизий рахимәһу Аллаһ ошбу хәдисне бәян итеп болай диде: *«Кайбер гыйлем әһелләре бу хәдис, пәйгамбәребез ﷺ каберләрне зиярат кылуны рөхсәт иткәнче иде, дип әйттеләр».*

Хатын-кызларга каберләрне зиярат кылуны тыючылар һәм мәкруһ диючеләр, шулай ук алда искә алып узган Үммү Гатыяның хәдисе белән дәлилләнделәр, мәгънәсе: Үммү Гатыя ﵁ әйтте: *«Без җеназа артыннан барырга тыелдык, ләкин катгый рәвештә түгел».* Ләкин инде күренгәнчә бу зиярат кылуны тыя торган ачык дәлил түгел, бәлки җеназа артыннан иярүнең мәкруһ икәнлеген бәян итәдер. Алар Әбү Давытта, Әхмәдтә, ибен Мәҗәһдә, ән-Нәсәи, әл-Бәйһәкый һәм әл-Хәкимдә килгән башка хәдисләрне

дәлил итеп китерделәр, әмма ләкин ул хәдисләр зәгыйфь булу сәбәпле, без аларга тукталып тормыйбыз.

**Хатын-кызларга каберләргә зиярат кылуны рөхсәт итүчеләрнең кайбер дәлилләре:**

عَنْ أَنَسِ بْنِ مَالِكٍ ﵁ قَالَ: مَرَّ النَّبِيُّ ﷺ بِامْرَأَةٍ تَبْكِي عِنْدَ قَبْرٍ فَقَالَ: «اتَّقِي اللهَ وَاصْبِرِي» قَالَتْ: إِلَيْكَ عَنِّي فَإِنَّكَ لَمْ تُصَبْ بِمُصِيبَتِي وَلَمْ تَعْرِفْهُ فَقِيلَ لَهَا إِنَّهُ النَّبِيُّ ﷺ فَأَتَتْ بَابَ النَّبِيِّ ﷺ فَلَمْ تَجِدْ عِنْدَهُ بَوَّابِينَ فَقَالَتْ لَمْ أَعْرِفْكَ فَقَالَ: «إِنَّمَا الصَّبْرُ عِنْدَ الصَّدْمَةِ الأُولَى» [ البخاري١٢٨٣ ]

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәлик ﵁ риваять итеп әйтте: *«Пәйгамбәребез ﷺ кабер янында елап торган бер хатын-кыз яныннан узып барганда (туктап) аңа әйтте:* ***«Аллаһка тәкъва бул, һәм сабыр ит!».*** *Ул (хатын) аның расүл ﷺ икәнлеген белмичә әйтте: «Калдыр мине, чөнки сиңа минеке кебек кайгы төшкәне юк!». Аңа әйттеләр: «Хакыйкатьтә, ул бит пәйгамбәребез ﷺ!». Шуннан соң ул хатын пәйгамбәребез ﷺ (йорты) янына килде, әмма ләкин аның ишеге янында бер сакчы да күрмәде (чөнки пәйгамбәребез ﷺ патшалар кебек яши дип уйлаган иде) һәм әйтте: «Мин сине белмәдем!». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Хакыйкатьтә, сабырлыкны кайгының (авырлыкның) иң беренче мизгелендә күрсәтергә кирәк!».***

Бу хәдистән күренгәнчә, пәйгамбәребез ﷺ ул хатынның кабер янында зиярат кылып утырганын инкяр итмәде.

٩٧٦ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ ﵁ قَالَ: زَارَ النَّبِيُّ ﷺ قَبْرَ أُمِّهِ فَبَكَى وَأَبْكَى مَنْ حَوْلَهُ فَقَالَ: «اسْتَأْذَنْتُ رَبِّي فِي أَنْ أَسْتَغْفِرَ لَهَا فَلَمْ يُؤْذَنْ لِي وَاسْتَأْذَنْتُهُ فِي أَنْ أَزُورَ قَبْرَهَا فَأُذِنَ لِي فَزُورُوا الْقُبُورَ فَإِنَّهَا تُذَكِّرُ الْمَوْتَ» [ مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайра ﵁ әйтте: *«Пәйгамбәребез ﷺ әнисенең каберен зиярат кылганда елап җибәрде, һәм аңа кушылып янындагылар да елый башладылар. Шуннан соң расүлебез ﷺ әйтте:* ***«Мин Раббымнан әниемә ярлыкау сорарга дип рөхсәт сорадым, әмма ләкин рөхсәт ителмәдем. Шуннан соң каберен зиярат кылырга дип рөхсәт сора-***

***дым, монысына рөхсәт ителдем. Каберләрне зиярат итегез, хакыйкатьтә, ул сезгә үлемне искә төшерә!».***

***«Каберләрне зиярат итегез»,*** — дигәне, бу гомуми, ирләргә дә, хатыннарга да кагыла. Бу карашны ныгытып килгән башка сахих (дөрес) хәдисләр вә әсәрләр бар. Боларның барсын да карап узгач, рөхсәт итүчеләрнең дәлилләре көчлерәк икәнлеге, һәм хатын-кызларның ирләр кебек үк ахирәтне вә үлемне искә алуга мохтаҗ икәнлекләре аңлашыла. Аллаһу әгъләм.

# УРАЗА китабы

# Рамазан кичләрендә иргә хатыны белән йокларга рөхсәт ителүе хакында

(أُحِلَّ لَكُمْ لَيْلَةَ الصِّيَامِ الرَّفَثُ إِلَى نِسَائِكُمْ هُنَّ لِبَاسٌ لَكُمْ وَأَنْتُمْ لِبَاسٌ لَهُنَّ عَلِمَ اللَّهُ
أَنَّكُمْ كُنْتُمْ تَخْتَانُونَ أَنْفُسَكُمْ فَتَابَ عَلَيْكُمْ وَعَفَا عَنْكُمْ فَالآنَ بَاشِرُوهُنَّ وَابْتَغُوا مَا
كَتَبَ اللَّهُ لَكُمْ وَكُلُوا وَاشْرَبُوا حَتَّى يَتَبَيَّنَ لَكُمُ الْخَيْطُ الأَبْيَضُ مِنَ الْخَيْطِ الأَسْوَدِ
مِنَ الْفَجْرِ ثُمَّ أَتِمُّوا الصِّيَامَ إِلَى اللَّيْلِ وَلا تُبَاشِرُوهُنَّ وَأَنْتُمْ عَاكِفُونَ فِي الْمَسَاجِدِ
تِلْكَ حُدُودُ اللَّهِ فَلا تَقْرَبُوهَا كَذَلِكَ يُبَيِّنُ اللَّهُ آيَاتِهِ لِلنَّاسِ لَعَلَّهُمْ يَتَّقُونَ) البقرة: ١٨٧

Мәгънәсе: **«Рамазан аенда авыз ачканнан соң таңга хәтле хатыннарыгызга якынлык кылу хәләл ителде. Хатыннарыгыз сезгә, сез аларга кием. Аллаһ белде сезнең үз-үзегезгә хыянәт иткәнегезне, тәүбәләрне кабул итеп, гөнаһларыгызны гафу итте. Хәзер инде Рамазан кичләрендә хатыннарыгызга якынлык кылыгыз һәм Аллаһ тәкъдир иткән баланы эстәгез, балагызның һидәятле булуын Аллаһтан сорагыз һәм сәхәрдә ашагыз, эчегез, хәтта таң яктылыгы беленгәнче, аннары уразаны тотып тәмам итегез кояш баеганчы! Мәсҗидләрдә игътикәфтә булган көннәрегездә хатыннарыгызга якынлык кылмагыз. Югарыда әйтелгән хөкемнәр Аллаһның билгеләгән чиге, Аллаһ чигенә якын бармагыз! Әнә шулай Аллаһ аятьләрен кешеләргә ачык бәян итә, шаять, тәкъва булырлар дип».**

***Бу аятьнең төшү сәбәбе:***

١٩١٥ - عَنْ الْبَرَاءِ ﵁ قَالَ كَانَ أَصْحَابُ مُحَمَّدٍ ﷺ إِذَا كَانَ الرَّجُلُ صَائِمًا فَحَضَرَ الْإِفْطَارُ فَنَامَ قَبْلَ أَنْ يُفْطِرَ لَمْ يَأْكُلْ لَيْلَتَهُ وَلَا يَوْمَهُ حَتَّى يُمْسِيَ وَإِنَّ قَيْسَ بْنَ صِرْمَةَ الْأَنْصَارِيَّ كَانَ صَائِمًا فَلَمَّا حَضَرَ الْإِفْطَارُ أَتَى امْرَأَتَهُ فَقَالَ لَهَا أَعِنْدَكِ طَعَامٌ؟ قَالَتْ لا وَلَكِنْ أَنْطَلِقُ فَأَطْلُبُ لَكَ وَكَانَ يَوْمَهُ يَعْمَلُ فَغَلَبَتْهُ عَيْنَاهُ، فَجَاءَتْهُ امْرَأَتُهُ فَلَمَّا رَأَتْهُ قَالَتْ خَيْبَةً لَكَ فَلَمَّا انْتَصَفَ النَّهَارُ غُشِيَ عَلَيْهِ فَذُكِرَ ذَلِكَ لِلنَّبِيِّ ﷺ فَنَزَلَتْ هَذِهِ الْآيَةُ **(أُحِلَّ لَكُمْ لَيْلَةَ الصِّيَامِ الرَّفَثُ إِلَى نِسَائِكُمْ)** فَفَرِحُوا بِهَا فَرَحًا شَدِيدًا وَنَزَلَتْ **(وَكُلُوا وَاشْرَبُوا حَتَّى يَتَبَيَّنَ لَكُمُ الْخَيْطُ الْأَبْيَضُ مِنَ الْخَيْطِ الْأَسْوَدِ)** [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әл-Бәра' ﷺ әйтте: *«Әгәр дә Мөхәммәднең ﷺ сахәбәләреннән берәрсе ураза булып ифтар (авыз ачу) вакыты җитсә, һәм авыз ачканчы йоклап китә торган булса, ул инде бу төнне дә (төннә уянса), киләсе көндезен дә, икенче кичкә кадәр ашамый иде. Бервакыт Кайс бин Сыйрмә әл-Ансарий ураза иде, авыз ачыр вакыт җиткәч, ул хатыныннан сорады: «Синдә ашарга берәр нәрсә бармы?». Хатыны әйтте: «Юк, ләкин мин чыгып синең өчен ашарга берәр нәрсә эзләп керәм». Ул көне буе эшләгән иде, шуңа да аның күзләрен йокы басты, һәм йоклап китте. Бераздан хатыны кайтып аны күргәч әйтте: «Синең теләгең тормышка ашмады». Икенче көнне төш уртасы җиткәч, ул һуштан язды. Бу хәлне пәйгамбәребезгә ﷺ хәбәр иттеләр, һәм шуннан соң ошбу аять иңдерелде:* **«Рамазан кичләрендә хатыннарыгызга якынлык кылу сезгә хәләл ителде».** (әл-Бакара 187) *Алар (сахәбәләр) моңа бик тә нык шатландылар, аннары бу аять инде:* **«Ашагыз, эчегез, хәтта таң яктылыгы беленгәнче».** (әл-Бакара 187)

## Ураза хәлендә ир-атка хатынын кочакларга вә үбәргә рөхсәт ителүе хакында

Ураза хәлендә иргә хатынын үбәргә яки кочакларга рөхсәт итеп килгән хәдисләр вә әсәрләр бик күп. Без инде бу хактагы берничә хәдис һәм әсәрләрне искә алып узарбыз. Шулай ук, гыйлем әһелләренең бу хакта булган кайбер караш вә фикерләрен китерербез, иншәАллаһ.

١٩٢٧ - عَنْ عَائِشَةَ رَضِيَ اللهُ عَنْهَا قَالَتْ: «كَانَ النَّبِيُّ ﷺ يُقَبِّلُ وَيُبَاشِرُ وَهُوَ صَائِمٌ وَكَانَ أَمْلَكَكُمْ لِإِرْبِهِ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Гаишә әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ ураза килеш (үзенең хатыннарын) үбә вә кочаклый иде, ләкин сезнең***

***барчагызга караганда да ул үзен-үзе бик тә яхшы кулга ала белә иде».***

١١٠٦ - عَنْ عَائِشَةَ رَضِيَ اللهُ عَنْهَا قَالَتْ: «كَانَ رَسُولُ اللهِ ﷺ يُقَبِّلُ فِي شَهْرِ الصَّوْمِ» [ مسلم ]

Мәгънәсе: Гаишә әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ ураза аенда (хатыннарын) үбә торган иде».***

روى عبد الرزاق في مصنفه عن ابن عيينة عن زكريا عن الشعبي عن عمرو بن شرحبيل «أن ابن مسعود كان يباشر امرأته بنصف النهار و هو صائم» [ صحيح عن ابن مسعود ]

Мәгънәсе: Гамр бин Шурхәбийл әйтте: ***«Ибен Мәсгуд ураза хәлендә көн уртасында хатынын кочаклый торган иде».***

حدثنا عباد بن العوام عن الشيباني قال: «سألت عكرمة و الشعبي عن القبلة و المباشرة للصائم فرخصا فيها» [ صحيح عن عكرمة و الشعبي ]

Мәгънәсе: Әбү Исхак әш-Шәйбәний әйтте: ***«Мин Гыйкримә һәм әш-Шәгъбийдән ураза хәлендә булган кеше хатынын үбүе вә кочаклавы хакында сорадым һәм алар икесе дә моны рөхсәт иттеләр».***

Шулай ук, кайбер сахәбәләр вә тәбигыйннар моны тыялар иде, әммә ләкин хәдисләрдән мәгълүм булганча рөхсәт ителүе дөресрәк иншәАллаһ.

روى عبد الرزاق في مصنفه عن معمر عن الزهري عن ابن المسيب أن عمر بن الخطاب كان ينهى عن قبلة الصائم، فقيل له: «إن رسول الله ﷺ كان يقبل و هو صائم» فقال: «و من ذا له من الحفظ و العصمة ما لرسول الله ﷺ» [ هذا الأثر رجاله ثقات و علته الخلاف في سماع ابن المسيب من عمر رضي الله عنه ]

Мәгънәсе: Сәгыйд бин әл-Мүсәйб әйтте: *«Гомәр бин әл-Хәттаб ураза хәлендә булган кешегә үбүне тыя иде, шуннан соң аңа әйттеләр: «Хакыйкатьтә, расүл ﷺ ураза хәлендә дә (хатыннарын) үбә иде». Гомәр رضي الله عنه әйтте:* ***«Әгәр дә берәү үз-үзен (гөнаһлардан) пәйгамбәребез кебек саклый алса (эшләсен)».***

روى عبد الرزاق في مصنفه عن مالك عن نافع عن ابن عمر «أنه كان ينهى عن القبلة للصائم» [ صحيح عن ابن عمر ]

Мәгънәсе: Нәфигъ әйтте: ***«Габдуллаһ бин Гомәр ураза хәлендәге кешегә (хатынын) үбәргә тыя иде».***

Хәнәфиләрдән Әбү Бәкер бин Мәсгуд әл-Кәсәний "Бәдәигъ әс-Санаигъ фи тәртиб әш-Шәраигъ" китабында болай диде: *«Ураза хәлендә булган кеше хатынын үбсә һәм кочакласа, бер зарар да юк, әгәр дә үз-үзен кулга ала белсә».* Һәм дәвам итеп: *«Шәһвәтләнеп кочаклауны Әбү Хәнифә мәкруһ дип күрә»,* — диде.

Әш-Шәфигый "әл-Үмм" китабында: *«Ураза хәлендәге кешене шәһвәте хатынын үбәргә этәрсә, бу гамәл уразаны бозмаса да, хатыны аны кисәтергә һәм хупламаска тиеш, ә инде шәһвәтсез үбү булса, бер зарар да юк».*

"Әл-Мүдәүүәнә"дә: *«Мәлик ураза хәлендәге кешегә хатынын үбү яки кочаклауны мәкруһ күрә»,* — дип әйтелде.

Шулай ук, үбү һәм кочаклау уразаны бозмый дигән фикерне Хәнбәлиләрдән ибен Кудама "әл-Мугъний" китабында әйтеп узды.

Инде ураза килеш үпкәннән яки кочаклаганнан соң икесенең берсендә мәни чыгу сизелсә, ул вакытта нинди хөкем була дигән мәсьәләдә, гыйлем әһелләре берничә фикергә бүленделәр. Алда әйтеп узган хәдисләрдән билгеле булганча, ураза хәлендә ир үзенең хатынын үбә яки кочаклый ала, әмма ләкин шәһвәтләнеп мәни чыгуын ул күздә тотарга тиеш түгел. Чөнки хәдис кудсида Аллаһ тәгаләә ураза тотучы хакында болай диде:

«...يترك طعامه و شرابه و شهوته من أجلي...»

Мәгънәсе: ***«...Ризыгын, эчемлеген һәм шәһвәтен Минем өчен калдыра...».***

Шулай ук, пәйгамбәребезнең ﷺ Гомәргә үбү хакында әйткән сүзе, ураза кешенең үзе теләп шәһвәт эстәмәскә тиешлеген аңлата:

قَالَ عُمَرُ بْنُ الْخَطَّابِ ﵁ هَشَشْتُ فَقَبَّلْتُ وَأَنَا صَائِمٌ فَقُلْتُ يَا رَسُولَ اللهِ صَنَعْتُ الْيَوْمَ أَمْرًا عَظِيمًا قَبَّلْتُ وَأَنَا صَائِمٌ قَالَ أَرَأَيْتَ لَوْ مَضْمَضْتَ مِنْ الْمَاءِ وَأَنْتَ صَائِمٌ قَالَ عِيسَى بْنُ حَمَّادٍ فِي حَدِيثِهِ قُلْتُ لَا بَأْسَ بِهِ ثُمَّ اتَّفَقَا قَالَ فَمَهْ [ سنن أبي داود ٢٣٨٥ تحقيق الألباني :صحيح ]

Мәгънәсе: Гомәр бин әл-Хаттаб ﵁ әйтте: *«Мин шатланып дәртләнеп киттем һәм ураза килеш (хатынымны) үптем, шуннан пәйгамбәребезгә ﷺ әйттем: «Йә Расүл Аллаһ! Мин бүген бик зур (кирәкмәгән) эш эшләдем, ураза килеш (хатынымны) үптем». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Әгәр дә син ураза килеш авызыңны су белән чайкасаң (нәрсә була)?».*** *Әйттем (Гомәр): «Бер зарар да юк». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Шуннан (бу да шулай ук)?!».***

Ягъни, моннан аңлашылганча, ураза хәлендә үбү дә, авызны су белән чайкаган кебек үк мөбах гамәл. Ләкин, әгәр дә авызны су белән чайкаганда синең суны йотырга ниятең булган булса һәм су ялгыш булса да тамактан төшеп китсә, ураза бозылган була. Шулай ук, үбү дә. Әгәр дә шәһвәтләнү һәм мәнинең чыгуы күздә тотылган булса, һәм мәни чыкса, ураза бозыла. Ә инде андый нияте булмаган булса, ул вакытта бозылмый. Хатын-кызның хөкеме дә монда ир кешенеке кебек үк. Аллаһу әгъләм.

Хәнәфиләрдән Әс-Сәрхасий “әл-Мәбсут”та болай диде: *«Ир үзенең хатынын Рамазан аенда ураза хәлендә (шәһвәтләнеп) үпкәннән мәние чыкса, ул уразасын каза кылырга тиеш һәм аңа бернинди кәффәра да юк».*

Әш-Шәфигый “әл-Үмм”дә: *«Әгәр дә шәһвәтләнеп хатыны белән уйнаса һәм мәние чыкса, ул вакытта уразасы бозыла вә аңа каза кылырга кирәк була...».*

## Хатын-кыз ураза хәлендә ашарга пешергәндә ризыкның тәмен белер өчен кабып караса, шулай ук балага ризыкны чәйнәп бирсә ярыймы?

Әгәр дә хатын-кыз ашарга пешергәндә ризыкның тәмен, тозлымы-тозсызмы икәнен яки шуның кебек башка сәбәп белән аны йотмыйча кабып кына караса, бер зарар да юк. Шулай ук, балага ризыкны чәйнәп бирергә рөхсәт ителә, әгәр дә аны йотудан саклана торган булса. Бу хакта без сезгә сәләфләрдән һәм гыйлем әһелләреннән килгән кайбер әсәрләрне вә сүзләрне искә алып үтәрбез, иншәАллаһ.

قال ابن أبي شيبة في المصنف حدثنا وكيع عن إسرائيل عن جابر عن عطاء عن ابن عباس قال: «لا بأس أن يذوق الخل أو الشيء ما لم يدخل حلقه و هو صائم» [ المصنف، حسن لغيره ]

Мәгънәсе: Ибен Габбас ﷺ әйтте: ***«Ураза хәлендә булган кешегә серкә яки башка нәрсәне йотмыйча кабып кына караса, бер зарар да юк».***

عن معمر قال: «سألت حمادا عن المرأة الصائمة تذوق المرقة فلم ير عليها في ذلك بأسا» [ مصنف عبد الرزاق ]

Мәгънәсе: Мәгмәр әйтте: ***«Мин Хәммәдтән ураза хәлендә булган хатын-кыз шулпаны тәмләп каравы хакында сорадым, ул бу гамәлдә бер зарар да күрмәде».***

Хәнәфиләрдән Әс-Сәрхәсий «әл-Мәбсут»та ураза хәлендә булган хатын-кызның баласына ризык чәйнәп бирүе хакында болай диде: *«Әгәр дә хатын-кыз баласына ризыкны чәйнәп бирергә кирәклеген мөһим дип уйлый икән, аның шулай эшләвендә бер зарар да юк».* Һәм ризыкны тәмләп каравы хакында, болай дип дәвам итте: *«Әгәр дә*

*ураза булган кеше ризыкны йотмыйча теле белән тәмләп карый икән, аның уразасы бозылмый».*

Ибен Тәймия бу хакта: *«Әгәр дә ризыкны тәмләп карарга хаҗәт юк икән, ул вакытта аны тәмләп карау мәкруһ. Ә хаҗәт булса, ул вакытта инде ураза кеше таһәрат алганда авыз чайкаган кебек була».*

## Рамазанда хатын-кыз ураза хәлендә килеш ире белән якынлык кылса, йолым (кәффәра) тиешме?

١٩٣٦ - حَدَّثَنَا أَبُو الْيَمَانِ أَخْبَرَنَا شُعَيْبٌ عَنْ الزُّهْرِيِّ قَالَ أَخْبَرَنِي حُمَيْدُ بْنُ عَبْدِ الرَّحْمَنِ أَنَّ أَبَا هُرَيْرَةَ ﵁ قَالَ: «بَيْنَمَا نَحْنُ جُلُوسٌ عِنْدَ النَّبِيِّ ﷺ إِذْ جَاءَهُ رَجُلٌ فَقَالَ يَا رَسُولَ اللهِ هَلَكْتُ. قَالَ: مَا لَكَ؟ قَالَ: وَقَعْتُ عَلَى امْرَأَتِي وَأَنَا صَائِمٌ، فَقَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: هَلْ تَجِدُ رَقَبَةً تُعْتِقُهَا؟ قَالَ: لَا. قَالَ: فَهَلْ تَسْتَطِيعُ أَنْ تَصُومَ شَهْرَيْنِ مُتَتَابِعَيْنِ؟ قَالَ: لَا. فَقَالَ: فَهَلْ تَجِدُ إِطْعَامَ سِتِّينَ مِسْكِينًا؟ قَالَ: لَا. قَالَ: فَمَكَثَ النَّبِيُّ ﷺ فَبَيْنَا نَحْنُ عَلَى ذَلِكَ أُتِيَ النَّبِيُّ ﷺ بِعَرَقٍ فِيهَا تَمْرٌ- وَالْعَرَقُ: الْمِكْتَلُ- قَالَ: أَيْنَ السَّائِلُ؟ فَقَالَ: أَنَا، قَالَ: خُذْهَا فَتَصَدَّقْ بِهِ، فَقَالَ الرَّجُلُ: أَعَلَى أَفْقَرَ مِنِّي يَا رَسُولَ اللهِ، فَوَاللهِ مَا بَيْنَ لَابَتَيْهَا- يُرِيدُ الْحَرَّتَيْنِ- أَهْلُ بَيْتٍ أَفْقَرُ مِنْ أَهْلِ بَيْتِي، فَضَحِكَ النَّبِيُّ ﷺ حَتَّى بَدَتْ أَنْيَابُهُ ثُمَّ قَالَ: أَطْعِمْهُ أَهْلَكَ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайра ﵁ әйтте: *«Бервакыт без пәйгамбәребез ﷺ янында утырганда бер кеше килде һәм әйтте: «Йә Расүл Аллаһ! Һәлак булдым!». Пәйгамбәребез ﷺ аннан сорады:* ***«Нәрсә булды сиңа?».*** *Теге кеше әйтте: «Мин ураза килеш хатыным белән якынлык кылдым». Пәйгамбәребез ﷺ сорады:* ***«Син кол азат итә аласыңмы?».*** *Ул кеше: «Юк», — диде. Шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ аннан:* ***«Син ике ай бертоташ ураза тота аласыңмы?»,*** *— дип сорады. Теге кеше: «Юк», — дип җавап бирде. Пәйгамбәребез ﷺ сорады:* ***«Алтмыш мескенне ашата аласыңмы?».*** *Бу кеше: «Юк» — диде. Пәйгамбәребез ﷺ беразга тынып калды. Без шулай утырган вакытта расүлебезгә ﷺ бер кәрзин хөрмә китерделәр, һәм*

*ул сорады:* ***«Кайда теге сораучы?».*** *Теге кеше әйтте: «Мин (монда»). Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Моны ал һәм садака итеп тарат!».*** *Теге кеше әйтте: «Үземнән дә фәкыйрьрәккә биримме, йә Расүл Аллаһ?! ҮәАллаһи Мәдинәдә (һәм тирә янында) минем гаиләмнән дә фәкыйрьрәк кешеләр юктыр». Шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ көлеп җибәрде, хәтта аның тешләре күренде, һәм теге кешегә әйтте:* ***«Үзеңнең гаиләңне ашат!».***

**Нәрсә ул йолым яки кәффәра?**

Әгәр дә бер кеше Рамазан аенда үзенең уразасын хатыны белән, яки хатыны ире белән якынлык кылып бозса, ул вакытта аңа кәффәра тиеш.

**Кәффәра** ***— ул, алдагы хәдистән аңлашылганча, Рамазанда ошбу җинаятьне кылган кеше бер кол азат итәргә тиеш, аны булдыра алмаса, ике ай бертоташтан ураза тота, ә инде (авыру булып) аны да булдыра алмаса, ул вакытта алтмыш мескенне ашатырга тиеш.***

Күпчелек галимнәр кәффәра кылу (Әбү Хәнифә, әш-Шәфигый, әс-Сәүрий, әл-Әүзагый һәм Әхмәд бин Хәнбәл) тәртип буенча диделәр, һәм бу фикер дәлилләрнең куәтлегенә карап дөресрәк дип табылды. Иллә-мәгәр имам Мәлик ихтыяр буенча диде.

Шулай ук, хәдистә күргәнебезчә пәйгамбәребез ﷺ ир кешегә йолым (кәффәра) кылырга әмер итеп, хатыны хакында дәшми калды. Шуның өчен дә гыйлем әһелләре арасында хатын-кызга кәффәра тиешме яки юкмы дигән мәсьәләдә, кайбер каршылыклы фикерләр барлыкка килде. Күпчелек гыйлем әһелләре хатын-кызга да кәффәра тиеш диделәр.

Әл-Хаттабый әйтте: *«Иргә дә, хатынга да кәффәра тиешле, чөнки шәригать кешеләрне хөкемнәрдә тигез кылды, иллә-мәгәр (хатыннарга карата) аерым хас дәлил булса гына... Һәм бу күпчелек галимнәрнең мәзһәбе».*

Имам әш-Шәфигыйдан ике риваять бар:

1) Аларның берсенә дә кәффәра тиешле түгел.

2) Хатынга да тиешле, әмма ләкин аның кәффәрасы ир кеше өстендә була, ягъни икесенә бер кәффәра.

Имам Әбү Хәнифә әйтүенчә: «Әгәр дә хатын үз теләге белән якынлык кылса, кәффәра тиешле, ә инде мәҗбүр ителгән булса, тиеш түгел».

Имам Мәликтә һәм Әбү Юсуфта: «Хатын-кызга ир кеше кебек үк кәффәра тиешле».

Хәнәфиләрдән Әл-Кәсәний "Бәдәигъ әл-Санаигъ"та болай диде: *«Әгәр дә хатын-кыз үз теләге белән якынлык кылган булса, бездә (хәнәфиләрдә) аңа кәффәра тиешле».* Аллаһу әгъләм.

## Авырлы һәм күкрәктән бала имезүче хатын-кыз Рамазанда уразасын тотмыйча калдыра аламы?

Авырлы яки күкрәктән бала имезүче хатын-кыз әгәр дә үзе яки баласы өчен курыкса, ул вакытта Рамазан аенда уразасын калдырырга рөхсәт ителүе хакында гыйлем әһелләре арасында капма-каршылык юк.

Рамазанда уразасын калдырса, аларга каза тиешлеме? Яки аларга фидия генә тиешлеме? Яки аларга каза да һәм фидия дә тиешлеме? Әллә аларга каза да, фидия дә тиешле түгелме?

Бу мәсьәләдә гыйлем әһелләре арасында төрле карашлар барлыкка килде, һәм ул ихтиләфнең сәбәбе авырлы һәм күкрәктән бала имезүче хатыннарны «әл-Бакара» сүрәсенең 184нче аятендә килгән хасталарга яки ураза белән хәлсезләнүчеләргә охшатуда. Хасталар хөкеменә кертүчеләр каза гына тиеш диде. Ә ураза белән хәлсезләнүчеләр хөкеменә кертүчеләр кәффәра гына тиеш

диделәр. Кем бу мәсьәләдә гыйлемен арттырасы килсә, Коръән тәфсирләреннән, хөкемнәреннән һәм фикх китапларыннан карасын. Без инде кыскача гына гыйлем әһелләренең карашларын әйтеп узарбыз.

**1) Аларга каза гына тиешле.** Бу карашны Гали, Ибраһим ән-Нәхәгый, Гата бин әбий Рабәх, әл-Хәсән бин Хәй, әд-Даххәк, әз-Зүһрий, Рабийга, әл-Әүзагый, Әбү Хәнифә, Әбү Юсуф, Мөхәммәд, Зүфәр, әс-Сәүрий, Әбү Губәйд, Әбү Сәүр, ибен әл-Мүнзир һәм шулай ук хәзерге галимнәрдән Мүбәракфурий, ибен Гусаймийн һәм ибен Бәәзләр хуплады.

**2) Аларга фидия генә тиешле.** Бу караш ибен Габбас, ибен Гомәр һәм Сәгыйд бин Җубәйрдән риваять ителде.

**3) Аларга каза да, фидия дә тиешле.** Бу караш Мүҗәһид, әш-Шәфигый һәм Әхмәд бин Хәнбәлдән риваять ителде.

**4) Авырлы хатын уразаны каза гына кыла, ә күкрәктән имезүче хатын уразаны каза һәм фидия кыла.** Бу караш Мәлик һәм Ләйс бин Сәбитнеке.

**5) Каза да, фидия дә тиешле түгел.** Бу ибен Хәзмның карашы.

Мәликиләрдән ибен Рушд “Бидәя әл-Мүҗтәһид”тә болай диде: *«Ул хатыннарга кагылышлы бер хөкемне генә (каза яки кәффәра гына дип) әйтүчеләр, ике хөкемне (каза һәм кәффәраны) бергә җыючыларга караганда әүвәлрәк (дөресрәк), Аллаһу әгъләм. Шулай ук, каза гына тиешле диючеләр, кәффәра гына тиешле дип әйтүчеләргә караганда әүвәлрәк (дөресрәк). Чөнки (кәффәра гына тиешле дип әйтүчеләрнең) кыйраатлары мүтәвәтир түгел...».*

## Хатын-кыз нәфел уразасына иреннән рөхсәт сорау хакында

٥١٩٢ - حَدَّثَنَا مُحَمَّدُ بْنُ مُقَاتِلٍ أَخْبَرَنَا عَبْدُ اللهِ أَخْبَرَنَا مَعْمَرٌ عَنْ هَمَّامِ بْنِ مُنَبِّهٍ عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ عَنْ النَّبِيِّ ﷺ: «لا تَصُومُ الْمَرْأَةُ وَبَعْلُهَا شَاهِدٌ إِلا بِإِذْنِهِ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадән ﷺ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ире янында булганда хатынына аның рөхсәтеннән башка ураза тоту ярамас».***

Ибен Хәҗәр шушы ук мәгънәдә килгән Бохаридагы 5195нче хәдиснең шәрхендә: *«Күпчелек гыйлем әһелләренең әйтүенчә, бу риваять хатын-кызга (нәфел) уразасын иренең рөхсәтеннән башка тоту хәрам икәнлеген бәян итә»,* — диде. Чөнки, әгәр дә ире аның белән якынлык кылырга теләсә, хатынына иренә буйсыну фарыз була, ә инде билгеле булганча өстәмә (нәфел) уразалар тоту фарыз түгел. Шуңа да, нәфелгә караганда фарыз булган ирнең хакын үтәү әүвәлрәк. Әмма, әгәр дә фарыз уразасы булса, яки ире янында булмыйча сәфәрдә булса, әлбәттә рөхсәт сорап тору кирәкми.

## Уразада гаиләнең хакы барлыгы турында

١٩٧٥ - عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ عَمْرِو بْنِ الْعَاصِ رَضِيَ اللهُ عَنْهُمَا، قَالَ لِي رَسُولُ اللهِ ﷺ يَا عَبْدَ اللهِ أَلَمْ أُخْبَرْ أَنَّكَ تَصُومُ النَّهَارَ وَتَقُومُ اللَّيْلَ فَقُلْتُ بَلَى يَا رَسُولَ اللهِ قَالَ فَلا تَفْعَلْ صُمْ وَأَفْطِرْ وَقُمْ وَنَمْ فَإِنَّ لِجَسَدِكَ عَلَيْكَ حَقًّا وَإِنَّ لِعَيْنِكَ عَلَيْكَ حَقًّا وَإِنَّ لِزَوْجِكَ عَلَيْكَ حَقًّا وَإِنَّ لِزَوْرِكَ عَلَيْكَ حَقًّا وَإِنَّ بِحَسْبِكَ أَنْ تَصُومَ كُلَّ شَهْرٍ ثَلاثَةَ أَيَّامٍ فَإِنَّ لَكَ بِكُلِّ حَسَنَةٍ عَشْرَ أَمْثَالِهَا فَإِنَّ ذَلِكَ صِيَامُ الدَّهْرِ كُلِّهِ فَشَدَّدْتُ فَشُدِّدَ عَلَيَّ قُلْتُ يَا رَسُولَ اللهِ إِنِّي أَجِدُ قُوَّةً قَالَ فَصُمْ صِيَامَ نَبِيِّ اللهِ دَاوُدَ عليه السلام وَلَا تَزِدْ عَلَيْهِ قُلْتُ وَمَا كَانَ صِيَامُ نَبِيِّ اللهِ دَاوُدَ عليه السلام قَالَ نِصْفَ الدَّهْرِ فَكَانَ عَبْدُ اللهِ يَقُولُ بَعْدَ مَا كَبِرَ يَا لَيْتَنِي قَبِلْتُ رُخْصَةَ النَّبِيِّ ﷺ [ البخاري ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гамр бин әл-Гастан ﵁: *«Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ миңа әйтте:* ***«Йә Габдаллаһ! Син көндезе белән ураза тотасың һәм төннәрен кыям торасың дип миңа хәбәр иттеләр?».*** *Мин әйттем: «Әйе, шулай, йә Расүл Аллаһ!». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Алай эшләмә! Әмма ураза тот һәм (вакыты белән) тотма! Төннәрен кыям тор һәм йокла! Хакыйкатьтә, синең тәнеңнең синдә хакы бар, һәм күзләреңнең синдә хакы бар, һәм хатыныңның синдә хакы бар, һәм кунагыңның синдә хакы бар! Хакыйкатьтә, син аена өч көн ураза тотсаң, җитә. Чөнки һәрбер изгелек өчен син унлата арттырып аласың, һәм син бертуктаусыз ураза тоткан кебек буласың!»[6].*** *Ләкин мин (Габдуллаһ бин Гамр) катгый таләпчән булдым, һәм шуның өчен дә карт көнемдә авырлык сиздем, һәм пәйгамбәребезгә ﷺ әйттем: «Йә Расүл Аллаһ! Мин үземдә (күбрәк) көч сизәм». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Алайса Давыд ﵇ кебек ураза тот һәм шуннан арттырма!».*** *Мин сорадым: «Давыд ﵇ ничек ураза тота иде?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Көн аралаш».*** *Габдуллаһ бин Гамр картайгач әйтә торган иде: «Эх, әгәр дә мин расүлебезнең ﷺ рөхсәтен кабул иткән булсамчы?!».*

## Ураза хәлендә һәм башка вакытларда да гайбәтләрдән саклану хакында

Хакыйкатьтә, Аллаһ тәгалә мөэминнәрне бер-берсен гайбәт кылудан тыйды һәм болай диде:

(...وَلا يَغْتَبْ بَعْضُكُمْ بَعْضًا أَيُحِبُّ أَحَدُكُمْ أَنْ يَأْكُلَ لَحْمَ أَخِيهِ مَيْتًا فَكَرِهْتُمُوهُ وَاتَّقُوا اللَّهَ إِنَّ اللَّهَ تَوَّابٌ رَحِيمٌ) الحجرات: ١٢

6 Әгәр дә кеше аена өч көн — һиҗри тәкъвим буенча 13, 14, 15 — ураза тотса, аның һәр көне ун көнгә тиң була, вә шулай итеп өч көн утыз көнгә яки бер айга тиңләнә. Һәм ул кеше ел буе ягъни бертуктаусыз ураза тоткан кебек була, Аллаһу әгъләм

Мәгънәсе: «**Вә бер-берегезне гайбәт кылмагыз! Әллә сезнең берәрегез үлгән кардәшенең итен ашауны сөярме? Сез, әлбәттә, аны сөймисез, гайбәт сөйләүдән дә шулай сакланыгыз! Аллаһка тәкъва булыгыз, гайбәт эшләреннән тәүбә итегез! Шиксез Аллаһ тәүбә итеп төзәлгән кешеләрне гафу итүче вә рәхимле».**

Гайбәтнең төшенчәсен пәйгамбәребез ﷺ үзенең хәдис-шәрифендә болай дип аңлатты:

٢٥٨٩ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رَضِي الله عَنْهُ أَنَّ رَسُولَ اللهِ ﷺ قَالَ: «أَتَدْرُونَ مَا الْغِيبَةُ؟» قَالُوا: الله وَرَسُولُهُ أَعْلَمُ، قَالَ: «ذِكْرُكَ أَخَاكَ بِمَا يَكْرَهُ» قِيلَ: أَفَرَأَيْتَ إِنْ كَانَ فِي أَخِي مَا أَقُولُ؟ قَالَ: «إِنْ كَانَ فِيهِ مَا تَقُولُ، فَقَدْ اغْتَبْتَهُ، وَإِنْ لَمْ يَكُنْ فِيهِ، فَقَدْ بَهَتَّهُ» [ مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадән ؓ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Гайбәтнең нәрсә икәнен беләсезме?».*** *Әйттеләр: «Аллаһ һәм Аның илчесе яхшырак беләдер». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Үзеңнең кардәшеңне ул яратмаган нәрсә белән искә алу».*** *Әйтелде: «Әгәр дә әйтелгән нәрсәләр, ул кардәшебездә чынлап та булса?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Әгәр дә аңарда син әйткән нәрсәләр булса — гайбәт кылдың. Ә инде әгәр дә аңарда син әйткән нәрсәләр булмаса — ялган кылдың».***

Гайбәт кылу мөселман кешесенең сыйфаты түгел, шуның өчен дә Аллаһ тәгалә Коръәндә һәм пәйгамбәребез ﷺ үзенең хәдисләрендә бу хакта бик күп кисәтеп узды. Кәферләр җир йөзендә бозыклык таратыр өчен, кабахәт эшләрне матурлап мөэминнәрне төрле яклап гайбәт кылалар. Шулай ук, мөэминнәр арасында үзләрен мөселман дип йөргән кайбер бәндәләр дә, әгәр дә ул берәү янында булса — аны яхшы итеп сыйфатлый, ә ул юкта — аның хакында фәлән вә төгән дип гайбәт сөйли башлый. Бу төр кешеләр монафиклар кебек ике йөзлеләр, һәм шул кадәр түбән кешеләр ки, үзләренең файдалары өчен хәтта үләксә ашарга да әзерләр. Бу кисәтүләр, гомуми ураза хәлендә булмаган кешегә кагылса, ә ураза тотучы хакында әйтеп тә торасы юк, Аллаһу мүстәган. Йә Раббым, безне ошбу кабахәт сыйфаттан пакьлә!

# ИГЪТИКӘФ БҮЛЕГЕ

## Рамазанның соңгы ун көнендә ир кеше үзенең гаиләсен төнге гыйбадәткә уяту хакында

٢٠٢٤ - عَنْ عَائِشَةَ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهَا قَالَتْ: «كَانَ النَّبِيُّ ﷺ إِذَا دَخَلَ الْعَشْرُ شَدَّ مِئْزَرَهُ وَأَحْيَا لَيْلَهُ وَأَيْقَظَ أَهْلَهُ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Гаишә ﵂ әйтте: ***«Әгәр дә Рамазанның соңгы ун көне җитсә, пәйгамбәребез ﷺ үзенең изарын ныграк тарттырып бәйли иде (ягъни хатыннарыннан читләшеп тагын да ныграк гыйбадәт кыла иде), һәм төннәрен гыйбадәттә үткәреп, үзенең гаиләсен дә төнге намазга уята иде».***

## Шәригатебездә хатын-кызларга игътикәфнең рөхсәт ителүе хакында

٢٠٢٦ - عَنْ عَائِشَةَ رَضِيَ اللهُ عَنْهَا زَوْجِ النَّبِيِّ ﷺ أَنَّ النَّبِيَّ ﷺ كَانَ يَعْتَكِفُ الْعَشْرَ الْأَوَاخِرَ مِنْ رَمَضَانَ حَتَّى تَوَفَّاهُ اللهُ ثُمَّ اعْتَكَفَ أَزْوَاجُهُ مِنْ بَعْدِهِ [ البخاري ]

Мәгънәсе: Гаишә ﵂ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ вафат булганчыга кадәр, Рамазанның соңгы ун көнен (мәчеттә) игътикәфтә үткәрә иде. Ул вафат булганнан соң, аның хатыннары да игътикәф кыла торган булдылар».***

# Хатын-кызның игътикәф кылырга иреннән рөхсәт соравы хакында

Хатын-кызга иреннән рөхсәт алмыйча игътикәф кылырга ярамый. Ни өчен дигәндә, чөнки асылда хатын-кыз өйдән иренең рөхсәте белән генә чыга ала. Шулай ук, пәйгамбәребезнең ﷺ хатыннары игътикәф кылырга теләгәндә, расүлебездән рөхсәт сорый торган иделәр.

Әгәр дә ире хатынына рөхсәт итсә, ул хатынын күпмедер вакыттан соң игътикәфтән чыгара аламы, әллә юкмы?

Игътикәф нәфел булса, ире хатынын игътикәфтән чыгара ала. Ә инде әгәр дә игътикәф вәҗиб булса (мәсәлән нәзер кебек) ул вакытта нәзернең ниндилегенә карала. Тәгаенләп тоташ әйтелгән нәзер булса (мәсәлән: Рамазанның соңгы ун көнен игътикәф кылырга нәзер иттем, дигән кебек), ире аны игътикәфтән чыгара алмый. Тәгаенләп тоташ әйтелмәгән булса (мәсәлән: Бу елда 10 көн игътикәф кылырга нәзер иттем, дигән кебек), ул вакытта ире аны игътикәфтән чыгара ала. Һәм калган көннәрен соңыннан игътикәф кылып бетерә, Аллаһу әгъләм.

٢٠٤٥ - عَنْ عَائِشَةَ رَضِيَ اللهُ عَنْهَا أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ ذَكَرَ أَنْ يَعْتَكِفَ الْعَشْرَ الْأَوَاخِرَ مِنْ رَمَضَانَ فَاسْتَأْذَنَتْهُ عَائِشَةُ فَأَذِنَ لَهَا وَسَأَلَتْ حَفْصَةُ عَائِشَةَ أَنْ تَسْتَأْذِنَ لَهَا فَفَعَلَتْ فَلَمَّا رَأَتْ ذَلِكَ زَيْنَبُ ابْنَةُ جَحْشٍ أَمَرَتْ بِبِنَاءٍ فَبُنِيَ لَهَا قَالَتْ وَكَانَ رَسُولُ اللهِ ﷺ إِذَا صَلَّى انْصَرَفَ إِلَى بِنَائِهِ فَبَصُرَ بِالْأَبْنِيَةِ فَقَالَ مَا هَذَا قَالُوا بِنَاءُ عَائِشَةَ وَحَفْصَةَ وَزَيْنَبَ فَقَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ أَالْبِرَّ أَرَدْنَ بِهَذَا مَا أَنَا بِمُعْتَكِفٍ فَرَجَعَ فَلَمَّا أَفْطَرَ اعْتَكَفَ عَشْرًا مِنْ شَوَّالٍ [ البخاري ]

Мәгънәсе: Гаишә әйтте: *«Пәйгамбәребез ﷺ Рамазанның соңгы ун көнен игътикәф кылырга теләгәч, Гаишә дә игътикәф кылырга дип аннан рөхсәт сорады. Пәйгамбәребез ﷺ аңа рөхсәт итте. Хафса (пәйгамбәребезнең хатыны, Гаишәнең игътикәф кылганын күреп) Гаишәдән рөхсәт сорарга кушты, һәм ул Хафсага рөхсәт итте. Зәйнәб бинт Җәхш (пәйгамбәребезнең хатыны) бо-*

*ларны күреп, шулай ук (игътикәфкә дип, мәчеттә) үзенең чатырын куйды».* Гаишә (дәвам итеп) әйтте: *«Гадәттә (игътикәф вакытында) пәйгамбәребез ﷺ намаз укыгач, үзенең чатырына юнәлә иде. Анда башка чатырларны күреп сахәбәләрдән:* ***«Бу нәрсә?»,*** *— дип сорады. Әйттеләр: «Бу Гаишәнең, Хафсаның һәм Зәйнәбнең чатырлары». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Алар бу гамәлләрне диндарлыктан эшләделәр дип уйлыйсызмы?***[7]***. Мин игътикәф кылучы түгелмен».*** *Һәм пәйгамбәребез ﷺ Рамазанда игътикәфен кылмыйча, соңыннан Шәүвәлдә ун көн игътикәф кылды».*

Моннан күренгәнчә, хатын-кыз иренең рөхсәте белән игътикәф кыла ала. Шулай ук бу хәдис, хатын-кызлар игътикәфне ирләр кебек үк мәчеттә кылганлыгын бәян итә. Моңа Коръәннән ошбу аятьне дә дәлил итеп китерергә мөмкин:

(وَأَنْتُمْ عَاكِفُونَ فِي الْمَسَاجِدِ) البقرة ١٨٧

Мәгънәсе: **«Һәм сез мәчетләрдә игътикәфтә булган вакытларыгызда...».**

Бу аятьтән аңлашылганча игътикәф мәчеттә була, һәм хатыннар үзләренең йортларында игътикәф кылырга тиеш дип, аларга карата махсус килгән дәлил билгеле түгел. Шулай ук, пәйгамбәребез ﷺ вакытында да хатыннар йортларында игътикәф кылган дип килгән хәдисләр юк, ә киресенчә, ул вакытта да вә аннан соң да хатын-кызлар мәчеттә игътикәф кыла торган булганнар. Шуңа да кем дә кем, булсын ир-ат яки хатын-кыз, сөннәт буенча игътикәф кылырга тели икән, мәчеттә кылсын. Әгәр дә хатын-кыз мәчеттә игътикәф кыла икән, ул пәйгамбәребез хатыннары кебек чатыр яки шуңа охшаш әйбер белән чит кешеләрдән капланырга, һәм ул бүлмәдә намаз укучыларга комачауламаслык урынга урнашырга тиеш. Истихада хәлендә булган хатын-кыз да шушы ук хөкемдә, ягъни

---

7 Пәйгамбәребез ﷺ хатыннарының бу гамәлләрен бер-берсенә көнчелектән эшләгәннәрен күздә тотты

мәчеттә башкалар белән үк игътикәф кыла ала. Аллаһу әгъләм.

Әбү Хәнифә, Суфиян әс-Сәүрий һәм Шәфигый (кадимдә) хатын-кызның өендә игътикәф кылуы хәерлерәк диделәр.

Мәлик, Әхмәд бин Хәнбәл һәм Шәфигый (яңасында), хатын-кызның йортында игътикәф кылуы дөрес түгел, иллә-мәгәр җәмәгать намазы укыла торган мәчеттә генә кыла, диделәр.

## Хайд хәлендә булган хатын-кыз мәчеттә игътикәф кыламы?

Бу мәсьәләдә гыйлем әһелләре ике төрле карашка бүленделәр:

**1)** Дүрт мәзһәб имамнары хайд хәлендә булган хатын-кыз игътикәф кыла алмый, яки аңа мәчеттә игътикәф кылу дөрес түгел диделәр.

**2)** Ибен Хәзм хайд хәлендә булган хатын-кызның игътикәф кылуы дөрес була диде. Без дә бу карашны дөресрәк дип күрәбез һәм түбәндә сезгә ике тарафның да дәлилләрен китереп үтәрбез, иншәАллаһ.

**Хайд хәлендә булган хатын-кызның игътикәф кылуы дөрес яки дөрес түгеллеге ике мәсьәләгә бәйле:**

**Беренчесе:** Игътикәф кылучының уразада булуы шартмы, әллә түгелме?

**Икенчесе:** Хайд хәлендә булган хатын-кызга мәчеткә керергә ярыймы, әллә юкмы?

Игътикәф кылучының уразада булуы шарт диючеләр, хайд хәлендәге хатын-кыз ураза тотмый, шуңа да игътикәф кылуы дөрес түгел диделәр.

Шулай ук, хайд хәлендә булган хатын-кызга мәчеткә керергә ярамый диючеләр, игътикәф тә ярамый диделәр.

Без инде хәзер ошбу ике мәсьәләне ачыклап үтәрбез, иншәАллаһ:

**<u>Беренче:</u>** Игътикәф кылу өчен ураза тоту шарт түгел. Һәм моңа Бохарида килгән ошбу хәдисне дәлил итеп алырга була:

٢٠٣٢ - عَنْ ابْنِ عُمَرَ رَضِيَ اللهُ عَنْهُمَا أَنَّ عُمَرَ رَضِي الله عَنْهُ سَأَلَ النَّبِيَّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ قَالَ: «كُنْتُ نَذَرْتُ فِي الْجَاهِلِيَّةِ أَنْ أَعْتَكِفَ لَيْلَةً فِي الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ؟» قَالَ: «فَأَوْفِ بِنَذْرِكَ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Ибен Гомәр ﵁ әйтте: *«Бервакыт Гомәр ﵁ пәйгамбәребезнән ﷺ сорады: «Мин җәһилияттә вакытта бер төн (3144нче хәдистә бер көн дип килә) Хәрам мәчетендә игътикәф кылырга дип нәзер кылган идем ул нәзерне мин үтәргә тиешме?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Нәзереңне үтә!».***

Шушы ук мәгънәдәге хәдис Бохариның “Сахих”ында 2042, 2043, 3144, 4320, 6697нче саннар белән килә.

**<u>Икенче:</u>**

**1)** Хайд хәлендә булган хатын-кызга мәчеткә керү дөрес түгел диючеләр, күремле хатын-кызны җөнебле кешегә кыяс (охшату, тиңләү) кылдылар һәм ошбу аятьне китерделәр:

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لا تَقْرَبُوا الصَّلاةَ وَأَنْتُمْ سُكَارَى حَتَّى تَعْلَمُوا مَا تَقُولُونَ وَلا جُنُبًا إِلا عَابِرِي سَبِيلٍ حَتَّى تَغْتَسِلُوا) النساء: ٤٣

Мәгънәсе: **«Әй, мөэминнәр! Исерткеч эчеп исереп, ни сөйләгәнегезне белмәсәгез, намазга (салә) якын бармагыз! (Ул вакытта хәмер хәрам түгел иде, шул сәбәпле кайберәүләр исерек хәлдә намаз укып, аятьне хата белән укыдылар.) Янә җөнеб хәлдә госел коенганчыга кадәр намазга якын бармагыз, иллә мәгәр озын сәфәрдә булсагыз гына».**

Бу аятьтә **«намаз (салә)»** дип әйтелгән сүзнең максаты — ул намаз уку урыны, ягъни мәчет. Җөнеб хәлендә булган

кеше анда керүдән тыелды, иллә-мәгәр мосафир булса гына аның аша узып китү рөхсәт ителә диделәр. Һәм бу аятьтә **«намаз»** дигән сүзнең мәчет яки намаз уку урыны булуын аңлаткан, икенче аять белән дәлилләделәр:

(لَهُدِّمَتْ صَوَامِعُ وَبِيَعٌ وَصَلَوَاتٌ وَمَسَاجِدُ) الحج: ٤٠

Мәгънәсе: **«Монахларның саумагалары, насараларның чиркәүләре, яһүдләрнең гыйбадәт йортлары (саләват) вә мөселманнарның мәчетләре җимерелер иде».**

Бу аятьтә **«саләват»** җимерелер дигәннең мәгънәсе: Саләватнең (намазның) урыннары булган биналар җимерелер, диделәр.

Аларның бу аятьтә күремле хатын-кызны җөнеб хәлендәге кешегә кыяс кылулары зәгыйфь. Чөнки җөнеб хәлендә булган кеше һәрвакыт госел коенып пакьләнә ала, һәм бу аять җөнеб хәлендәге кешене озакка кичектермичә, тизрәк госел коенып пакьләнергә өнди. Ә инде хайд хәлендәге хатын-кыз күрем вакыты узмыйча госел коенып пакьләнә алмый.

**2)** Хайд хәлендәге хатын-кызны мәчеткә керүдән тыючылар, Бохаридагы 351нче хәдисне дәлил итеп китерделәр. Пәйгамбәребез ﷺ барча хатын-кызларга да ике гаед бәйрәменә чыгарга кушкач, күрем хәлендә булган хатын-кызларга мусалләдән (намаз уку урыныннан) читләшергә кушты.

Моңа болай итеп җавап бирергә мөмкин: Бу хәдистә **«мусаллә»**нең (намаз уку урынының) максаты — намаз үзе, ягъни пәйгамбәребез ﷺ намаздан тыйды. Чөнки Мөслимдә шул ук Үммү Гатыядан килгән 890нчы хәдистә намаздан тыелырга кушты диде. Шулай ук, гаед намазын алар мәчеттә түгел, ә сахрада укый торган иделәр. Һәм Бохариның вә Мөслимнең икенче риваятендә күремле хатын-кызлар, намаз укучы кешеләргә комачауламас өчен, аларның артында булырга кушылдылар. Кешеләр артын-

да дигән, ул мусалләнең (намаз укый торган урынның) тышкы ягында дигән сүз түгел.

**3)** Шулай ук, алар Бохаридагы 2046нчы һәм Мөслимдәге 297нче хәдисне китерделәр. Бу хәдистә пәйгамбәребез ﷺ мәчеттә игътикәф вакытында башын Гаишәнең бүлмәсенә якынайта иде, һәм Гаишә күрем хәлендә булган килеш, мәчеткә кермичә пәйгамбәребезнең ﷺ чәчен тарый торган иде.

Әмма ләкин бу хәдис, күрем хәлендәге хатын-кызның мәчеткә керүен тыюда ачык дәлил түгел, чөнки мәчеттә чит ир-атлар булу мөмкинлегеннән, пәйгамбәребез ﷺ Гаишәнең алардан читләшүен теләгән булуы мөмкин, Аллаһу әгъләм.

**4)** Әбү Дауыдта 232нче сан белән килгән: ***«...Хакыйкатьтә, мин җөнеб һәм хайд хәлендә булганнарны мәчеттән тыям»,*** — дигән хәдис, зәгыйфь.

**Хайд хәлендә булган хатын-кызның игътикәф кылуы дөрес диючеләрнең дәлилләре:**

**1)** Күрем хәлендә булган хатын-кызны мәчеттән тыеп килгән ачык дәлил билгеле түгел.

**2)** Бохарида 439нчы һәм 458нче хәдисләрдә күренгәнчә, хатын-кызның мәчеттә торуы, йоклавы дөрес. Һәм, әлбәттә, хатын-кызның билгеле вакытта күреме була, ләкин моңа карамастан пәйгамбәребез ﷺ вакытында Исламны кабул иткән кара хатын-кыз колның мәчеттә үзенең билгеле чатыры бар иде.

**3)** Бохаридагы 305нче хәдис. Мәгънәсе: Гаишә әйтте: *«Без хаҗ нияте белән чыктык, Сәрифкә җиткәч, минем күрем башланды. Пәйгамбәребез ﷺ минем янга кергәч, елап утырганымны күреп сорады:* ***«Нәрсә булды сиңа? Синең күрем башландымы?».*** *Мин әйттем: «Әйе». Шуннан соң ул әйтте:* ***«Хакыйкатьтә, бу Аллаһ тәгаләнең Адәм кызларына язылган тәкъдире, хаҗ кылучы эшли торган барча***

***нәрсәләрне дә эшлә, әмма ләкин Кәгъбә тирәли таваф кылма!».***

Бу хәдистән күренгәнчә, пәйгамбәребез ﷺ Гаишәне мәчеткә керүдән түгел, ә тавафтан тыйды.

**4)** Бохаридагы 285нче һәм Мөслимдәге 371нче хәдис-тә, пәйгамбәребез ﷺ ***«...Хакыйкатьтә, мөэмин нәҗес бул-мый»,*** — диде.

**5)** Шулай ук, пәйгамбәребез ﷺ әсирлеккә алган мөшрикләрне мәчеттәге баганага бәйләргә куша иде. Бу хәдисләр Бохарида 462, 469, 2422, 2423, 4372нче һәм Мөслимдә 1764нче саннар белән килә. Әгәр дә мөшрик мәчеткә керә икән, күрем хәлендәге мөселман хатыны мәчеткә керүдә аннан әүвәлрәк. Чөнки Әбү Хәнифәдә мөшрик гозерле булганда мәчеткә керә ала. Мәликтә һәм Шәфигыйда Хәрам мәчетеннән башкаларга керә ала, мәгәр Мәлик башка мәчетләргә мөшрикнең керүен берәр төрле хаҗәте булган хәлдә генә рөхсәт ителә дип шарт куйды. Бу мәсьәләдә, әлбәттә, каршылыклы фикерләр күп, чөнки кайбер гыйлем әһелләре мөшрик вә кәферләрнең барча мәчеткә дә керүләрен тыйды. Әмма ләкин безгә кирәк булган мәсьәлә ул, Әбү Хәнифә, Мәлик һәм Шәфигыйлар мөшрикнең мәчеткә керүен рөхсәт итәләр икән, әйткәнебезчә мөселман хатын-кызы хайд булган хәлендә мәчеткә керүе әүвәлрәк.

Инде ошбуларны караганнан соң, хайд хәлендә булган хатын-кызның мәчеттә игътикәф кылырга яраганын дөресрәк дип күрәбез. Аллаһу әгъләм.

# ХАҖ
# һәм
# ГУМРА

## Хажның ирләргә дә, хатын-кызларга да фарызлыгы хакында

(وَلِلَّهِ عَلَى النَّاسِ حِجُّ الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ إِلَيْهِ سَبِيلا) آل عمران: ٩٧

Мәгънәсе: **«Мөмкинчелеге булган кешеләргә Аллаһка гыйбадәт өчен Кәгъбәтуллага хаж кылу фарыз ителде».**

٨ - حَدَّثَنَا عُبَيْدُ اللهِ بْنُ مُوسَى قَالَ أَخْبَرَنَا حَنْظَلَةُ بْنُ أَبِي سُفْيَانَ عَنْ عِكْرِمَةَ بْنِ خَالِدٍ عَنْ ابْنِ عُمَرَ رَضِيَ اللهُ عَنْهُمَا قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «بُنِيَ الإِسْلَامُ عَلَى خَمْسٍ شَهَادَةِ أَنْ لا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَأَنَّ مُحَمَّدًا رَسُولُ اللهِ وَإِقَامِ الصَّلاةِ وَإِيتَاءِ الزَّكَاةِ وَالْحَجِّ وَصَوْمِ رَمَضَانَ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гомәрдән ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ислам биш нигезгә төзелгән: Хакыйкатьтә, «Аллаһтан башка иләһ юк, һәм Мөхәммәд ﷺ Аның расүле», — дип шәһәдәт кылу; намазны торгызу; зәкәт бирү; хаж кылу һәм Рамазанда ураза тоту».***

## Хатын-кызларның иң хәерле җиһәде – хаж

١٥٢٠- حَدَّثَنَا عَبْدُ الرَّحْمَنِ بْنُ الْمُبَارَكِ حَدَّثَنَا خَالِدٌ أَخْبَرَنَا حَبِيبُ بْنُ أَبِي عَمْرَةَ عَنْ عَائِشَةَ بِنْتِ طَلْحَةَ عَنْ عَائِشَةَ أُمِّ الْمُؤْمِنِينَ رَضِيَ اللهُ عَنْهَا أَنَّهَا قَالَتْ يَا رَسُولَ اللهِ نَرَى الْجِهَادَ أَفْضَلَ الْعَمَلِ أَفَلا نُجَاهِدُ قَالَ: «لا لَكِنَّ أَفْضَلَ الْجِهَادِ حَجٌّ مَبْرُورٌ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Гаишә әйтте: *«Йә Расүл Аллаһ! Без җиһәдне иң яхшы гамәл дип беләбез, бәлки без дә җиһәдтә катнашыйк?».* Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Юк! Сезгә иң хәерле җиһәд — ул, кабул булган хаж!».***

## Хатын-кыз хаҗга барыр өчен иреннән рөхсәт сорарга тиешме?

Хаҗ берничә төрле:

1) Фарыз хаҗ;

2) Нәфел хаҗ;

3) Нәзер хаҗ;

4) Башка кеше өчен булган хаҗ.

– Нәфел белән башка кеше өчен булган хаҗда, ул иреннән рөхсәт сорарга тиеш. Һәм ире хатынын бу хаҗлардан тыя ала.

– Нәзер хаҗын әгәр дә иренең рөхсәте белән әйткән булса, ире тыя алмый. Шулай ук, әгәр дә кияүгә чыкканчы хаҗ кылырга нәзер кылган булса һәм кияүгә чыкканда иренә моны хәбәр итеп, ире аңа ризалашкан булса, хатынын хаждан тыя алмый. Ә инде ире ризалыгын бирмәгән килеш нәзер кылган булса, ире хатынын хаждан тыя ала. Чөнки, ире — хатыны белән теләгән вакытында ләззәтләнү хуҗасы.

– Фарыз хаждан ире хатынын тыя алмый. Әмма ләкин хатыны иреннән рөхсәт сорарга тиешме, әллә юкмы?

Бер төркем гыйлем әһелләре хатын-кыз фарыз хаҗга иреннән рөхсәт сорарга тиеш түгел дисә, икенчеләре рөхсәт сорарга тиеш диде. Бу мәсьәлә кешенең мөмкинчелеге булгач, ул хаҗны шул ук вакытта кылырга тиешме, әллә киләсе елларга кичектерсә дә ярыймы дигәнгә бәйле. Безгә дөресрәк дип күренгәне, Аллаһу әгъләм, әгәр дә хатын-кызның хаҗ кылыр өчен сәламәтлеге, мәхрәме, юлның иминлеге, акчасы (юлга һәм ашарга) бар икән, иреннән сорап, ул рөхсәт итсә, әлхәмдүлилләһ. Әгәр дә ире бер төрле аклый торган мөһим сәбәп белән тыя икән, хатын-кыз хаҗын киләсе елга кичектерә, ә инде аклый торган мөһим сәбәп булмаса, иренең рөхсәтеннән башка

хаҗга китә. Шулай ук, аклый торган сәбәп ел да кабатланып килсә, ул вакытта алдагы елга кичектермичә хаҗга китә. Әйтүебезчә, хатын-кыз ошбу очракларда иренең рөхсәтеннән башка хаҗга бара ала, әгәр дә югарыда искә алынган; сәламәтлеге, мәхрәме, юлның иминлеге, акчасы булуы кебек шартлар үтәлсә генә.

Түбәндә кайбер гыйлем әһелләренең сүзләрен искә алып үтәрбез:

عن إبراهيم قال: «إذا كانت الفريضة وكان لها محرم، فلا بأس أن تخرج ولا تستأذن زوجها» [ مصنف ابن أبي شيبة، صحيح عن إبراهيم ]

Мәгънәсе: Ибраһим ән-Нәхәгый әйтте: ***«Әгәр дә фарыз хаҗ һәм аның (хатын-кызның) мәхрәме булса, иренең рөхсәтеннән тыш хаҗга чыгып китсә, бер зарар да юк».***

عن الحسن في المرأة التي لم تحج قال: «تستأذن زوجها فإذا أذن لها فذاك أحب إلي، وإن لم يأذن لها خرجت مع ذي محرم ، فإن ذلك فريضة من فرائض الله ليس له عليها فيها طاعة» [ مصنف ابن أبي شيبة، صحيح عن الحسن ]

Мәгънәсе: Әл-Хәсән хаҗ кылмаган хатын-кыз хакында болай диде: ***«Иреннән рөхсәт сорый, әгәр дә ире рөхсәт итсә, бу минем өчен сөйкемлерәк. Ә инде рөхсәт итмәсә, ул вакытта мәхрәме белән чыгып китә, чөнки хаҗ Аллаһ тәгалә йөкләгән фарызларның берсе, һәм бу очракта иренә итагать кылу юк».***

Хәнәфиләрдән Мөхәммәд әс-Сәрхасий "әл-Мәбсут"та болай диде: *«Әгәр дә хатын-кыз мәхрәме булып фарыз хаҗын кылырга тели икән, ире аны хаҗга барудан тыя алмый».*

Ибен Кудамә "әл-Мугъний"дә болай диде: *«Ир кеше хатынын фарыз хаждан тыя алмый. Бу Ибраһим ән-Нәхәгый, Исхак, Әбү Сәүрның карашлары. Шулай ук, Шәфигыйдан билгеле булган мәшһүр карашларның берсе, аның икенче карашы буенча ир кеше хатынын тыя ала, чөнки ул хаҗны мөмкинчелеге булу белән шул ук вакытта кылырга тиеш түгел, бәлки киләсе елга кичектерсә дә ярый. Бездә билгеле булганча, ир кеше хатынын Рамазанда уразадан яки*

*биш вакыт намаздан тыя алмаган кебек, фарыз хаждан да тыя алмый, ләкин иреннән рөхсәт сорау мөстәхәб. Имам Әхмәд моны шулай ук билгеләп үтте. Әгәр дә ире рөхсәт итә икән — яхшы, ә инде рөхсәт итми икән — фарыз хаҗга рөхсәтсез чыгып китә. Ә инде нәфел хаҗында ире хатынын тыя ала».*

## Хатын-кызның мәхрәмсез яки ирсез сәфәргә чыгарга ярамаганлыгы хакында кайбер хәдисләр

١٨٦٢- عَنْ ابْنِ عَبَّاسٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُمَا قَالَ: قَالَ النَّبِيُّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ: «لا تُسَافِرْ الْمَرْأَةُ إِلا مَعَ ذِي مَحْرَمٍ وَلا يَدْخُلُ عَلَيْهَا رَجُلٌ إِلا وَمَعَهَا مَحْرَمٌ». فَقَالَ رَجُلٌ: يَا رَسُولَ اللهِ إِنِّي أُرِيدُ أَنْ أَخْرُجَ فِي جَيْشِ كَذَا وَكَذَا وَامْرَأَتِي تُرِيدُ الْحَجَّ؟ فَقَالَ: «اخْرُجْ مَعَهَا» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Ибен Габбастан ؓ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хатын-кыз мәхрәмсез сәфәр кыла алмый, һәм аның янына да мәхрәмсез чит кеше керә алмый».*** Шуннан соң бер ират әйтте: *«Йә Расүл Аллаһ! Мин шундый-шундый гаскәр белән җиһәдкә чыгасым килә, ә хатынымның хаҗ кыласы килә?».* Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хатының белән бар!».***

١٠٨٦ - عَنْ ابْنِ عُمَرَ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمَا أَنَّ النَّبِيَّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «لا تُسَافِرْ الْمَرْأَةُ ثَلَاثَةَ أَيَّامٍ إِلا مَعَ ذِي مَحْرَمٍ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Ибен Гомәрдән ؓ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хатын-кыз мәхрәмсез өч көнлек сәфәргә чыга алмый».***

١٠٨٨ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ ؓ قَالَ: قَالَ النَّبِيُّ ﷺ: «لا يَحِلُّ لِامْرَأَةٍ تُؤْمِنُ بِاللهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ أَنْ تُسَافِرَ مَسِيرَةَ يَوْمٍ وَلَيْلَةٍ لَيْسَ مَعَهَا حُرْمَةٌ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ؓ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһка һәм Кыямәт көненә иман китергән хатын-кызга мәхрәмсез бер көн вә бер төн озынлыгындагы сәфәргә чыгу ярамас».***

**Кем ул мәхрәм?**

**Мәхрәм** — ул, хатынның ире, яки нәсел-нәсәб сәбәпле[8] яки бер күкрәктән имеп туганлашкан сәбәпле[9] яки өйләнеп вә кияүгә чыгып туганлашкан сәбәпле[10] беркайчан да вә бервакытта да никахлашырга ярамаган һәм никахлашырга хәрам булган кешеләр **мәхрәм** дип аталалар.

## Хаҗга ихрамланган хатын-кызга никаб яки бияләй кебек нәрсәләр кияргә ярыймы?

١٨٣٨ - عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ عُمَرَ رَضِيَ اللهُ عَنْهُمَا قَالَ قَامَ رَجُلٌ فَقَالَ: يَا رَسُولَ اللهِ مَاذَا تَأْمُرُنَا أَنْ نَلْبَسَ مِنْ الثِّيَابِ فِي الْإِحْرَامِ؟ فَقَالَ النَّبِيُّ ﷺ: «لا تَلْبَسُوا الْقَمِيصَ وَلا السَّرَاوِيلَاتِ وَلا الْعَمَائِمَ وَلا الْبَرَانِسَ إِلاَّ أَنْ يَكُونَ أَحَدٌ لَيْسَتْ لَهُ نَعْلَانِ فَلْيَلْبَسْ الْخُفَّيْنِ وَلْيَقْطَعْ أَسْفَلَ مِنْ الْكَعْبَيْنِ وَلا تَلْبَسُوا شَيْئًا مَسَّهُ زَعْفَرَانٌ وَلا الْوَرْسُ، وَلا تَنْتَقِبْ الْمَرْأَةُ الْمُحْرِمَةُ وَلا تَلْبَسْ الْقُفَّازَيْنِ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гомәр ؓ әйтте: *«Бервакыт бер кеше пәйгамбәребездән ﷺ сорады: «Йә Расүл Аллаһ! Ихрамда чакта безгә нәрсә кияргә кушасың?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Күлмәк тә, ыштан-чалбар да, чалма да, бурнус та, зәгъфранга яки уәрска[11] буялган киемнәрне дә кимәгез! Иллә-мәгәр берәрсенең җиңел аяк киеме (сандалы) булмаса, ул вакытта читекне тубыктан аскы өлешеннән кисеп кисен. Шулай ук, ихрамдагы хатын-кыз никаб вә бияләй***

8 - Әтиләр һәм бабалар (әти-әнисе ягыннан)

- Угыллар, угылларның һәм кызларның уллары (шулай ук, аска таба нәсел-нәсәб төшсә)

- Абый-энеләр (булсын бертуган яки әти-әни яклап)

- Абый-энеләрнең һәм кыз-сеңелләрнең уллары

9 Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Нәсел-нәсәб тыюлары, бер күкрәктән имеп туганлашканнарны да тыя»***

10 Ирнең әтисе, бабалары, малае, оныклары яки кызының һәм оныкларының ирләре кебек

11 Сары төс бирә торган, хуш исле үсемлек

***(яки перчатка) кимәсен!».*** (Билгеле булганча хатын-кызларга күлмәк вә ыштан-чалбар кебек киемнәр кию рөхсәт ителә).

Соңгы җөмлә пәйгамбәребезнең ﷺ сүземе әллә ибен Гомәрнекеме икәнлегендә гыйлем әһелләре арасында капма-каршылыклы карашлар барлыкка килде. Әбү Гали әл-Хәфиз "Сүнән әл-Бәйһәкый"да, ибен Хәҗәр "Фәтх әл-Бәрий"дә, ибен Гадий һәм башкалар бу сүзләр ибен Гомәрнеке диделәр. Хәнәфиләрдә никаб биткә тиеп тормаса кияргә ярый. Һәм шулай ук кайбер Шәфигыйләр һәм Мәликиләр ихрамдагы хатын-кызга никаб киюне рөхсәт итсәләр дә, ләкин күпчелек галимнәр никаб киюне тыйдылар. Аллаһу әгъләм.

## Хаҗда хайд һәм нифәс хәлендә булган хатын-кызлар хакында

Хайд һәм нифәс хәлендә булган хатын-кызларга хаҗга вә гумрага ихрамлану тыелмый. Алар тавафтан башка, хаҗига тиеш булган барча хаҗ йолаларын да шулай ук үтиләр. Моңа пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләре вә гыйлем әһелләренең бу мәсьәләгә карата бердәм карары дәлил булып тора.

عَنْ عَائِشَةَ قَالَتْ: «خَرَجْنَا لَا نَرَى إِلَّا الْحَجَّ فَلَمَّا كُنَّا بِسَرِفَ حِضْتُ فَدَخَلَ عَلَيَّ رَسُولُ اللهِ ﷺ وَأَنَا أَبْكِي قَالَ: «مَا لَكِ أَنُفِسْتِ؟» قُلْتُ: «نَعَمْ» قَالَ: «إِنَّ هَذَا أَمْرٌ كَتَبَهُ اللهُ عَلَى بَنَاتِ آدَمَ فَاقْضِي مَا يَقْضِي الْحَاجُّ غَيْرَ أَنْ لا تَطُوفِي بِالْبَيْتِ» قَالَتْ: «وَضَحَّى رَسُولُ اللهِ ﷺ عَنْ نِسَائِهِ بِالْبَقَرِ» [ البخاري ٢٩٤ ]

Мәгънәсе: Гаишә әйтте: *«Без хаҗ нияте белән чыктык, Сәрифкә[12] җиткәч, минем күрем башланды. Пәйгамбәребез ﷺ минем янга кергәч, елап утырганымны күреп сорады:* ***«Нәрсә булды сиңа? Синең хайд (күрем) башландымы?».*** *Мин әйттем: «Әйе». Шуннан соң ул әйтте:*

12 Мәккәнең төньягында 12 чакрым ераклыктагы урын

***«Хакыйкатьтә, бу Аллаһ тәгаләнең Адәм кызларына язган тәкъдире, хаҗ кылучы эшли торган барча нәрсәләрне дә эшлә, әмма ләкин Кәгъба тирәли таваф кылма!».*** *Әйттем (Гаишә): «Пәйгамбәребез ﷺ барча хатыннары исеменнән сыер чалдыртты».*

### Әгәр дә хатын-кыз тәмәттугъ хаҗын ниятләп ихрамга кергәннән соң таваф әл-ифада кылганчы күреме башланып, Гарәфә көне җитеп хаҗны калдырудан курыкса, нишләргә тиеш?

Бу мәсьәләдә гыйлем әһелләре ике карашка бүленде:

**1)** Хәнәфиләрдә: Гумраны калдырып хаҗга ниятли, һәм ифрад хаҗын кыла, һәм хаҗдан соң, әгәр дә теләсә, «Тәнгыйм» яки «Гаишә мәчете» дип аталган урыннан гумрага ихрамланып гумра кыла.

**2)** Мәлики, Шәфигый, Хәнбәли һәм ибен Хәзмның карашында: Гумра ниятен өзмичә хаҗга керә, һәм кыйран хаҗын кыла.

## Таваф кылыр өчен таһәратле (вудулы) булу шарт булып торамы?

Бу мәсьәләдә гыйлем әһелләре өчкә бүленде:

**1)** Тавафның дөрес булуы өчен таһәратле (вудулы) булу шарт булып тора. Бу караш Мәлики, Шәфигый һәм Хәнбәли мәзһәбләреннән билгеле.

**2)** Таваф кылу өчен таһәратле булу вәҗиб. Әгәр дә таһәратсез таваф кылган булса, тавафы дөрес була, әмма ләкин шулай эшләгәне өчен корбан чалырга тиеш. Бу Хәнәфиләрдә билгеле караш, шулай ук бу имам Әхмәднең бер риваяте.

**3)** Таваф кылу өчен таһәратле булу сөннәт. Бу карашны ибен Тәймия әйтеп узды.

**– Тавафка таһәрат шарт диючеләрнең кайбер дәлилләре:**

حَدَّثَنَا أَصْبَغُ عَنْ ابْنِ وَهْبٍ أَخْبَرَنِي عَمْرٌو عَنْ مُحَمَّدِ بْنِ عَبْدِ الرَّحْمَنِ ذَكَرْتُ لِعُرْوَةَ قَالَ فَأَخْبَرَتْنِي عَائِشَةُ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهَا أَنَّ أَوَّلَ شَيْءٍ بَدَأَ بِهِ حِينَ قَدِمَ النَّبِيُّ ﷺ أَنَّهُ تَوَضَّأَ ثُمَّ طَافَ ثُمَّ لَمْ تَكُنْ عُمْرَةً...(الحديث) [ البخاري١٦١٤ ]

Мәгънәсе: Гаишә ﵂ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ Мәккәгә килгәч, иң беренче булып таһәрат алды, аннан соң тавaф кылды...».***

Кайбер гыйлем әһелләре бу дәлилгә болай дип җавап бирде: *«Пәйгамбәребезнең ﷺ тавафка таһәрат алуы, бу аның шарт икәнлеген билгеләми. Чөнки расүлебез ﷺ таһәрате булса да, шулай ук һәрбер намазга таһәратләнә иде, һәм кешегә сәлам кайтарганда тәяммум кыла иде, вә: «Мин таһәратсез килеш Аллаһны зикер итәргә яратмыйм», — дия иде».*

عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ أَنَّ النَّبِىَّ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «الطَّوَافُ حَوْلَ الْبَيْتِ مِثْلُ الصَّلاَةِ إِلاَّ أَنَّكُمْ تَتَكَلَّمُونَ فِيهِ فَمَنْ تَكَلَّمَ فِيهِ فَلاَ يَتَكَلَّمَنَّ إِلاَّ بِخَيْرٍ» قَالَ أَبُو عِيسَى وَقَدْ رُوِى هَذَا الْحَدِيثُ عَنِ ابْنِ طَاوُسٍ وَغَيْرِهِ عَنْ طَاوُسٍ عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ مَوْقُوفًا. وَلاَ نَعْرِفُهُ مَرْفُوعًا إِلاَّ مِنْ حَدِيثِ عَطَاءِ بْنِ السَّائِبِ. وَالْعَمَلُ عَلَى هَذَا عِنْدَ أَكْثَرِ أَهْلِ الْعِلْمِ يَسْتَحِبُّونَ أَنْ لاَ يَتَكَلَّمَ الرَّجُلُ فِى الطَّوَافِ إِلاَّ لِحَاجَةٍ أَوْ بِذِكْرِ اللَّهِ تَعَالَى أَوْ مِنَ الْعِلْمِ. [ سنن الترمذي ٩٦٠ تحقيق الألباني : صحيح ]

Мәгънәсе: Ибен Габбастан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кәгъбәтулла тирәли таваф кылу, намаз кебек, иллә мәгәр сез таваф вакытында сөйләшәсез. Әгәр дә берәрегез сөйләшә икән, хәерле сүз генә сөйләшсен».***

Бу хәдис пәйгамбәребезнең ﷺ сүземе, әллә ибен Габбасныкымы икәнлегендә гыйлем әһелләре арасында төрле сүзләр булды, һәм дөресрәге ул ибен Габбасның сүзе икәнлеге билгеләнде. Бу карашны ибен Тәймия үзенең “Мәҗмугъ әл-Фәтәвә”сендә, әт-Тирмизий, әл-Бәйһәкый, ибен Хәҗәр,ән-Нәсәи, ибен Салах, әл-Мүнзирий, ән-Нәвәвий, ибен Габдулһәдий һәм башкалар хуплады. Аллаһу әгъләм.

(وَإِذْ بَوَّأْنَا لِإِبْرَاهِيمَ مَكَانَ الْبَيْتِ أَنْ لا تُشْرِكْ بِي شَيْئًا وَطَهِّرْ
بَيْتِيَ لِلطَّائِفِينَ وَالْقَائِمِينَ وَالرُّكَّعِ السُّجُودِ) الحج: ٢٦

Мәгънәсе: **«Дәхи хәтерләгез, Ибраһимга Кәгъбәнең урынын бәян иттек, вә аңа әйттек: «Миңа һичнәрсәне тиңдәш итмә! Вә Минем өемне (Кәгъбәне) таваф итүчеләргә, вә анда торучыларга, вә намаз укучыларга, рукүгъ вә сәҗдә кылучыларга пакьлә!».**

Бу аятьтә таваф намаз белән бергә искә алынды, намазга таһәрат шарт булып тора икән, тавафка да таһәрат шарт була. Шулай ук, таваф кылу урынын пакьләргә диелгән икән, таваф кылучыларга тәннәрен пакьләп таһәратләнү әүвәлрәк, диделәр.

Моңа болай дип җавап бирелде: Бу очракта хөкемдә намаз белән тавафны бер-берсенә бәйләп дәлилләү — иң зәгыйфь дәлилләү.

(كُلُوا مِنْ ثَمَرِهِ إِذَا أَثْمَرَ وَآتُوا حَقَّهُ يَوْمَ حَصَادِهِ) الأنعام: ١٤١

Мәгънәсе: **«Өлгергәч һәрберсенең җимешләрен ашагыз һәм уңышларын алганда тиешле өлешен садака итеп бирегез!».**

Белгәнебезчә, җимешләрдән ашау мөбәх, әмма ләкин алардан зәкәт чыгару да мөбәхмы, әгәр дә сез әйткәнчә булса? Шуңа да, бу аятьтәге кебек бер хөкемне икенчесенә бәйләп булмаган шикелле, алдагы аятьтә дә намазга хас хөкемне тавафка бәйләп булмый. Шулай ук, моңа охшаш башка аятьләр бар.

**– Таваф кылырга таһәратле булу сөннәт диючеләрнең кайбер дәлилләре:**

**1)** Таһәратле булуны фарыз кылган ачык-дөрес дәлил килгәнчегә кадәр, кешенең вөҗданы пакь. Ибен Тәймия бу хакта "Мәҗмугъ әл-Фәтәвә 21/273" китабында болай диде: *«Пәйгамбәребездән ﷺ тавафка таһәратле (вудулы) булуны әмер итеп килгән дөрес яки зәгыйфь иснәд белән*

*дәлилне бер кеше дә китермәде. Чөнки аның белән саубуллашу хаҗында бик күп кеше хаҗ вә гумра кылды. Әгәр дә таваф кылырга таһәрат (вуду) фарыз булса, расүлебез ﷺ моны аңлатып узган булыр иде, һәм ул сүзләрне, башка хәдисләр кебек үк, мөселманнар ятлап җиткерерләр иде».*

Ошбу мәгънәдә үк ибен Кайим әл-Җәүзия “Тәһзиб әс-Сүнән 1/52, 53”дә әйтеп узды.

Шулай ук, ибен Тәймия: *«Таваф ул намаз хөкемендә түгел, чөнки “Мүснәд Әхмәд”тә килгән хәсән хәдиснең мәгънәсендә пәйгамбәребез ﷺ:* ***«Намазның ачкычы — таһәрат, тәхриме (намазга керүе) — тәкбир, тәхлиле (намаздан чыгуы) — сәлам»,*** *— диде. Нинди дә булса гыйбадәткә керү тәкбир белән вә аннан чыгу сәлам белән билгеләнми икән, ул намаз түгел, һәм аның ачкычы таһәрат була алмый»,* — диде.

– Дөресрәге, хатын-кызга хайдтан пакь булу таваф өчен шарт булып тора, ә инде кечкенә таһәрат (вуду) шарт түгел. Әмма ләкин моңа карамастан таваф кылучының бу гамәлдә хыйләфтән чыгу өчен таһәратле булуы күпкә хәерлерәк. Һәм таваф кылучы бу мәсьәләдә җитди вә игътибарлы булырга тиеш. Аллаһу әгъләм.

## Хатын-кыз тавафта рамл, һәм сәгыйдә ике яшел билге арасында кызу атлап йөгерергә тиешме?

Бу мәсьәләдә пәйгамбәребездән ﷺ хатын-кызларга кагылышлы әсәр билгеле түгелдер. Ләкин күпчелек гыйлем әһелләре хатын-кызларга рамл тиеш түгел, дигән фикерне әйттеләр, хәтта кайберләре бу гыйлем әһелләренең бердәм карашы диделәр. Без ошбу мәсьәләгә бәйле кайбер әсәрләрне искә алып үтәрбез:

عن ابن عمر رضي الله عنهما قال: «ليس على النساء رمل ولا بين الصفا والمروة» [ مصنف ابن أبي شيبة، صحيح عن ابن عمر ]

Мәгънәсе: Ибен Гомәр ﷺ әйтте: ***«Хатын-кызларга тавафта һәм Сафа белән Марва арасында рамл (ике билге арасын кызу атлап йөгерү) юк!».***

عن ابن عباس قال : «ليس على النساء رمل» [ مصنف ابن أبي شيبة ]

Мәгънәсе: Ибен Габбас ﷺ әйтте: ***«Хатын-кызларга рамл юк!».***

عن إبراهيم قال : «المرأة تقص، ليس على النساء حلق ولا رمل» [ مصنف ابن أبي شيبة ]

Мәгънәсе: Ибраһим (ән-Нәхәгый) әйтте: ***«Хатын-кызлар чәчләрен кисәләр, әмма ләкин аларга чәч кыру һәм рамл юк!».***

عن عطاء قال : «ليس على النساء رمل بالبيت ولا بين الصفا والمروة» [ مصنف ابن أبي شيبة، صحيح عن عطاء ]

Мәгънәсе: Гата (бин Әбий Рабәх) әйтте: ***«Хатын-кызларга Кәгъбә тирәли һәм Сафа вә Марва арасында рамл юк!».***

**– Хатын-кыз чәчен кыскарту хакында**

١٩٨٥- عَنْ ابْنِ عَبَّاس قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم: «لَيْسَ عَلَى النِّسَاءِ الْحَلْقُ إِنَّمَا عَلَى النِّسَاءِ التَّقْصِيرُ» [ سنن أبي داود، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Ибен Габбастан ﷺ риваять ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хатын-кызларга чәч кыру юк, аларга бәлки чәч кыскартудыр».***

Хатын-кыз чәчен кыскартканда күпме кисәргә тиешлеге хакында Коръәннән яки Сөннәттән дәлил искә алынмый. Бу хакта кайбер гыйлем әһелләре чәч толымының очын бер бармак буыны кадәр кисә дисә, икенчеләре һәрбер чәченең очыннан кисә диделәр, һәм шулай ук башка фикерләр әйтелде. Шуның өчен дә хатын-кыз күпме киссә дә ярый, иллә-мәгәр чәчен кырмый.

# НИКАХ
# китабы

**<u>Никахның шәргый мәгънәсе:</u>**

Никах — ул, өйләнү максаты белән килешү төзү. Коръәндә **«никах»** дип килгән сүз, күпчелек гыйлем әһелләре әйтүенчә, ул өйләнүне аңлата. Иллә-мәгәр ике урында гына **«никах»** сүзе өйләнү мәгънәсендә килми, Аллаһу әгъләм.

(وَابْتَلُوا الْيَتَامَى حَتَّى إِذَا بَلَغُوا النِّكَاحَ...) النساء: ٦

Мәгънәсе: **«Ятимнәрне никахланырга яраклы булганга чаклы сынагыз».**

Бу аятьтә никах «бәлигъ булу» (төшләнү) мәгънәсендә килә.

(حَتَّى تَنْكِحَ زَوْجًا غَيْرَهُ) البقرة: ٢٣٠

Мәгънәсе: **«Хәтта икенче иргә никахланып аерылганга чаклы».**

Кайбер гыйлем әһелләре бу аятьтә никах «якынлык кылу» мәгънәсендә килә диделәр. Чөнки, пәйгамбәребез ﷺ моны аңлатып болай диде: ***«Хәтта син аның тәмен белгәнчегә кадәр, һәм ул синең тәмеңне белгәнчегә кадәр...».***

Өйләнү, кешенең бер-берсенә карата булган дуслыгында иң көчле бәйләнешләрнең берсе. Шуның өчен дә, булсын ул ир яки хатын-кыз, һәрберсе үзенә динле вә күркәм холыклы булган иптәш сайларга тиеш. Әгәр дә шулай булмаса, ул вакытта аларның өйләнүе тормышларын бозып иң куркыныч мөгамәләгә әйләнә. Бу хакта пәйгамбәребез ﷺ болай дип әйтеп узды:

٢٠٩٠ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ عَنْ النَّبِيِّ ﷺ قَالَ: «تُنْكَحُ الْمَرْأَةُ لأَرْبَعٍ لِمَالِهَا وَلِحَسَبِهَا وَلِجَمَالِهَا وَلِدِينِهَا فَاظْفَرْ بِذَاتِ الدِّينِ تَرِبَتْ يَدَاكَ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ؓ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хатын-кызга дүрт нәрсә өчен өйләнәләр: Байлыгы өчен, затлы нәселе өчен, чибәрлеге өчен һәм дине өчен. Диндар булганны сайла, югыйсә отыласың!».***

Бу хәдистә пәйгамбәребез ﷺ диндар хатынны ир кеше өчен зур табыш итеп билгеләде.

١٠٠٤ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «إِذَا خَطَبَ إِلَيْكُمْ مَنْ تَرْضَوْنَ دِينَهُ وَخُلُقَهُ فَزَوِّجُوهُ إِلا تَفْعَلُوا تَكُنْ فِتْنَةٌ فِي الأَرْضِ وَفَسَادٌ عَرِيضٌ» [ سنن الترمذي تحقيق الألباني: حسن ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә сездән (кызларыгызга) өйләнергә дип, дине һәм холкы риза булырлык бердү килеп сораса, аны (кызларыгызга) өйләндерегез! Өйләндермәсәгез, җир йөзендә фетнә һәм зур фәсәд таралыр».***

Бу хәдистә расүлебез ﷺ дине вә холкы күркәм кешегә кызларны бирергә өндәде. Чөнки тормышта ир белән хатынның мөгамәләсе иң четерекле мөгамәлә. Әгәр дә гаиләнең нигезе булып дин тормаса, ул вакытта Аллаһка гөнаһ кылуга һәм бәхетсезлеккә китерәчәк. Шуның өчен дә Аллаһ тәгалә мөселман кешесен мөшриккә өйләнүдән тыйды. Һәм ошбу тыюның сәбәбен, мөшрикләрнең утка чакырулары, ягъни Җәһәннәм утына юл күрсәтүчеләр булулары белән аңлатты.

(وَلا تَنْكِحُوا الْمُشْرِكَاتِ حَتَّى يُؤْمِنَّ وَلأَمَةٌ مُؤْمِنَةٌ خَيْرٌ مِنْ مُشْرِكَةٍ وَلَوْ أَعْجَبَتْكُمْ وَلا تُنْكِحُوا الْمُشْرِكِينَ حَتَّى يُؤْمِنُوا وَلَعَبْدٌ مُؤْمِنٌ خَيْرٌ مِنْ مُشْرِكٍ وَلَوْ أَعْجَبَكُمْ أُولَئِكَ يَدْعُونَ إِلَى النَّارِ وَاللَّهُ يَدْعُو إِلَى الْجَنَّةِ وَالْمَغْفِرَةِ بِإِذْنِهِ وَيُبَيِّنُ آيَاتِهِ لِلنَّاسِ لَعَلَّهُمْ يَتَذَكَّرُونَ) البقرة: ٢٢١

Мәгънәсе: **«Ислам динендә булмаган мөшрикә хатынга иман китергәнчегә кадәр никахланмагыз. Азат булган, чибәрлеге яки байлыгы белән сезне гаҗәпләндергән мөшрикә хатынына караганда, кол булган мөэминә хатын, әлбәттә, хәерлерәк. Янә мөшрик булган ирләргә иман китергәнчеләренә кадәр мөселман булган хатыннарыгызны никахландырмагыз. Байлыгы яки яхшылыгы сезне гаҗәпләндергән мөшрик ирләргә караганда, кол булган мөселман ир, әлбәттә, хәерле. Ул мөшрик ирләр һәм мөшрикә хатыннар сезне Җәһәннәм утына чакыралар. Ягъ-**

**ни, аларга ир яки хатын булсагыз, үзләре белән Җәһәннәмгә алып керерләр. Алардан ерак булыгыз! Аллаһ үзенең теләге белән сезне Җәннәткә һәм ярлыкауга чакыра. Аллаһ үзенең аятьләрен кешеләргә бәян кыла вәгазьләнсеннәр өчен».**

## Никахлану һәм изге-салих балалар сорау хакында

***Коръән аятьләре:***

(وَإِنْ خِفْتُمْ أَلا تُقْسِطُوا فِي الْيَتَامَى فَانْكِحُوا مَا طَابَ لَكُمْ مِنَ
النِّسَاءِ مَثْنَى وَثُلاثَ وَرُبَاعَ فَإِنْ خِفْتُمْ أَلا تَعْدِلُوا فَوَاحِدَةً أَوْ
مَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ ذَلِكَ أَدْنَى أَلا تَعُولُوا) النساء: ٣

Мәгънәсе: **«Ятимнәрне гаделлек белән тәрбия кылырга курыксагыз, күңелегезгә хуш килгән башка хатын-кызлардан икешәр, өчәр һәм дүртәрне үзегезгә никах кылып алыгыз. Әгәр гаделлек кыла алмабыз дип курыксагыз, бергә генә никахланыгыз яки сатып алган кәнизәләрегез җитәр. Бу (бергә генә никахлану яки сатып алган кәнизә белән канәгатьләнү) гаделсезлектән саклануыгыз өчен хәерлерәктер».**

(وَمِنْ آيَاتِهِ أَنْ خَلَقَ لَكُمْ مِنْ أَنْفُسِكُمْ أَزْوَاجًا لِتَسْكُنُوا إِلَيْهَا وَجَعَلَ بَيْنَكُمْ
مَوَدَّةً وَرَحْمَةً إِنَّ فِي ذَلِكَ لَآيَاتٍ لِقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ) الروم: ٢١

Мәгънәсе: **«Дәхи Аллаһның кодрәтенә дәлилләрдән: сезнең өчен Аллаһ үзегездән хатыннар яратты, ул хатыннар белән өлфәтләнеп бергә яшәвегез өчен, һәм ир белән хатын арасында дуслык һәм мәрхәмәтлек кылды, әлбәттә, Аллаһның бу эшләрендә фикерле белгән кешеләр өчен гыйбрәт бар».**

(يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُمْ مِنْ ذَكَرٍ وَأُنْثَى وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا
إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِنْدَ اللهِ أَتْقَاكُمْ إِنَّ اللهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ) الحجرات: ١٣

Мәгънәсе: **«Әй кешеләр! Без сезләрне ир вә хатын итеп халык кылдык, вә сездән тармаклар, вә кабиләләр кылдык, бер-берегезне аерып белер өчен, тәхкыйк, сезнең Аллаһ хозурында хөрмәтлерәк булучыгыз шул: кем Аллаһка тәкъвалырак. Хакыйкатьтә, Аллаһ белүче, вә һәр эшегездән хәбәрдар».**

(يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُمْ مِنْ نَفْسٍ وَاحِدَةٍ وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالًا كَثِيرًا وَنِسَاءً وَاتَّقُوا اللَّهَ الَّذِي تَسَاءَلُونَ بِهِ وَالأَرْحَامَ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلَيْكُمْ رَقِيبًا) النساء: ١

Мәгънәсе: **«Әй кешеләр! Сезне бер нәфестән (Адәмнән) халык кылучы Аллаһка тәкъва булыгыз! Ул (Аллаһ), Адәм г-мнең үзеннән хатын (Хәваны) яратты, вә икесеннән күп ирләрне һәм күп хатыннарны дөньяга чәчте. Янә Аллаһка тәкъвалык кылыгыз, Ул — Аллаһ исеме белән бер-берегездән сорыйсыз, ягъни Аллаһ ризалыгы өчен бир, сүземне тыңла, дисез, һәм Аллаһ ризалыгы өчен сорагач, кешенең кире как-маганлыгын беләсез. Шулай булгач, Аллаһны зурлагыз вә якын туганлык җепләрен өзүдән сакланыгыз! Аллаһ бит сезнең барча эшләрегезне тикшереп күзәтүче».**

(وَلَقَدْ أَرْسَلْنَا رُسُلًا مِنْ قَبْلِكَ وَجَعَلْنَا لَهُمْ أَزْوَاجًا وَذُرِّيَّةً) الرعد: ٣٨

Мәгънәсе: **«Синнән элек тә расүлләр җибәрдек вә аларга күп хатыннар вә күп балалар бирдек...».**

(هُنَالِكَ دَعَا زَكَرِيَّا رَبَّهُ قَالَ رَبِّ هَبْ لِي مِنْ لَدُنْكَ ذُرِّيَّةً طَيِّبَةً إِنَّكَ سَمِيعُ الدُّعَاءِ) آل عمران: ٣٨

Мәгънәсе: **«Зәкәрия** ﴿عليه السلام﴾ **Раббысына ялварып дога кылды: "Әй Раббым! Рәхмәтеңнән миңа изге вә күркәм нәселтокым бир! Шиксез, Син доганы ишетәсең"».**

(وَالَّذِينَ يَقُولُونَ رَبَّنَا هَبْ لَنَا مِنْ أَزْوَاجِنَا وَذُرِّيَّاتِنَا قُرَّةَ أَعْيُنٍ وَاجْعَلْنَا لِلْمُتَّقِينَ إِمَامًا) الفرقان: ٧٤

Мәгънәсе: **«Алар әйтерләр: Әй Раббыбыз! Безгә изге хатыннар вә яхшы балалар бир, аларның итагать иткәннәрен**

**күреп, күзләребез вә күңелләребез тынычланырлык булсын, һәм безне тәкъва мөэминнәргә имам кыл, алар дин эшләрендә безгә иярсеннәр!».**

(وَأَنْكِحُوا الأَيَامَى مِنْكُمْ وَالصَّالِحِينَ مِنْ عِبَادِكُمْ وَإِمَائِكُمْ إِنْ يَكُونُوا فُقَرَاءَ يُغْنِهِمُ اللَّهُ مِنْ فَضْلِهِ وَاللَّهُ وَاسِعٌ عَلِيمٌ) النور: ٣٢

Мәгънәсе: **«Үзләрегездән ирсез хатыннарны вә хатынсыз ирләрне, һәм никах хакларын үтәргә яраклы булган яхшы колларыгызны вә җарияләрегезне өйләндерегез, әгәр өйләнүчеләр фәкыйрь булсалар, Аллаһ аларны бай кылыр Үзенең юмартлыгы белән, шиксез Аллаһ киңлек иясе вә белеп эш кылучы».**

***Хәдисләр:***

٥٠٦٣ - حَدَّثَنَا سَعِيدُ بْنُ أَبِي مَرْيَمَ أَخْبَرَنَا مُحَمَّدُ بْنُ جَعْفَرٍ أَخْبَرَنَا حُمَيْدُ بْنُ أَبِي حُمَيْدٍ الطَّوِيلُ أَنَّهُ سَمِعَ أَنَسَ بْنَ مَالِكٍ ﵁ يَقُولُ جَاءَ ثَلَاثَةُ رَهْطٍ إِلَى بُيُوتِ أَزْوَاجِ النَّبِيِّ ﷺ يَسْأَلُونَ عَنْ عِبَادَةِ النَّبِيِّ ﷺ فَلَمَّا أُخْبِرُوا كَأَنَّهُمْ تَقَالُّوهَا فَقَالُوا وَأَيْنَ نَحْنُ مِنَ النَّبِيِّ ﷺ قَدْ غُفِرَ لَهُ مَا تَقَدَّمَ مِنْ ذَنْبِهِ وَمَا تَأَخَّرَ قَالَ أَحَدُهُمْ أَمَّا أَنَا فَإِنِّي أُصَلِّي اللَّيْلَ أَبَدًا وَقَالَ آخَرُ أَنَا أَصُومُ الدَّهْرَ وَلَا أُفْطِرُ وَقَالَ آخَرُ أَنَا أَعْتَزِلُ النِّسَاءَ فَلَا أَتَزَوَّجُ أَبَدًا فَجَاءَ رَسُولُ اللهِ ﷺ إِلَيْهِمْ فَقَالَ: «أَنْتُمُ الَّذِينَ قُلْتُمْ كَذَا وَكَذَا أَمَا وَاللهِ إِنِّي لَأَخْشَاكُمْ لِلهِ وَأَتْقَاكُمْ لَهُ لَكِنِّي أَصُومُ وَأُفْطِرُ وَأُصَلِّي وَأَرْقُدُ وَأَتَزَوَّجُ النِّسَاءَ فَمَنْ رَغِبَ عَنْ سُنَّتِي فَلَيْسَ مِنِّي» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәлик ﵁ әйтте: *«Бервакыт пәйгамбәребезнең ﷺ хатыннарының өйләре янына өч кеше килеп расүлебезнең ничек гыйбәдәт кылуы хакында сораша башладылар. Аларга бу хакта хәбәр ителгәч, моны алар алай ук күпкә санамыйча әйттеләр: «Кайда инде ул безгә пәйгамбәребез ﷺ кебек булу, Аллаһ аның элекке һәм киләсе гөнаһларын гафу итте». Шуннан соң араларыннан берсе әйтте: «Миңа килгәндә, мин моннан соң һәр төн йокламыйча намаз укыячакмын!». Икенчесе әйтте: «Мин гомер буе ураза тотачакмын!». Өченчесе әйтте: «Ә мин хатын-кызлардан читләшәм, һәм беркайчан да өйләнмәячәкмен!». Бераздан алар янына пәйгамбәребез ﷺ килде, һәм әйтте:*

***«Сез әйттегезме шундый сүзләр? Әмма мин сезгә караганда да Аллаһтан иң куркучымын, һәм сезнең арагыздан иң тәкъвалыракмын, ләкин мин ураза тотам һәм шулай ук кайбер көннәрне тотмыйм, төннәрен намаз укыйм һәм йоклыйм, шулай ук өйләнәм. Кем дә кем минем сөннәтемне (юлымны ташлап) кабул итмичә башка юл сайлый икән, ул миннән түгел».***

٢٠٥٠ - عَنْ مَعْقِلِ بْنِ يَسَارٍ قَالَ جَاءَ رَجُلٌ إِلَى النَّبِيِّ ﷺ فَقَالَ: إِنِّي أَصَبْتُ امْرَأَةً ذَاتَ حَسَبٍ وَجَمَالٍ وَإِنَّهَا لَا تَلِدُ أَفَأَتَزَوَّجُهَا قَالَ: «لَا» ثُمَّ أَتَاهُ الثَّانِيَةَ فَنَهَاهُ ثُمَّ أَتَاهُ الثَّالِثَةَ فَقَالَ: «تَزَوَّجُوا الْوَدُودَ الْوَلُودَ فَإِنِّي مُكَاثِرٌ بِكُمُ الأُمَمَ» [ سنن أبي داود صحيح ]

Мәгънәсе: Мәгъкыйл бин Ясәр ﵁ әйтте: *«Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ янына бер кеше килде һәм әйтте: «Мин затлы нәселдән булган һәм бик чибәр хатын-кызны очраттым, ләкин ул бала тапмый, аңа өйләнимме?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Юк!».*** *Шуннан соң, бу кеше икенче тапкыр килеп сорады, анда да пәйгамбәребез ﷺ аны тыйды. Бераз вакыттан соң өченче тапкыр килде, һәм пәйгамбәребез ﷺ аңа әйтте:* ***«Ирләрен ярата торган һәм күп бала табучы хатыннарга өйләнегез! Хакыйкатьтә, мин сезнең башка өммәтләргә караганда күплегегез белән горурланам».***

١٦٣١ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ أَنَّ رَسُولَ اللهِ ﷺ قَالَ إِذَا مَاتَ الْإِنْسَانُ انْقَطَعَ عَنْهُ عَمَلُهُ إِلَّا مِنْ ثَلَاثَةٍ إِلَّا مِنْ صَدَقَةٍ جَارِيَةٍ أَوْ عِلْمٍ يُنْتَفَعُ بِهِ أَوْ وَلَدٍ صَالِحٍ يَدْعُو لَهُ [ مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә кеше үлсә, өч әйбердән башка аның барча гамәлләре дә киселә (туктала): Савабы килеп торучы садака, яки файдаланыла торган гыйлем, яки аңа дога кылучы изге бала».***

٥٠٦٨ - عَنْ أَنَسٍ ﵁ أَنَّ النَّبِيَّ ﷺ كَانَ يَطُوفُ عَلَى نِسَائِهِ فِي لَيْلَةٍ وَاحِدَةٍ وَلَهُ تِسْعُ نِسْوَةٍ [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәлик ﵁ әйтте: ***«Пәйгамбәребезнең ﷺ тугыз хатыны бар иде, һәм ул бер төн эчендә хатыннарын әйләнеп чыга иде».***

١٤٦٩- عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ عَمْرٍو أَنَّ رَسُولَ اللهِ ﷺ قَالَ: «الدُّنْيَا مَتَاعٌ وَخَيْرُ مَتَاعِ الدُّنْيَا الْمَرْأَةُ الصَّالِحَةُ» [ مسلم ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гамр бин әл-Гастан ﵁ риваять ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөнья ул — ләззәтлек, һәм андагы иң хәерле ләззәтлек — изге хатын».***

٣٩٣٩ - عَنْ أَنَسٍ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «حُبِّبَ إِلَيَّ مِنْ الدُّنْيَا النِّسَاءُ وَالطِّيبُ وَجُعِلَ قُرَّةُ عَيْنِي فِي الصَّلَاةِ» [ سنن النسائي، تحقيق الألباني: حسن صحيح ]

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәликтән ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Миңа бу дөньядан хатын-кызлар һәм хушбуй сөйкемле булды, ә күземнең тынычлыгы намазда булды».***

٣١٢١- عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ عَنْ النَّبِيِّ ﷺ قَالَ: «ثَلَاثَةٌ كُلُّهُمْ حَقٌّ عَلَى اللهِ عَزَّ وَجَلَّ عَوْنُهُ الْمُجَاهِدُ فِي سَبِيلِ اللهِ وَالنَّاكِحُ الَّذِي يُرِيدُ الْعَفَافَ وَالْمُكَاتَبُ الَّذِي يُرِيدُ الْأَدَاءَ» [ سنن النسائي، حسن ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Өч төрле кешене Аллаһ тәгалә Үзенең ярдәменнән калдырмый: Аллаһ юлында сугышучы мөҗәһид, үзен зинадан һәм башка төрле хәрамнардан сакларга тырышып өйләнергә теләүче һәм үзен хуҗасыннан сатып алырга теләүче кол».***

***Сахәбәләрдән кайбер әсәрләр:***

٥٠٦٩ - عَنْ سَعِيدِ بْنِ جُبَيْرٍ قَالَ: «قَالَ لِي ابْنُ عَبَّاسٍ: هَلْ تَزَوَّجْتَ؟ قُلْتُ: لا. قَالَ: فَتَزَوَّجْ فَإِنَّ خَيْرَ هَذِهِ الْأُمَّةِ أَكْثَرُهَا نِسَاءً» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Сәгыйд бин Җубәйрдән ﵁: *«Ибен Габбас ﵁ миннән сорады:* ***«Син өйләндеңме?».*** *Мин әйттем: «Юк». Шуннан соң ул миңа әйтте:* ***«Өйлән! Хакыйкатьтә, бу өммәтнең иң хәерле кешесе — күп хатынлысы».***

عن عبد الله قال : «لو لم يبق من الدهر إلا ليلة لأحببت أن يكون لي في تلك الليلة امرأة» [ مصنف ابن أبي شيبة صحيح عن ابن مسعود ]

Мәгънәсе: Габдулаһ бин Мәсъгуд ﵁ әйтте: ***«Әгәр дә бу гомердән бер генә төн калса иде, ул төнне миндә хатын-кыз булуын теләр идем».***

## Мүхәррамәт яки өйләнергә тыелган хатын-кызлар

Өйләнергә тыелган хатын-кызлар ике төрле: Берәүләренә беркайчан да һәм бервакытта да өйләнергә ярамый, ә икенчеләренә вакытлыча өйләнергә ярамый.

**1) Беркайчан да һәм бервакытта да өйләнергә ярамаган хатын-кызлар үзләре өч төрлегә бүленәләр:**

**А)** Нәсел-нәсәб туганлыгы буенча тыелганнар һәм алар үзләре дүрт төрле:

**1-** Әнисе һәм әбиләре; әнисенең әнисе, әтисенең әнисе һәм шулай алардан югарыга менеп китсә нәсел-нәсәбе (дәү әнисенең әнисе, әтисенең әнисенең әнисе һ.б.)

**2-** Кызлары, оныклары һәм шулай алардан аска төшеп китсә нәсел-нәсәбе (оныкларының кызлары һ.б.).

**3-** Бертуган апа-сеңелләре, аларның кызлары, бертуган абый-энеләренең кызлары һәм шулай ук алардан аска төшеп китсә нәсел-нәсәбе (апа-сеңелләренең һәм абый-энеләренең кызларының кызлары һ.б.).

**4-** Әтисенең һәм әнисенең бертуган апа-сеңелләре.

Ошбу ук, никахланырга тыелган хатын-кызларны аять тәртибе буенча җиде дип әйттеләр:

٥١٠٥ - عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ رضي الله عنهما قال: «حَرُمَ مِنَ النَّسَبِ سَبْعٌ وَمِنَ الصِّهْرِ سَبْعٌ» ثُمَّ قَرَأَ (حُرِّمَتْ عَلَيْكُمْ أُمَّهَاتُكُمْ) الآيَةَ [ البخاري ]

Мәгънәсе: Ибен Габбас ﵁ әйтте: ***«Нәсел-нәсәб туганлыгы буенча җиде төрле кеше тыела һәм өйләнеп туганлашкан буенча да җиде төрле кеше тыела».*** Шуннан соң әл-Нисә сүрәсенең 23нче аятен укыды.

Ягъни: 1- Әниләрегез һәм югарыда алар белән искә алынганнар, 2- Кызларыгыз һәм алар белән искә алынганнар, 3- Бертуган апа-сеңелләрегез, 4- Әтиләрегезнең бертуган апа-сеңелләре, 5- Әниләрегезнең бертуган апа-сеңелләре, 6- Бертуган абый-энеләрегезнең кызлары һәм алар белән

искә алынганнар, 7- Бертуган апа-сеңелләрегезнең кызлары һәм алар белән искә алынганнар.

Югарыда әйтелгән мөхәррамәтләр (өйләнергә тыелган хатын-кызлар) «әл-Нисә» сүрәсенең 23нче аятендә искә алынды:

(حُرِّمَتْ عَلَيْكُمْ أُمَّهَاتُكُمْ وَبَنَاتُكُمْ وَأَخَوَاتُكُمْ وَعَمَّاتُكُمْ
وَخَالاتُكُمْ وَبَنَاتُ الأخِ وَبَنَاتُ الأخْتِ) النساء: ٢٣

Мәгънәсе: **«Сезгә никахланырга хәрам булды: аналарыгыз (һәм аларның аналары) вә кызларыгыз (һәм кызларыгызның кызлары), бертуган апагыз вә сеңелегез, атагызның бертуган апалары вә сеңелләре, анагызның бертуган апалары вә сеңелләре, бертуган ир кардәшләрегезнең кызлары, бертуган кыз кардәшләрегезнең кызлары».**

**Б)** Өйләнеп туганлашу буенча тыелганнар, алар шулай ук дүрт төрле:

**1-** Әтинең хатыннары һәм бабаларның хатыннары.

(وَلا تَنْكِحُوا مَا نَكَحَ آبَاؤُكُمْ مِنَ النِّسَاءِ إِلا مَا قَدْ سَلَفَ إِنَّهُ
كَانَ فَاحِشَةً وَمَقْتًا وَسَاءَ سَبِيلا) النساء: ٢٢

Мәгънәсе: **«Атагыздан калган хатынны, ягъни атагыз аерган үги анагызга никахланмагыз, үткән җәһилияттән башка, ягъни мондый хәлләр җәһилият заманында булып үтте. Ул эш, әлбәттә, фәхеш һәм ачулы эштер һәм ул эшне эшләгән кешеләрнең юлы кабахәт юлдыр».**

**2-** Хатынның әнисе, әбиләре һәм шулай өскә менеп китсә нәсел-нәсәбе (хатынның дәү әнисе һ.б.).

**3-** Хатынның кызлары һәм хатынның улларының кызлары. (Монсында хатыны белән якынлык кылу шарт булып тора, әгәр дә ул хатын белән якынлык кылмыйча аны талак кылган булса яки якынлык кылганчы ул хатын үлсә, аның кызына өйләнергә ярый).

**4-** Ир-атның үз улларының хатыннары һәм оныкларының хатыннары.

(وَأُمَّهَاتُ نِسَائِكُمْ وَرَبَائِبُكُمُ اللاتِي فِي حُجُورِكُمْ مِنْ نِسَائِكُمُ اللاتِي دَخَلْتُمْ بِهِنَّ فَإِنْ لَمْ تَكُونُوا دَخَلْتُمْ بِهِنَّ فَلا جُنَاحَ عَلَيْكُمْ وَحَلائِلُ أَبْنَائِكُمُ الَّذِينَ مِنْ أَصْلابِكُمْ) النساء: ٢٣

Мәгънәсе: **«Сезгә никахланырга тыелды хатыннарыгызның аналары, өегездә тәрбия ителә торган үги кызларыгыз, ягъни хатыныгызга ияреп килгән кызлар, әгәр ул хатынга якынлык кылган булсагыз. Әгәр ул хатынга никахлангач, якынлык кылмыйча талак кылсагыз, аның кызына никахлануыгызда сезгә гөнаһ юк. Шулай ук, аркагыздан килгән үз улларыгызның хатыннарына никахлану сезгә тыелды!».**

**B)** Бер ана күкрәгеннән имү буенча никахланырга тыелганнар:

Бер ана күкрәгеннән имү буенча өйләнергә тыелган хатын-кызларның төре, шул ук, нәсел-нәсәб буенча никахланырга тыелган хатын-кызларның төредер (без аларны **-А-** бүлегендә әйтеп уздык).

(وَأُمَّهَاتُكُمُ اللاتِي أَرْضَعْنَكُمْ وَأَخَوَاتُكُمْ مِنَ الرَّضَاعَةِ) النساء: ٢٣

Мәгънәсе: **«Күкрәк сөтен имезүче үги аналарыгыз һәм аларның кызлары».**

Бу аятьне аңлатып, шулай ук, пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләре килде:

٢٦٤٥ - عَنْ ابْنِ عَبَّاسٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُمَا قَالَ: قَالَ النَّبِيُّ صلى الله عليه و سلم فِي بِنْتِ حَمْزَةَ: «لا تَحِلُّ لِي، يَحْرُمُ مِنْ الرَّضَاعِ مَا يَحْرُمُ مِنْ النَّسَبِ هِيَ بِنْتُ أَخِي مِنْ الرَّضَاعَةِ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Ибен Габбастан رضي الله عنه, пәйгамбәребез ﷺ Хәмзәнең кызы хакында болай диде: ***«Миңа ул хәләл түгел, нәсел-нәсәб буенча тыелганнар, күкрәк сөте имү буенча да тыелалар, ул күкрәк сөте буенча булган абыемның кызы».***

١٤٤٧- «وَإِنَّهُ يَحْرُمُ مِنْ الرَّضَاعَةِ مَا يَحْرُمُ مِنْ النَّسَبِ» [ مسلم ]

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хакыйкатьтә, нәсел-нәсәб буенча тыелганнар күкрәк сөте имү буенча да тыелалар».***

**2) Вакытлыча өйләнергә ярамаган хатын-кызлар:**

**А)** Кияүдәге хатын-кызларга һәм шулай ук (аерылу яки ире үлү сәбәпле) гыйддә вакыты узмаганнарга.

(وَالْمُحْصَنَاتُ مِنَ النِّسَاءِ إِلا مَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ) النساء: ٢٤

Мәгънәсе: **«Янә ире булган хатыннар сезгә хәрам булды, мәгәр сугышта әсир төшкән ирле хатыннар хәләлдер».**

(وَلا تَعْزِمُوا عُقْدَةَ النِّكَاحِ حَتَّى يَبْلُغَ الْكِتَابُ أَجَلَهُ) البقرة: ٢٣٥

Мәгънәсе: **«Хатыннарның гыйддә вакыты үтмичә никахланырга бер карар да кылмагыз!».**

**Б)** Бер ир-атның дүрт хатыны булса.

Әгәр бер ир-атның дүрт хатыны булса, аңа бишенчегә өйләнергә тыела. Чөнки аның кул астында дүрттән артык хатыны булырга тиеш түгел. Ә инде ул дүрт хатынының берсен талак кыла икән, ул вакытта аңа дүртенчегә икенче башка хатынны никах кылып алырга ярый.

(فَانْكِحُوا مَا طَابَ لَكُمْ مِنَ النِّسَاءِ مَثْنَى وَثُلاثَ وَرُبَاعَ) النساء: ٣

Мәгънәсе: **«Күңелегезгә хуш килгән хатын-кызлардан икешәр, өчәр һәм дүртәрне үзегезгә никах кылып алыгыз».**

٣١٧٦- عن ابن عمر رضي الله عنه أَنَّ غَيْلانَ بْنَ سَلَمَةَ الثَّقَفِيَّ أَسْلَمَ وَلَهُ عَشْرُ نِسْوَةٍ فِي الْجَاهِلِيَّةِ فَأَسْلَمْنَ مَعَهُ، فقال النبي ﷺ: «أمسك أربعا وفارق سائرهن» [ مشكاة المصابيح، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гомәрдән رضي الله عنه: *«Гайлән бин Сәламә әс-Сәкафый Исламны кабул иткәндә, аның җәһилияттә (Исламга кадәр) ун хатыны бар иде, һәм алар да*

*аның белән бергә Исламны кабул иттеләр. Шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ аңа әйтте:* ***«Дүртесен калдыр, ә калганнарын аерып җибәр!».***

**В)** Ир-ат хатынын талак кылганнан соң, гыйддә вакыты узмыйча ул хатынның бертуган апа-сеңелләренә дә, шулай ук ул хатынның әтисенең бертуган апа сеңелләренә дә яки әнисенең бертуган апа сеңелләренә дә өйләнә алмый.

**Г)** Иреннән өч тапкыр талак белән аерылган хатын икенче иргә кияүгә чыгып, икенче ире талак кылып аерып җибәрмичә, беренче ире кире кайтарып ала алмый.

(الطَّلاقُ مَرَّتَانِ فَإِمْسَاكٌ بِمَعْرُوفٍ أَوْ تَسْرِيحٌ بِإِحْسَانٍ) البقرة: ٢٢٩

Мәгънәсе: **«Талак ике мәртәбә — ягъни ир хатынын бер мәртәбә талак кылгач та, икенче мәртәбә талак кылгач та бергә торырга теләге булса, кайтарып алырга хаклы була. Әмма өченче мәртәбә талак кылса, якынлык кылырга да, кайтарып алырга да хакы юктыр. Икенче талактан соң кайтарып алса, шәригать кушканча гаделлек белән хатын итеп тотмак лязем, аерып җибәрсә дә яхшылык белән җибәрү тиештер».**

(فَإِنْ طَلَّقَهَا فَلا تَحِلُّ لَهُ مِنْ بَعْدُ حَتَّى تَنْكِحَ زَوْجًا غَيْرَهُ) البقرة: ٢٣٠

Мәгънәсе: **«Әгәр берәү хатынын өченче мәртәбә талак кылса, ул хатын иренә хәләл булмас, хәтта икенче иргә никахланып аерылганга чаклы».**

**Д)** Бертуган апалы-сеңелле хатын-кызны икесен бергә хатын итеп алу, шулай ук хатын-кызны әтисенең бертуган апа-сеңеле белән яки әнисенең бертуган апа-сеңеле белән бергә хатын итеп алу тыела.

Ир-атка ике бертуган хатын-кызны бергә җыеп никахланырга ярамый, ягъни хатынын талак кылмыйча яки

хатыны үлмичә торып һәм ул хатынның гыйддә вакыты үтмичә, аның бертуган апасына, бертуган сеңеленә, ул хатынның әтисенең яки әнисенең бертуган апасеңелләренә никахлана алмый.

(وَأَنْ تَجْمَعُوا بَيْنَ الأُخْتَيْنِ إِلا مَا قَدْ سَلَفَ) النساء: ٢٣

Мәгънәсе: **«Һәм бертуган ике кызны бергә җыеп никахлану сезгә тыелды, мәгәр бу эшне Исламга кадәр эшләдегез, Исламга кергәч, гафу ителдегез».**

٥١٠٨ - حَدَّثَنَا عَبْدَانُ أَخْبَرَنَا عَبْدُ اللهِ أَخْبَرَنَا عَاصِمٌ عَنْ الشَّعْبِيِّ سَمِعَ جَابِرًا ﵁ قَالَ: «نَهَى رَسُولُ اللهِ ﷺ أَنْ تُنْكَحَ الْمَرْأَةُ عَلَى عَمَّتِهَا أَوْ خَالَتِهَا» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Җәбир ﵁ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ хатынның әтисенең яки әнисенең бертуган апа-сеңелләренә өйләнеп, аларны бер ирдә бергә җыюдан тыйды».***

**З)** Мөслимә хатын-кызга мөселман булмаган кешегә (Исламны кабул иткәнчегә кадәр) кияүгә чыгарга тыела. Һәм шулай ук, мөселман ир-атка яһүд яки насара хатыннарыннан башка булган хатын-кызларга (Исламны кабул иткәнчегә кадәр) өйләнергә тыела (“әл-Бакара” 221, “әл-Мәидә” 5).

**К)** Зина кылучы хатын-кыз тәүбә иткәнчегә кадәр, аңа никахланырга ярамый.

(الزَّانِي لا يَنْكِحُ إِلا زَانِيَةً أَوْ مُشْرِكَةً وَالزَّانِيَةُ لا يَنْكِحُهَا إِلا زَانٍ أَوْ مُشْرِكٌ وَحُرِّمَ ذَلِكَ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ) النور: ٣

Мәгънәсе: **«Зина кылучы ир никахланмас, мәгәр зина кылучы хатынга яки мөшрикә хатынга никахланыр, вә зина кылучы хатынга һичкем никахланмас, мәгәр зина итүче ир яки мөшрик ир никахланыр. Зиначыларның никахы мөэминнәргә хәрам ителде».**

**Л)** Хаҗ яки гумрага ихрамланган кешенең никахлануы хакында гыйлем әһелләре арасында ике караш бар:

**1-** Тыела яки хәрам (бу карашны Мәлик, Шәфигый, Әхмәд һәм башкалар хуплады).

**2-** Рөхсәт ителә, әмма ләкин ихрамнан чыкканчыга кадәр якынлык кылырга тыела (бу караш Әбү Хәнифәдә билгеле).

**– Тыела диючеләрнең кайбер дәлилләре:**

١٤٠٩ - عَنْ عُثْمَانَ بْنِ عَفَّانَ ﷺ أَنَّ رَسُولَ اللهِ ﷺ قَالَ: «لا يَنْكِحُ الْمُحْرِمُ وَلا يُنْكَحُ وَلا يَخْطُبُ» [ مسلم ]

Мәгънәсе: Госман бин Гаффаннан ﷺ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ихрамдагы кешегә никахланырга, никахландырырга һәм шулай ук ярәшергә (кыз сорарга) тыела».***

**– Рөхсәт ителә, әмма ләкин ихрамнан чыкканчыга кадәр якынлык кылырга тыела диючеләрнең кайбер дәлилләре:**

عَنْ ابْنِ عَبَّاسٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُمَا «أَنَّ النَّبِيَّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ تَزَوَّجَ مَيْمُونَةَ وَهُوَ مُحْرِمٌ» [ البخاري١٨٣٧، و مسلم ١٤١٠ ]

Мәгънәсе: Ибен Габбас ﷺ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ Мәймүнәгә ихрамда килеш өйләнде».***

Мустафа әл-Гадавий үзенең “Җәмигъ әхкәм әл-Нисә” китабында ике тарафның да дәлилләрен искә алып узгач, азакта болай дип тәмамлады: *«Боларның (хәдисләрнең вә әсәрләрнең) һәм гыйлем әһелләренең карашларын барчасын да ачып салганнан соң, миңа бу ике хәдис белән дә гамәл итү тиешлеге әүвәлрәк күренде, Аллаһу әгъләм».* Һәм дәвам итеп әйтте: *«Госман хәдисендә ихрамдагы кешегә карата килгән тыю, хәрам тыю түгел (мәкруһ тыю). Бу нәтиҗә Госман һәм ибен Габбас хәдисләрен бергә җыйганнан соң. Бу төрле ысулны (сахих хәдисләрне бергә җыю ысулын) гыйлем әһелләре күп вакытта кулланалар. Мәсәлән, пәйгамбәребездән ﷺ баскан килеш эчкән кешене*

*тәнкыйтьләп килгән хәдисләр бар, шул ук вакытта аның (с.г.в.нең) басып эчкәнлеге хакында дөрес хәдисләр бар. Шуңа да, күпчелек галимнәр ике хәдисне бергә җыйганнан соң утырып эчү мөстәхәб дигән карашны хупладылар...».*

## Өйләнгәндә гыйффәтле (саф) кызларны сайлау хәерлерәк

٥٠٧٧ - عَنْ عَائِشَةَ رَضِيَ اللهُ عَنْهَا قَالَتْ: «قُلْتُ يَا رَسُولَ اللهِ أَرَأَيْتَ لَوْ نَزَلْتَ وَادِيًا وَفِيهِ شَجَرَةٌ قَدْ أُكِلَ مِنْهَا، وَوَجَدْتَ شَجَرًا لَمْ يُؤْكَلْ مِنْهَا فِي أَيِّهَا كُنْتَ تُرْتِعُ بَعِيرَكَ؟ قَالَ: «فِي الَّذِي لَمْ يُرْتَعْ مِنْهَا» تَعْنِي أَنَّ رَسُولَ اللهِ ﷺ لَمْ يَتَزَوَّجْ بِكْرًا غَيْرَهَا» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Гаишә әйтте: *«Мин пәйгамбәребездән ﷺ сорадым: «Йә Расүл Аллаһ! Әгәр дә син бер үзәнлеккә туктасаң һәм анда яфраклары ашалган вә яфраклары ашалмаган агачлар күрсәң, дөяңне ашатырга кайсы агачларга җибәрер идең?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Ашалмаган агачларга (җибәрер идем)».*** *Ягъни, пәйгамбәребез ﷺ Гаишәдән башка саф кыз булган хатынга өйләнмәде».*

Шулай ук, Бохарида килгән икенче бер хәдистә пәйгамбәребез ﷺ саф кыз булганга никахлануны хуплап болай диде:

٥٢٤٧ - «فَهَلا بِكْرًا تُلاعِبُهَا وَتُلاعِبُكَ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: ***«Әгәр дә саф кыз булганга өйләнсәң!».***

١٨٦١- حدثنا إبراهيم بن المنذر الحزامي حدثنا محمد بن طلحة التيمي حدثني عبد الرحمن بن سالم بن عتبة بن عويم بن ساعدة الأنصاري عن أبيه عن جده قال: قال رسول الله ﷺ: «عَلَيْكُمْ بِالأَبْكَارِ فَإِنَّهُنَّ أَعْذَبُ أَفْوَاهًا وَأَنْتَقُ أَرْحَامًا وَأَرْضَى بِالْيَسِيرِ» [ سنن ابن ماجة، تحقيق الألباني: حسن ]

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Саф кыз булганнарга өйләнегез, чөнки аларның авызлары тәмлерәк, шулай ук күбрәк бала табалар һәм сезне канәгатьләндерәләр».***

# Никахка килешенгән кызга икенче егетнең тәкъдим ясавы хакында

Никахка килешенгән яки ярәшелгән кызга икенче ир-ат тәкъдим ясый алмый. Чөнки, бу гамәл ике мөселман арасында бер-берсенә карата дошманлык уята, һәм бер мөселманның үзен-үзе мактап вә өстен куеп икенче мөселманны аның тарафыннан түбәнсетүгә китерә. Дүрт имам да моның тыелган гамәл икәнлегенә килештеләр, иллә-мәгәр ул никахның батылмы яки дөресме икәнлегендә ике карашка бүленделәр. Имам Мәликтә һәм Әхмәдтәге бер риваять буенча ул никах батыл була. Әбү Хәнифә, Шәфигый һәм Әхмәднең икенче риваяте буенча ул никах дөрес булып кала.

Бу гамәлнең ярамаганлыгы пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләреннән билгеле.

٥١٤٢ - عن ابْنِ عُمَرَ رَضِيَ اللهُ عَنْهُمَا قال: «نَهَى النَّبِيُّ ﷺ أَنْ يَبِيعَ بَعْضُكُمْ عَلَى بَيْعِ بَعْضٍ وَلا يَخْطُبَ الرَّجُلُ عَلَى خِطْبَةِ أَخِيهِ حَتَّى يَتْرُكَ الْخَاطِبُ قَبْلَهُ أَوْ يَأْذَنَ لَهُ الْخَاطِبُ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Ибен Гомәр  әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ сезгә сәүдәдә бер-берегезнең сатуы өстенә сатудан тыйды[13] һәм шулай ук, мөселман кардәше ярәшеп килешкән кызга икенче кешене ярәшүдән тыйды. Иллә-мәгәр беренче ярәшкән егет кире какса яки рөхсәт бирсә генә ярәшергә мөмкин».***

Шәйх әл-Ислам ибен Тәймия моның хәрамлыгын бәян итеп болай диде: ***«Дүрт имам (Әбү Хәнифә, Мәлик, Шәфигый һәм Әхмәд) һәм башкалар, алардан билгеле булган карашлар буенча, бер кешенең икенче кардәше өстенә кыз ярәшүенең хәрам икәнлегенә килештеләр».*** (Мәҗмугъ әл-Фәтәвә, 32-7).

---

13 Ягъни, әгәр дә сатучы белән алучы билгеле хакка килештеләр икән, алар янына икенче сатучы килеп, алучыга: «Мин сиңа бу хактан арзангарак бирәм, миннән ал», — дип беренче сатучы өстенә сата алмый

# Әгәр егет кызга тәкъдим ясаса, ләкин кыз ризалыгын да, кире кагуын да әйтмәсә яки уйлыйм әле дисә, бу вакытта аңа икенче егет тәкъдим ясый аламы?

Әгәр дә егет кызга тәкъдим ясаса, ләкин кыз бер төрле дә җавап бирмәсә (тәкъдимне кабул да итмәсә, кире дә какмаса) яки уйлыйм әле дисә, бу вакытта аңа икенче егет тәкъдим ясый ала. Ә инде кыз ризалыгын белдерсә һәм егетне ышандырса, ул вакытта бу кызга беркем дә тәкъдим ясый алмый.

Бер төрле дә җавап бирмәгән кызга икенче егет тәкъдим ясый ала дигәнгә дәлил итеп пәйгамбәребезнең ﷺ Мөслимдә килгән 1480нче хәдисен алырга була. Бу хәдистә искә алынганча Фатыйма бинт Кайс үзенә Мугавия бин Әбий Суфиян белән Әбү Җәһмнең ярәшкәннәрен пәйгамбәребезгә ﷺ әйткәч, расүлебез ﷺ аңа болай диде:

١٤٨٠- ...قَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «أَمَّا أَبُو جَهْم فَلا يَضَعُ عَصَاهُ عَنْ عَاتِقِهِ وَأَمَّا مُعَاوِيَةُ فَصُعْلُوكٌ لا مَالَ لَهُ انْكِحِي أُسَامَةَ بْنَ زَيْدٍ» فَكَرِهْتُهُ ثُمَّ قَالَ: «انْكِحِي أُسَامَةَ» فَنَكَحْتُهُ فَجَعَلَ اللهُ فِيهِ خَيْرًا وَاغْتَبَطْتُ [ مسلم ]

Мәгънәсе: ***«...Әмма Әбү Җәһм — аның иңсәсеннән таягы төшми, әмма Мугавия — ул фәкыйрь, аның малы юк. Үсәмә бин Зәйдкә никахлан!».*** *Мин (Фатыйма бинт Кайс Үсәмә бин Зәйдне) ошатмадым, шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ тагын кабатлап әйтте:* ***«Үсәмә бин Зәйдкә никахлан!».*** *Пәйгамбәребез ﷺ әйткәнчә Үсәмәгә никахландым һәм Аллаһ тәгалә аңарда бик күп хәерлек кылды, хәтта мин бик бәхетле булып, аның бетмәвен теләдем».*

# Икенче, яки өченче, яки дүртенче хатын булып кияүгә чыгучы хатын-кыз көндәшен талак итүне сорый алмый

Гадәттә икенче хатын булып кияүгә чыгучы хатын-кызлар, аларга тәкъдим ясаган ирләрдән беренче хатыннарын аеруны таләп итәләр, һәм: *«Беренче хатыныңны аерсаң, мин сиңа кияүгә чыгарга риза»,* — дип шарт куялар. Кайбер ирләр үзләренең холыкларының зәгыйфьлеге яки гыйлемсезлекләре сәбәпле, бу шарт хатын-кызның хакыдыр дип уйлап, риза булалар. Шулай ук, бу шартны хатын-кызлар гыйлемсезлек аркасында, яки инде шәйтан вәсвәсәсе аркасында куялар, Аллаһу мүстәган. Пәйгамбәребез ﷺ мондый шарт куюны тыеп болай диде:

٥١٥٢ - حَدَّثَنَا عُبَيْدُ اللَّهِ بْنُ مُوسَى عَنْ زَكَرِيَّاءَ هُوَ ابْنُ أَبِي زَائِدَةَ عَنْ سَعْدِ بْنِ إِبْرَاهِيمَ عَنْ أَبِي سَلَمَةَ عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رضي الله عنه عَنِ النَّبِيِّ ﷺ قَالَ: «لا يَحِلُّ لامْرَأَةٍ تَسْأَلُ طَلاقَ أُخْتِهَا لِتَسْتَفْرِغَ صَحْفَتَهَا فَإِنَّمَا لَهَا مَا قُدِّرَ لَهَا» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан رضي الله عنه, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«(Бер иргә икенче, өченче яки дүртенче хатын булып кияүгә чыгучы) хатын-кызга беренче хатынның урынын алу өчен, көндәшен талак кылуны сорарга ярамый, чөнки ничек кенә булса да аңа тәкъдирдә нәрсә язылган булса, шул гына була».***

Шулай ук, бу хакта башка сахих хәдисләр бар, һәм алар барсы да бу гамәлдән катгый рәвештә тыю мәгънәсендә килделәр. Шуңа да, хатын-кыз мондый шартны кую алдыннан бик яхшылап уйласын, ул пәйгамбәребез ﷺ кушканча эшлиме, әллә расүлебезнең хөкеменә каршы барып шәйтан кушканча эшлиме?!

## Мәһер һәм аның хөкеме

Никахлана торган хатын-кызга ир-ат тарафыннан бирелә торган мал **«мәһер»** дип атала. Коръәндә ул «садак», «әҗер» һәм «фәрыйда» исемнәре белән искә алынды.

Ибен Габд әл-Бир үзенең "әл-Истизкәр" китабында мәһернең хөкеме вәҗиб, ягъни фарыз икәнлегенә барча гыйлем әһелләре дә килеште дип әйтеп узды. Моның фарызлыгын бәян итеп Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде:

(وَآتُوا النِّسَاءَ صَدُقَاتِهِنَّ نِحْلَةً) النساء: ٤

Мәгънәсе: **«Хатыннарыгызга мәһерләрен чын күңелдән, аларны кимсетмичә бирегез...».**

(فَمَا اسْتَمْتَعْتُمْ بِهِ مِنْهُنَّ فَآتُوهُنَّ أُجُورَهُنَّ فَرِيضَةً) النساء: ٢٤

Мәгънәсе: **«...Алардан алган рәхәтлек өчен, тиешле бүләкләрен (мәһерләрен) бирегез!».**

## Мәһернең күләме

Мәһернең күплегенең чиге юк, һәм бу гыйлем әһелләренең бердәм карашы. Чөнки Аллаһ тәгалә Коръәндә бу хакта болай диде:

(وَآتَيْتُمْ إِحْدَاهُنَّ قِنْطَارًا) النساء: ٢٠

Мәгънәсе: **«...Хатыныгызның берсенә (талак кылынасына яки икенчегә өйләнәсенә) мәһерне күп итеп биргән булсагыз...».**

Әмма мәһернең иң азы күпме булырга тиеш дигән мәсьәләдә, гыйлем әһелләре арасында капма каршылыклы фикерләр барлыкка килде:

**1)** Әс-Сәүрий, әл-Әүзәгый, Ләйс бин Сәгъд, Шәфигый һәм Әхмәд бин Хәнбәл мәзһәбләре буенча, мәһернең азлыгы аерым микъдар белән билгеләнмәгән, бәлки егет белән кызның килешүләреннән тора дигән караш билгеле. Һәм

үзләренең карашларын Бохарида вә Мөслимдә ***«Тимер йөзек булса да биреп өйлән...»,*** — дигән, һәм Тирмизидә вә ибен Мәҗәһдә килгән, Бәнү Фәзәра кабиләсеннән булган хатын-кызның мәһер итеп ике аяк киеменә риза булып кияүгә чыккан, хәдисләр белән дәлилләделәр. Шулай ук, ошбу аятьтә искә алынган малларыгыз яки байлыкларыгыз дигәнгә күбе дә, азы дә керә диделәр:

(وَأُحِلَّ لَكُمْ مَا وَرَاءَ ذَلِكُمْ أَنْ تَبْتَغُوا بِأَمْوَالِكُمْ مُحْصِنِينَ غَيْرَ مُسَافِحِينَ) النساء ٢٤

Мәгънәсе: **«Шулай ук, сезгә башка хатыннар рөхсәт ителде, әгәр дә сез аларны үзегезенең малларыгыз (байлыкларыгыз) белән зинадан вә золымнан сакланган хәлдә яхшы мөгамәлә белән таләп итәсез икән».**

Ибен Кудамә сахәбәләрнең күп мәһергә дә, азга да өйләнгәннәрен искә алып узды, хәтта кайберәүләре күпмедер ризык күләмен мәһер итеп өйләнделәр, һәм Сәгыйд бин Мүсәйб үзенең кызын ике дирһәмгә мәһер итеп кияүгә бирде, диде.

**2)** Гыйлем әһелләреннән ән-Нәхәгый, ибен Шүбрумәһ, Сәгыйд бин Җүбәйр, Әбү Хәнифә һәм Мәликләр мәһернең иң аз микъдарын билгеләү вәҗиб һәм шул билгеләнгән күләмнән дә ким булырга тиеш түгел диделәр. Ләкин алар мәһернең иң аз микъдарын билгеләүдә үз-ара төрле карашларга бүленделәр. Әбү Хәнифә буенча мәһер ун дирһәмнән яки аның бәясенә тиң әйбердән дә аз булырга тиеш түгел. Мәлик динарның дүрттән бер өлеше яки өч дирһәмнән дә ким булырга тиеш түгел диде. Шулай ук, гыйлем әһелләре тарафыннан башка фикерләр әйтелде. Ләкин мәһернең иң аз күләмен билгеләүчеләрнең сүзләрен куәтләп килгән сахих дәлилләр билгеле түгел. Ә инде «мәһер ун дирһәмнән да ким булмый», — дигән хәдис зәгыйфь, чөнки бу хәдисне риваять иткән Мүбәшшир бин Губәйд хакында Бохари, әд-Дәр Кутный, Әхмәд һ.б. аның хәдисләре кабул ителми, диделәр. (Ируә әл-Галилне кара)

Шушыларны искә алып узганнан соң, безгә дөресрәк дип күренгәне, мәһер хатын-кызны кимсетерлек бик аз да һәм ир-атка авырлык китерерлек бик күп тә булырга тиеш түгел. Аллаһу әгъләм.

## Кем ул никахтагы вәли?

**Вәли — *ул, хатын-кыз яки кечкенә бала кебек үзен-үзе никахлый алмаган кешене кияүгә бирүче яки өйләндерүче мөселман, бәлигъ, варис, гакылы тулы булган якын ир кешесе.***

Тулы гакыллы, бәлигъ булган хатын-кыз кияүгә чыгу өчен аның вәлие булырга тиешме дигән мәсьәләдә гыйлем әһелләре берничә карашка бүленделәр:

**1)** Мәлик, Шәфигый һәм Әхмәдләр; тулы гакыллы, бәлигъ булган хатын-кызның никахта вәлие булуны шарт, диделәр. Кияүгә чыгучы хатын, булсын гыйффәтле (саф) кыз яки тол хатын, аермасы юк.

**2)** Әбү Хәнифә, Зөфәр, әш-Шәгъбий һәм әз-Зүһрий кебек гыйлем әһелләре; хатын-кыз кияүгә чыкканда аның вәлие булуы шарт түгел, диделәр.

**3)** Дауыд әз-Заһирий; гыйффәтле (саф) кыз кияүгә чыкканда аның вәлие булу шарт, ә инде тол хатын кияүгә чыкканда аңа вәли шарт түгел, диде.

**4)** Мөхәммәд бин Сирин, әл-Касыйм бин Мөхәммәд, әл-Хәсән бин Салих һәм Әбү Юсуф кебек гыйлем әһелләре; хатын-кыз әгәр дә вәлисез кияүгә чыкса, аның бу гамәле вәли карамагында була. Әгәр вәли хупласа — кияүгә чыгуы дөрес була, хупламаса — дөрес булмый, диделәр.

• <u>Беренче</u>: **Вәли шарт диючеләрнең кайбер дәлилләре:**

***Коръән аятьләре:***

(الرِّجَالُ قَوَّامُونَ عَلَى النِّسَاءِ بِمَا فَضَّلَ اللَّهُ بَعْضَهُمْ عَلَى بَعْضٍ) النساء: ٣٤

Мәгънәсе: **«Ирләр хатынга әдәп, тәрбия бирмәк өчен каимнәрдер. Аллаһ Тәгалә мәхлукларны кайберләрен кайберләреннән артык кылу белән, ирләр гакылда, куәттә хатыннардан өстен булды...».**

(وَأَنْكِحُوا الأَيَامَى مِنْكُمْ) النور: ٣٢

Мәгънәсе: **«Үзләрегездән ирсез хатыннарны вә хатынсыз ирләрне өйләндерегез...».**

(فَانْكِحُوهُنَّ بِإِذْنِ أَهْلِهِنَّ) النساء: ٢٥

Мәгънәсе: **«Кәнизәк хатыннарга хуҗаларының рөхсәте белән никахланыгыз».**

(وَإِذَا طَلَّقْتُمُ النِّسَاءَ فَبَلَغْنَ أَجَلَهُنَّ فَلا تَعْضُلُوهُنَّ أَنْ يَنْكِحْنَ
أَزْوَاجَهُنَّ إِذَا تَرَاضَوْا بَيْنَهُمْ بِالْمَعْرُوفِ) البقرة: ٢٣٢

Мәгънәсе: **«Әгәр хатыннарны талак кылсагыз һәм аларның гыйддәтләре үтсә, ул хатыннарны әүвәлге ирләре белән никахлашудан тыймагыз** (кайбер тәфсир галимнәре монда мөрәҗәгать вәлиләргә кагыла диде, икенчеләре талак кылган иргә яки гомуми барчасына да кагыла диде)**, әгәр үзләре шәригать кушканча яшәргә риза булсалар».**

(قَالَ إِنِّي أُرِيدُ أَنْ أُنْكِحَكَ إِحْدَى ابْنَتَيَّ هَاتَيْنِ) القصص: ٢٧

Мәгънәсе: **«Әйтте: «Мин ошбу ике кызның берсен сиңа никахламакны телим».**

***Хәдисләр:***

٢٠٨٥ - عَنْ أَبِى مُوسَى ﷺ أَنَّ النَّبِىَّ صلى الله عليه وسلم قَالَ «لاَ نِكَاحَ إِلاَّ بِوَلِىٍّ»
[ سنن أبي داود، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Муса әл-Әшгарийдән ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Вәлисез никах булмый».***

٢٠٨٣- عَنْ عَائِشَةَ قَالَتْ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ «أَيُّمَا امْرَأَةٍ نَكَحَتْ بِغَيْرِ إِذْنِ مَوَالِيهَا فَنِكَاحُهَا بَاطِلٌ» ثَلاَثَ مَرَّاتٍ... [ أبو داود، تحقيق الألباني :صحيح ]

Мәгънәсе: Гаишәдән, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәр хатын-кыз вәлиенең рөхсәтеннән башка никахланса, аның ул никахы дөрес булмый...»,*** *— өч тапкыр.*

١٨٨٢- عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ «لاَ تُزَوِّجُ الْمَرْأَةُ الْمَرْأَةَ وَلاَ تُزَوِّجُ الْمَرْأَةُ نَفْسَهَا فَإِنَّ الزَّانِيَةَ هِىَ الَّتِى تُزَوِّجُ نَفْسَهَا» [ ابن ماجة، تحقيق الألباني: صحيح - دون جملة الزانية - ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хатын-кыз хатын-кызны кияүгә бирә алмый, шулай ук хатын-кыз үзен-үзе кияүгә бирә алмый».***

***Сахәбәләрдән вә тәбигыйннәрдән кайбер әсәрләр:***

عَنْ عُمَرَ بْنِ الْخَطَّابِ قَالَ: «لاَ تُنْكَحُ الْمَرْأَةُ إِلاَّ بِإِذْنِ وَلِيِّهَا أَوْ ذِى الرَّأْىِ مِنْ أَهْلِهَا أَوِ السُّلْطَانِ» (سنن الدار قطني ٢٢٩/٣ - موقوف صحيح لغيره)

Мәгънәсе: Гомәр ﵁ әйтте: ***«Хатын-кыз вәлиенең яки үзенең әһеленнән булган базымлы кешенең яки солтанның рөхсәтеннән башка никахлана алмый».***

عَنْ عَلِيٍّ رَضِىَ اللَّهُ عَنْهُ قَالَ: «أَيُّمَا امْرَأَةٍ نُكِحَتْ بِغَيْرِ إِذْنِ وَلِيِّهَا فَنِكَاحُهَا بَاطِلٌ لاَ نِكَاحَ إِلاَّ بِإِذْنِ وَلِىٍّ» قال البيهقي: هذا إسناده صحيح [ السنن الكبرى للبيهقي ]

Мәгънәсе: Гали ﵁ әйтте: ***«Әгәр дә берәр хатын-кыз вәлиенең рөхсәтеннән башка никахланса, аның ул никахы батыл була. Вәли рөхсәтеннән башка никах булмый!».***

عن ابن عباس ﵁ قال : «لا نكاح إلا بإذن ولي أو سلطان» [ المصنف، حسن ]

Мәгънәсе: Ибен Габбас ﵁ әйтте: ***«Вәлинең яки солтанның рөхсәтеннән башка никах булмый».***

١٠٤٩٤- عن أبي هريرة ﵁ قال : «لا تنكح المرأة نفسها، فإن الزانية تنكح نفسها» [ مصنف عبد الرزاق، موقوف صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайра ﷺ әйтте: ***«Хатын-кыз (вәлисез) үзен-үзе никахлатмый, чөнки, хакыйкатьтә, зиначы хатын гына үзен-үзе никахлый».***

• **<u>Икенче</u>: Вәли шарт түгел диючеләрнең кайбер дәлилләре:**

***Коръән аятьләре:***

(وَإِذَا طَلَّقْتُمُ النِّسَاءَ فَبَلَغْنَ أَجَلَهُنَّ فَلا تَعْضُلُوهُنَّ أَنْ يَنْكِحْنَ
أَزْوَاجَهُنَّ إِذَا تَرَاضَوْا بَيْنَهُمْ بِالْمَعْرُوفِ) البقرة: ٢٣٢

Мәгънәсе: **«Әгәр хатыннарны талак кылсагыз һәм аларның гыйддәтләре үтсә, ул хатыннарны әүвәлге ирләре белән никахлашудан тыймагыз** (кайбер тәфсир галимнәре монда мөрәҗәгать вәлиләргә кагыла диде, икенчеләре талак кылган иргә яки гомуми барчасына да кагыла диде)**, әгәр үзләре шәригать кушканча яшәргә риза булсалар».**

Бу аятьтә никах хатыннарга бәйле, шуңа да алар вәлисез үзләре генә никахлана алалар. Шулай ук, әгәр дә хатын белән ир килешсәләр, вәлиләргә хатын-кызның үз-үзен никахлаудан тыерга ярамый диелде, Аллаһу әгъләм.

(وَامْرَأَةً مُؤْمِنَةً إِنْ وَهَبَتْ نَفْسَهَا لِلنَّبِيِّ إِنْ أَرَادَ النَّبِيُّ أَنْ يَسْتَنْكِحَهَا) الأحزاب: ٥٠

Мәгънәсе: **«Шулай ук, үзен пәйгамбәргә һибә итүче мөэминә хатынны хәләл иттек, әгәр пәйгамбәр аны никахларга теләсә».**

(فَإِنْ طَلَّقَهَا فَلا تَحِلُّ لَهُ مِنْ بَعْدُ حَتَّى تَنْكِحَ زَوْجًا غَيْرَهُ) البقرة: ٢٣٠

Мәгънәсе: **«Әгәр берәү хатынын өченче мәртәбә талак кылса, ул хатын иренә хәләл булмас, хәтта икенче иргә никахланып аерылганга чаклы».**

(فَإِنْ طَلَّقَهَا فَلا جُنَاحَ عَلَيْهِمَا أَنْ يَتَرَاجَعَا) البقرة: ٢٣٠

Мәгънәсе: **«Өченче талактан соң бу хатынны никахлап алган ир талак кылса, әүвәлге ир белән никахлансалар, иргә дә, хатынга да гөнаһ булмас».**

Монда вәли искә алынмыйча, никах беренче ир белән хатынга бәйләнде.

***Хәдисләр:***

١٤٢١ - عَنْ ابْنِ عَبَّاسٍ ﵄ أَنَّ النَّبِيَّ ﷺ قَالَ: «الأَيِّمُ أَحَقُّ بِنَفْسِهَا مِنْ وَلِيِّهَا وَالْبِكْرُ تُسْتَأْذَنُ فِي نَفْسِهَا وَإِذْنُهَا صُمَاتُهَا» [ مسلم ]

Мәгънәсе: Ибен Габбастан ﵄, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ирсез яки тол хатын-кыз вәлиенә караганда үзенә-үзе хак-лырак, ә гыйффәтле (саф) кызның ризалыгы сорала, һәм аның (оялып) дәшмәве ризалыгын белдерә».***

Бу хәдис белән шулай ук Дауыд әз-Заһирий тол хатын-кызга вәли шарт түгел, ә саф кызга шарт дигән карашын исбатлады.

٢١٠٠ - عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ ﵄ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ قَالَ: «لَيْسَ لِلْوَلِىِّ مَعَ الثَّيِّبِ أَمْرٌ وَالْيَتِيمَةُ تُسْتَأْمَرُ وَصَمْتُهَا إِقْرَارُهَا» [ سنن أبي داود، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Ибен Габбастан ﵄, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ирсез яки тол хатын-кызда вәлинең хакы юк, ә ятим кызның ризалыгы сорала, һәм аның (оялып) дәшмәве ризалыгын белдерә».***

***Сахәбәләрдән вә тәбигыйннәрдән кайбер әсәрләр:***

عَنْ عُمَرَ بْنِ الْخَطَّابِ قَالَ: «لاَ تُنْكَحُ الْمَرْأَةُ إِلاَّ بِإِذْنِ وَلِيِّهَا أَوْ ذِى الرَّأْىِ مِنْ أَهْلِهَا أَوِ السُّلْطَانِ» [ سنن الدار قطني ٢٢٩/٣ - موقوف صحيح لغيره ]

Мәгънәсе: Гомәр ﵁ әйтте: ***«Хатын-кыз вәлиенең яки үзенең әһеленнән булган базымлы кешенең яки солтанның рөхсәтеннән башка никахлана алмый».***

Хатын-кызның әһеленнән булган базымлы кешене аерып әйтү вәлигә керми, шуның өчен дә вәли шарт түгел.

Шулай ук, Габдурраззакның "Мусаннаф"ында әз-Зүһрий, Гата һәм башкалардан килгән риваятьләрне китерделәр. Һәм ибен Әбий Шәйбәһнең "Мусаннаф"ында риваять ителгән Гаишә, абыйсы Габдурраһманның кызы

Хафсаны әл-Мүнзир бин әз-Зүбәйргә никахлаганы белән дәлилләделәр.

Без инде боларның барысын да карап узгач, беренчеләрнең, ягъни вәли шарт диючеләрнең карашын көчлерәк вә дөресрәк дип табабыз, Аллаһу әгъләм.

## Дүрт мәзһәб буенча никахтагы вәлинең тәртибе

| Мәртәбә | Хәнәфи | Мәлики | Шәфигый | Хәнбәли |
|---|---|---|---|---|
| **беренче** | уллары аннан соң аларның уллары | уллары аннан соң аларның уллары | әтисе аннан соң бабасы | әтисе аннан соң бабасы |
| **икенче** | әтисе аннан соң бабасы | әтисе | абыйлары аннан соң аларның уллары | уллары аннан соң аларның уллары |
| **өченче** | абыйлары аннан соң аларның уллары | абыйлары аннан соң аларның уллары | әтисенең абыйлары аннан соң аларның уллары | абыйлары аннан соң аларның уллары |
| **дүртенче** | әтисенең абыйлары аннан соң аларның уллары | бабасы | — | әтисенең абыйлары аннан соң аларның уллары |

## Кәфер илендә яшәгән һәм вәлие булмаган хатын-кыз ничек кияүгә чыга?

Бу мәсьәлә без яшәгән илдә бик тә көнүзәк мәсьәлә булып тора. Белүебезчә, әгәр дә кызның нәсел-нәсәбе буенча вәлие юк икән, ул вакытта мөселман илендә аның вәлие булып солтан санала. Ә безгә — солтаны да, казые да булмаган илдә яшәүче мөселманнарга нишләргә соң?

Бу хакта Гомәр әл-Әшкар менә нәрсә ди: «Әгәр дә мөселманнарның солтаны булмаса, яки хатын-кыз Америка, Англия, Русия кебек кәфер илендә яшәп, аның вәлие гомумән булмаса, ләкин ул илләрдә мөселманнарның хәлләрен кайгыртучы Ислам оешмасы булса, ошбу оешма хатын-кызның кияүгә чыгуын хәстәрли торган була. Шулай ук, әгәр дә ул җирдә мөселманнарның буйсына торган һәм аларның хәлләрен хәстәрли торган әмирләре бар икән, бу вакытта никахка ул мәсъүл була».

Ә инде әгәр дә ул яшәгән җирдә буйсына торган мөселман хәкиме дә, имамы да (мәчет имамы түгел, бәлки мөселманнарның буйсына торган гомуми имамы — әмире, чөнки имамлык ике төрлегә бүленә; беренчесе кечкенә имамлык — бу инде мәчеттә биш вакыт намаз, гаед һәм җомга намазларын укытучы, икенчесе зур имамлык — бу инде мөселманнар буйсына торган мөселман булган солтан яки патша) яки аңа буйсына торган бер мөселман әмире дә булмаса, бу вакытта гадел бер мөселман ир-ат (мәчет имамы да ярый) ошбу никах мәсьәләсен үз өстенә ала....».

Кайберәүләр бу вакытта хатын-кызны кияүгә бирү мәсъүлиятен үз өсләренә галимнәр ала дип әйтеп узды. (Әхкәм әл-Зиүәҗ). Аллаһу әгъләм.

# Никахта шәһидләр мәсьәләсе

Шәһидләрсез һәм игълан кылынмыйча үткәрелгән никах батыл була яки дөрес булмый дигән караштa гыйлем әһелләре арасында капма-каршылык юк. Шулай ук, алар ике һәм күбрәк ир-ат шәһидлек кылган һәм игълан ителгән никахның дөрес булуында килештеләр. Әмма гыйлем әһелләре, шәһидләре булып, ләкин игълан ителмәгән, шулай ук игълан ителеп, шәһидләре булмаган никахта төрле карашларга килделәр:

**1)** Ибен Шиһәб, әл-Ләйс бин Наср (ибен Тәймиянең шәйхы), Әхмәд бин Хәнбәлнең бер риваятендә һәм имам Мәлик буенча, никахта шәһидләрнең булуы шарт түгел, ләкин никахны игълан кылу шарт булып тора.

Ибен Кудәмә әл-Мугънийдә болай диде: *«Әхмәд бин Хәнбәлдә (бер риваятендә) никах шәһидләрсез дөрес була, чөнки ибен Гомәр, әл-Хәсән бин Галий, ибен Зөбәйр, Сәлим бин Габдуллаһ бин Гомәр, Хәмзә бин Габдуллаһ бин Гомәр шулай эшләделәр. Шулай ук, бу фикерне Габдуллаһ бин Идрис, Габдурахман бин Мәһдий, Язид бин Һарун, әл-Ганбәрий, Әбү Сәүр, ибен әл-Мүнзир, ибен Шиһәб әл-Зүһрий һәм Мәликләр, никах игълан ителсә (шәһидләрнең булуы шарт түгел) дип әйтте».*

Бу хакта мәликиләрдән ибен Габд әл-Бир “әл-Истизкәр” китабында болай дип әйтеп узды: *«Мәлик буенча никахта шәһидләрнең булуы фарыз түгел, шәһидләрсез дә никах кылырга рөхсәт ителә. Ләкин нәсел-нәсәбләрне саклау өчен игълан итеп белгертү фарыз булып тора».*

Алар үзләренең сүзләрен, никахтагы шәһидләр шарт дип бер сахих дәлил дә килмәде, һәм пәйгамбәребез ﷺ моны бәян итеп узмады диделәр.

Ләкин мәлики мәзһәбенең ахыргы галимнәре, никахта шәһидләрнең булуы, никахның бер рөкененнән (шартыннан) дип әйттеләр.

**2)** Әбү Хәнифә, Шәфигый һәм Әхмәд бин Хәнбәлдән билгеле булган мәшһүр риваятьтә никахта шәһидләрнең булуы шарт булып тора.

Хәнәфиләрдән әл-Кәсәний “Бәдәигъ әл-Санаигъ” китабында болай дип әйтеп узды: *«Күпчелек галимнәрнең әйтүе буенча шәһидлек кылу (шәһидләрнең булуы) никахның дөреслегенә шарт булып тора».*

Ән-Нәвәвий Шәфигый мәзһәбенең карашын бәян итеп болай диде: *«Өченче рөкен: Шәһидлек кылу. Никахта ике ир кеше шәһид булмаса, никах дөрес булмый».*

Ибен Кудәмә әл-Мугънийдә: *«Әхмәдтән мәшһүр булган риваять буенча никах ике шәһидсез дөрес булмый. Бу караш Гомәр һәм Галидан риваять ителде. Шулай ук бу фикерне ибен Габбас, Сәгыйд бин әл-Мүсәйб, Җәбир бин Зәйд, әл-Хәсән, ән-Нәхәгый, әс-Сәүрий һәм әл-Әүзәгыйлар әйтеп узды»,* — диде.

Бу карашны әйтүчеләрнең кайбер дәлилләреннән Әбү Муса әл-Әшгарийдән килгән хәдис.

«لا نِكَاحَ إِلَّا بِوَلِيّ وَ شَاهِدَيْن» [ الجامع الصغير،تحقيق الألباني صحيح ]

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Вәлисез һәм ике шәһидсез никах (дөрес) булмый».***

***Шәһидләрдә нинди шартлар булырга тиеш:***

**1)** Ислам (шәһидләрнең мөселман булулары тиешле, чөнки кәферләрнең шәһәдәтләре кабул ителми).

**2)** Бәлигъ һәм гакыллы булу.

**3)** Ир-ат (Әбү Хәнифә белән Әхмәд карашлары буенча никахта әгәр дә шәһидлеккә ике ир-ат табылмаса, ул вакытта бер ир һәм ике хатын-кыз рөхсәт ителә).

**4)** Гаделлек (Әбү Хәнифә буенча шәһидкә гаделлек шарт түгел).

**5)** Кабул һәм иҗәбне ягъни ике якның да ризалыкларын үз колаклары белән ишетеп, аңларга тиешләр.

# Никахка бәйле кайбер хәдисләр

١٤٢٩ - عَنْ ابْنِ عُمَر ﷺ أَنَّ النَّبِيَّ ﷺ قَالَ: «إِذَا دُعِيَ أَحَدُكُمْ إِلَى وَلِيمَةِ عُرْسٍ فَلْيُجِبْ» [ مسلم ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гомәрдән ﷺ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәрегез никах туе мәҗлесенә чакырылсагыз, барыгыз (кире какмагыз)!».***

٢١٣٠ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ أَنَّ النَّبِيَّ ﷺ كَانَ إِذَا رَفَّأَ الإِنْسَانَ إِذَا تَزَوَّجَ قَالَ: «بَارَكَ اللهُ لَكَ وَبَارَكَ عَلَيْكَ وَجَمَعَ بَيْنَكُمَا فِي خَيْرٍ» [ أبو داود، حسن ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﷺ, Пәйгамбәребез ﷺ өйләнгәннәрне тәбрикләп әйтә иде: «***Аллаһ сиңа барча яклап та бәрәкәт бирсен, һәм сезне (икегезне) хәерлелектә берләштерсен!***» (БәракАллаһу ләкә үә бәракә галәйкә үә җәмәга бәйнәкүмә фи хайр).

٢١٦٠ - عَنْ عَمْرِو بْنِ شُعَيْبٍ عَنْ أَبِيهِ عَنْ جَدِّهِ عَنْ النَّبِيِّ ﷺ قَالَ: «إِذَا تَزَوَّجَ أَحَدُكُمْ امْرَأَةً أَوْ اشْتَرَى خَادِمًا فَلْيَقُلْ: اللَّهُمَّ إِنِّي أَسْأَلُكَ خَيْرَهَا وَخَيْرَ مَا جَبَلْتَهَا عَلَيْهِ وَأَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهَا وَمِنْ شَرِّ مَا جَبَلْتَهَا عَلَيْهِ وَإِذَا اشْتَرَى بَعِيرًا فَلْيَأْخُذْ بِذِرْوَةِ سَنَامِهِ وَلْيَقُلْ مِثْلَ ذَلِكَ قَالَ أَبُو دَاوُد زَادَ أَبُو سَعِيدٍ ثُمَّ لِيَأْخُذْ بِنَاصِيَتِهَا وَلْيَدْعُ بِالْبَرَكَةِ فِي الْمَرْأَةِ وَالْخَادِمِ» [ أبو داود، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Гамр бин Шүгайб әтисеннән, бабасыннан риваять итеп әйтте, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәрегез өйләнә яки кол сатып ала икән, ошбу рәвештә дога кылсын: “Йә Аллаһ! Мин Синнән хәерлесен сорыйм, һәм Син хәерле холыклы, вә хәерле сыйфатлы итеп халык кылган (хатынны яки колны) сорыйм. (Йә Аллаһ!) Сиңа ул хатынның яки колның зыяныннан, һәм аларда булган зыянлы холык вә сыйфатлардан сыгынам!” Әгәр дөя сатып алса, аның өркәченнән (дөянең өске өлешендәге бөкресе) тотып, шулай ук әйтсен!».*** Әбү Сәгыйд өстәп әйтте: *«Хатынның яки колның маңгай чәченнән тотып бәрәкәт сорап дога кылсын!».*

٦٣٨٨ - حَدَّثَنَا عُثْمَانُ بْنُ أَبِي شَيْبَةَ حَدَّثَنَا جَرِيرٌ عَنْ مَنْصُورٍ عَنْ سَالِمٍ عَنْ كُرَيْبٍ عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُمَا قَالَ: قَالَ النَّبِيُّ ﷺ: «لَوْ أَنَّ أَحَدَهُمْ إِذَا أَرَادَ أَنْ يَأْتِيَ أَهْلَهُ قَالَ: بِاسْمِ اللهِ اللَّهُمَّ جَنِّبْنَا الشَّيْطَانَ وَجَنِّبْ الشَّيْطَانَ مَا رَزَقْتَنَا فَإِنَّهُ إِنْ يُقَدَّرْ بَيْنَهُمَا وَلَدٌ فِي ذَلِكَ لَمْ يَضُرَّهُ شَيْطَانٌ أَبَدًا» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Ибен Габбастан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәү хатыны белән якынлашырга теләгәндә ошбу рәвештә дога кылса: (Бисмилләһ, Аллаһүммә джәннибнәш-шәйтан, үә джәннибиш-шәйтанә мә разәкътәнә) «Бисмилләһ. Йә Аллаһ! Бездән шәйтанны ерагайт! Һәм безгә биргән (баладан) шәйтанны ерагайт!», — һәм алар ошбу якынлашуларыннан балага узса, ул балага шәйтан беркайчан да зыян итә алмый».***

٣٢٣٧ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ ﵁ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «إِذَا دَعَا الرَّجُلُ امْرَأَتَهُ إِلَى فِرَاشِهِ فَأَبَتْ فَبَاتَ غَضْبَانَ عَلَيْهَا لَعَنَتْهَا الْمَلَائِكَةُ حَتَّى تُصْبِحَ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә ире хатынын үзенең янына ятакка чакырса (якынлык кылырга), һәм хатыны аны кире кагып, ире аңа ачуланган хәлдә төн чыкса, ул хатынны фәрештәләр иртәнгә кадәр ләгънәт кылыр».***

عن ابن عمر رضي الله عنهما قال: قال رسول الله صلى الله عليه و سلم: «اثنان لا تجاوز صلاتهما رءوسهما: عبد آبق من مواليه حتى يرجع وامرأة عصت زوجها حتى ترجع» [ المستدرك على الصحيحين للحاكم ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гомәрдән ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ике төрле кешенең намазы баш өсләреннән артык күтәрелми (ягъни кабул булмый): хуҗасыннан качкан кол хәтта кире кайтканчыга кадәр, һәм иренә мәгъсыять иткән (гөнаһ кылган, буйсынмаган) хатын хәтта тәүбә иткәнчегә кадәр (ягъни тәүбә итеп, ире аннан риза булганчыга кадәр)».***

قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ «مِنْ سَعَادَةِ ابْنِ آدَمَ ثَلَاثَةٌ وَمِنْ شِقْوَةِ ابْنِ آدَمَ ثَلَاثَةٌ مِنْ سَعَادَةِ ابْنِ آدَمَ الْمَرْأَةُ الصَّالِحَةُ وَالْمَسْكَنُ الصَّالِحُ وَالْمَرْكَبُ الصَّالِحُ وَمِنْ شِقْوَةِ ابْنِ آدَمَ الْمَرْأَةُ السُّوءُ وَالْمَسْكَنُ السُّوءُ وَالْمَرْكَبُ السُّوءُ» [ صحيح الترغيب والترهيب الألباني ]

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Адәм баласының бәхетле булуы өч нәрсәдә һәм бәхетсез булуы да өч нәрсәдә: бәхетле булуы — изге хатында, яхшы йортта һәм яхшы атта, адәм баласының бәхетсез булуы — начар хатында, начар йортта һәм начар атта».***

٥١٩٥ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رضي الله عنه أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ قَالَ: «لا يَحِلُّ لِلْمَرْأَةِ أَنْ تَصُومَ وَزَوْجُهَا شَاهِدٌ إِلا بِإِذْنِهِ وَلا تَأْذَنَ فِي بَيْتِهِ إِلا بِإِذْنِهِ وَمَا أَنْفَقَتْ مِنْ نَفَقَةٍ عَنْ غَيْرِ أَمْرِهِ فَإِنَّهُ يُؤَدَّى إِلَيْهِ شَطْرُهُ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан رضي الله عنه, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Иренең рөхсәтеннән башка хатын-кыз ураза (нәфел уразасы) тота алмый, шулай ук иренең рөхсәтеннән башка өйгә кеше кертми. Ә инде иренең рөхсәтеннән тыш изге гамәлгә (акча, байлык-мал кебек) бирәр нәрсә сарыф итсә, иренә моның өчен ярты әҗере була (ягъни хатынына тулы әҗер булса, иренә ярты әҗер була. Кайберәүләр хатынга да ярты әҗер-савап, иргә дә ярты әҗер-савап диде. Аллаһу әгъләм)».***

٥٢٣٢ - عَنْ عُقْبَةَ بْنِ عَامِرٍ رضي الله عنه أَنَّ رَسُولَ اللهِ ﷺ قَالَ: «إِيَّاكُمْ وَالدُّخُولَ عَلَى النِّسَاءِ» فَقَالَ رَجُلٌ مِنْ الأَنْصَارِ: يَا رَسُولَ اللهِ أَفَرَأَيْتَ الْحَمْوَ؟ قَالَ: «الْحَمْوُ الْمَوْتُ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Гукъбә бин Гамирдән رضي الله عنه, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Һичбер вакытта да чит хатын-кызлар янына кермәгез!».*** Шуннан соң ансарлардан бер кеше сорады: *«Йә Расүл Аллаһ! Ә ирнең туган кардәшләре (абый-энеләре, аларның малайлары кебек хатынга мәхрәм булмаган ирнең туганнары) хакында нәрсә әйтәсең?».* Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Алар үлем».*** (Ягъни үлемнән ничек саклансаң, алардан да шулай саклан. Чөнки чит кеше булса, син, әлбәттә, аны хатының янына кертмичә гөнаһлы эшләрдән ерагаюны эзлисең. Ә инде ирнең абый-энесе кебек аңа якын кешеләр гадәттә күп килеп йөриләр, һәм алар ягыннан хатын-кызга куркыныч күбрәк була, Аллаһ сакласын. Шуңа да хатын-кызга иренең абый-энеләре кебек туганнары белән аерым калу хәрам була).

# Кайбер әдәпләр хакында

٥٩٧٣ - عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ عَمْرٍو رَضِيَ اللهُ عَنْهُمَا قَالَ :قَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «إِنَّ مِنْ أَكْبَرِ الْكَبَائِرِ أَنْ يَلْعَنَ الرَّجُلُ وَالِدَيْهِ» قِيلَ: يَا رَسُولَ اللهِ وَكَيْفَ يَلْعَنُ الرَّجُلُ وَالِدَيْهِ؟ قَالَ: «يَسُبُّ الرَّجُلُ أَبَا الرَّجُلِ فَيَسُبُّ أَبَاهُ وَيَسُبُّ أُمَّهُ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Габдуллаh бин Гамрдан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хакыйкатьтә, ата-ананы ләгънәтләү иң зур гөнаhлардан!».*** Шуннан соң пәйгамбәребездән сорадылар: *«Йә Расүл Аллаh! Кеше ничек инде ата-анасын ләгънәтләсен?».* Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Берәү икенче кешенең әтисен сүксә, ул кеше дә беренченең әтисен сүгә. Шуннан соң беренчесе икенчесенең әнисен сүгә, ә икенчесе беренчесенекен».***

Бик зур кызганычка каршы, без яшәгән динсез җәмгыятьтә мондый үкенеч хәлләр күп очрый. Без инде кәферләр турында әйтмибез дә. Ләкин үзләрен мөселман дип санаган татарлар хакында борчылабыз. Безнең кабахәт җәмгыятьтә яшәвебезнең нәтиҗәсе булып, шул нәҗесләрнең кабахәт сыйфатларын үзебезгә алуыбыз бик тә йөрәкне сызлата, Аллаhу мүстәган! Йә Раббым! Әхлакъларыбызны күркәм кыл, hәм дә безне изге-салих балалар белән ризыкландыр! Хакыйкатьтә, Син догаларны ишетүче вә кабул итүче!

٦٢٠١ - حَدَّثَنَا أَبُو الْيَمَانِ أَخْبَرَنَا شُعَيْبٌ عَنْ الزُّهْرِيِّ قَالَ حَدَّثَنِي أَبُو سَلَمَةَ بْنُ عَبْدِ الرَّحْمَنِ أَنَّ عَائِشَةَ رَضِيَ اللهُ عَنْهَا زَوْجَ النَّبِيِّ ﷺ قَالَتْ: قَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «يَا عَائِشَ هَذَا جِبْرِيلُ يُقْرِئُكِ السَّلامَ» قُلْتُ: وَعَلَيْهِ السَّلامُ وَرَحْمَةُ اللهِ... [ البخاري ]

Мәгънәсе: Гаишәдән риваять ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Йә Гаиш! Җибрил сиңа сәлам әйтә»[14].*** Гаишә әйтте: *«(Вә галәйhис-сәлам вә рахмәтүллаh) Аңа да сәлам вә Аллаhның бәракәте булсын!».*

---

14 Пәйгамбәребез ﷺ Гаишәне йомшаклык белән "Гаиш" дип дәште

٥٢٠٤ - عَنْ أَسْمَاء بِنْت يَزِيد «مَرَّ عَلَيْنَا النَّبِىُّ ﷺ فِى نِسْوَةٍ فَسَلَّمَ عَلَيْنَا» ( سنن أبي داود، تحقيق الألباني: صحيح)

Мәгънәсе: Әсмә бинт Язид әйтте: ***«Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ безнең яннан узып киткәндә безгә сәлам бирде».***

Бу һәм башка хәдисләрдән билгеле булганча, әгәр дә фетнәдән иминлек булса, ир-ат хатын-кызга, хатын-кыз ир-атка сәлам бирә ала (монда сәлам бирү кул бирешмичә бәлки сүз белән икәнлекне аңлата). Шулай ук, Бохарида Үммү Һәнии хәдисе моны куәтләп һәм дә хатын-кызның тавышы гаурәт түгел икәнен бәян итә. Аллаһу әгъләм.

٧١٨٠ - عَنْ عَائِشَةَ رَضِيَ اللهُ عَنْهَا أَنَّ هِنْدًا قَالَتْ لِلنَّبِيِّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ: إِنَّ أَبَا سُفْيَانَ رَجُلٌ شَحِيحٌ فَأَحْتَاجُ أَنْ آخُذَ مِنْ مَالِهِ؟ قَالَ: «خُذِي مَا يَكْفِيكِ وَوَلَدَكِ بِالْمَعْرُوفِ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Гаишә риваять кылуынча: «Бервакыт Һинд (Әбү Суфиянның хатыны) пәйгамбәребездән ﷺ сорады: *«Хакыйкатьтә, Әбү Суфиян саран кеше, мин аңа әйтмичә аның малыннан алсам ярыймы?».* Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Үзеңә һәм балаларыңа җитәрлек тиешлесен генә ал!».***

Гыйлем әһелләре әйтүенчә, хатын-кыз мәхрамсыз, гыйлемле кешедән нинди дә булса мәсьәлә хакында сорый ала.

٢٩ - عَنْ ابْنِ عَبَّاسٍ قَالَ: قَالَ النَّبِيُّ ﷺ: «أُرِيتُ النَّارَ فَإِذَا أَكْثَرُ أَهْلِهَا النِّسَاءُ يَكْفُرْنَ» قِيلَ: أَيَكْفُرْنَ بِاللهِ؟ قَالَ: «يَكْفُرْنَ الْعَشِيرَ وَيَكْفُرْنَ الإِحْسَانَ لَوْ أَحْسَنْتَ إِلَى إِحْدَاهُنَّ الدَّهْرَ ثُمَّ رَأَتْ مِنْكَ شَيْئًا قَالَتْ مَا رَأَيْتُ مِنْكَ خَيْرًا قَطُّ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Ибен Габбастан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Миңа Җәһәннәм күрсәтелде һәм анда иң күбе көферлек кылган хатын-кызлар булды».*** Шуннан соң сорадылар: *«Алар Аллаһка көферлек кылганнармы?».* Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Алар ирләренә һәм аларга карата күрсәтелгән ихсанга рәхмәтле булмаганнар. Әгәр дә син ул хатыннарга гомер буе ихсанлы, яхшы булсаң да, һәм шуннан соң синдә бер генә булса да аңа ошамаган әйбер күрсә, ул сиңа: “Мин синнән гомер буе изгелек күрмәдем”, — дип әйтер».***

# ТАЛАК
# китабы

Талак иң авыр һәм иң җитди мәсьәләләрнең берсе, гади укучы тиз генә аңламаска мөмкин. Шуңа да сезнең тормышыгызда нинди генә очрак булмасын, иң әүвәле гыйлемле кешеләр, мәдрәсәләрдә яки башка Ислам уку йортларында укып кайткан шәкертләребез вә остаз-мөгаллимнәребез белән киңәшләшегез.

**Талакның шәргый мәгънәсе:**

Талак — ул, никах килешүен бетерү, яки ир белән хатынның аерылуы. Әгәр дә, ир белән хатын арасы бозылып, аларның бергә калулары бер-берсенә зарар вә зыян гына китерә торган булса, һәм аларның килешү мөмкинлеге булмаса, иң соңгы чара булып, шәригатебез талак кылуны һәм аларның аерылуларын рөхсәт итте.

Талак Иблискә иң сөйкемле гамәлләрнең берсе булып тора. Пәйгамбәребез ﷺ бу хакта үзенең хәдисендә болай диде:

٢١٦٧ - عَنْ جَابِرٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «إِنَّ إِبْلِيسَ يَضَعُ عَرْشَهُ عَلَى الْمَاءِ ثُمَّ يَبْعَثُ سَرَايَاهُ فَأَدْنَاهُمْ مِنْهُ مَنْزِلَةً أَعْظَمُهُمْ فِتْنَةً يَجِيءُ أَحَدُهُمْ فَيَقُولُ فَعَلْتُ كَذَا وَكَذَا فَيَقُولُ مَا صَنَعْتَ شَيْئًا قَالَ ثُمَّ يَجِيءُ أَحَدُهُمْ فَيَقُولُ مَا تَرَكْتُهُ حَتَّى فَرَّقْتُ بَيْنَهُ وَبَيْنَ امْرَأَتِهِ قَالَ فَيُدْنِيهِ مِنْهُ وَيَقُولُ نِعْمَ أَنْتَ» [ مسلم ]

Мәгънәсе: Җәбирдән رَضِيَ اللهُ عَنْهُ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Иблис гарешен диңгезгә куйгач (иблиснең мәркәзе — диңгез), үзенең төркемнәрен фәсәд таратыр өчен җирнең төрле ягына җибәрә. Иң зур фетнә ясаучы шәйтан аның иң якыны була. Шуларның берсе аның янына килә дә: “Мин шундый-шундый бозыклык ясадым”, — ди. Иблис аңа: “Син һичнәрсә дә эшләмәдең”, — дип аны инкяр итә. Шуннан соң икенче берсе килә һәм: “Мин ир белән хатын арасына фетнә салдым, вә аларның араларын аерганчыга кадәр фетнә салуны ташламадым”, — ди. Иблис аны үзенә якынрак ала һәм аңа: “Син иң яхшы эш эшләдең”, — ди».***

Шулай ук, кешеләр арасында бик тә киң таралган талак мәсьәләсенә кагылган кайбер зәгыйфь һәм дөрес булма-

ган хәдисләр дә очрый, шуларның бер-икесен искә алып үтәрбез, иншәАллаһ.

٢١٧٨ - عَن ابْنِ عُمَرَ ﷺ عَنِ النَّبِيِّ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «أَبْغَضُ الْحَلاَلِ إِلَى اللَّهِ تَعَالَى الطَّلاَقُ» [ سنن أبي داود، تحقيق الألباني : ضعيف ]

Мәгънәсе: Ибен Гомәрдән ﷺ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хәләл булган нәрсәләрдән Аллаһ тәгаләгә иң нәфрәтлесе (сөйкемле булмаганы), ул — талак».***

٧٣١ - «تزوجوا و لا تطلقوا، فإن الطلاق يهتز له العرش» [ قال الألباني في السلسلة الضعيفة و الموضوعة ( ٢ / ١٦١ ) موضوع ]

Мәгънәсе: ***«Өйләнегез һәм аерылмагыз! Хакыйкатьтә, талактан гареш дерелди».***

Күп кенә гыйлем әһелләре хаҗәтсез талак кылу мәкруһ дигән карашны хупладылар. Чөнки талак никах белән билгеләнгән файдаларны җимерә. Шул сәбәпле балаларның ата-ана иркәсеннән мәхрүм калулары дисеңме, мөселманнар арасында низаг вә фетнә чыгуы дисеңме һәм башкалар. Шулай ук, әйткәнебезчә, талак шәйтанны сөендерә, ә Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде, мәгънәсе:

**«Әй, Мөхәммәд ﷺ! Колларыма әйт, бер-берсе белән яхшы сүзләр илә сөйләшсеннәр! Хакыйкатьтә, шәйтан аларның арасына ихтиләф вә низагны сала. Әлбәттә, шәйтан кешеләргә ачык дошман булды».** («Әл-Исра» 53)

Һәм дә талакка караганда килешү вә бергә булу хәерлерәк дип болай әйтте, мәгънәсе:

**«Килешү, гафу итешү аерылышудан хәерле».** («ән-Ниса» 128)

Гыйлем әһелләре талак кайчан вәҗиб, мәндүб, мөбах, мәкруһ яки мүхәррам икәнлеген кыскача гына бәян итеп болай әйттеләр:

Талак кайбер вакытларда вәҗиб булырга мөмкин. Мәсәлән: Әгәр дә казый ир белән хатын арасын ачыкларга дип ике якның да туганнарыннан ике кешене билгеләгәннән соң алар икесе дә ир белән хатынның ае-

рылулары хәерле дигәнгә килешсәләр, бу вакыта талак вәҗиб була.

Талак кайбер вакытларда мәндүб булырга мөмкин. Мәсәлән: Әгәр дә хатын-кызның динендә кимчелек булса, яки изге хатын булмаса, бу очракта талак кылу хәерлерәк. Бу очракларда кайбер гыйлем әһелләре талак вәҗиб диделәр. Бигрәк тә әгәр хатын-кыз шәригатебездә намаз кебек фарыз яки вәҗиб булган гамәлләрне кылмый торган булса. Ә инде ирендә шәригатебезгә муафыйкъ булмаган кабахәт сыйфатлар булса, ул вакытта хатын-кыз хульга таләп итә ала (моны алга таба аңлатып узарбыз, иншәАллаһ).

Талак кайбер вакытларда мөбах булырга мөмкин. Мәсәлән: Хатын-кыз начар холыклы, яки иренә карата начар мөгамәләдә булып, ире аннан зыян күрә торган булса, бу очракта талак рөхсәт ителә.

Талакның мәкруһ булуы мөмкин. Мәсәлән: Әгәр дә бер сәбәпсез талак кылса.

Талакның мөхәррам булуы мөмкин. Мәсәлән: Хайд (айлык күрем) вакытында, яки хатын-кыз пакь вакытта ире аның белән йоклаган булса, талак кылу ярамый. Бу вакыттагы талак «талак әл-бидга» дип атала. Күрем вакытында талак кылырга ярамаганлыгын бәян итеп ошбу хәдис килә:

٥٢٥١ - عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ عُمَرَ أَنَّهُ طَلَّقَ امْرَأَتَهُ وَهِيَ حَائِضٌ عَلَى عَهْدِ رَسُولِ اللهِ ﷺ فَسَأَلَ عُمَرُ بْنُ الْخَطَّابِ رَسُولَ اللهِ ﷺ عَنْ ذَلِك فَقَال رَسُولُ اللهِ ﷺ: «مُرْهُ فَلْيُرَاجِعْهَا ثُمَّ لِيُمْسِكْهَا حَتَّى تَطْهُرَ ثُمَّ تَحِيضَ ثُمَّ تَطْهُرَ ثُمَّ إِنْ شَاءَ أَمْسَكَ بَعْدُ وَإِنْ شَاءَ طَلَّقَ قَبْلَ أَنْ يَمَسَّ فَتِلْكَ الْعِدَّةُ الَّتِي أَمَرَ اللهُ أَنْ تُطَلَّقَ لَهَا النِّسَاءُ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Ибен Гомәрдән رضي الله عنه риваять ителә: Пәйгамбәребез ﷺ вакытында ибен Гомәр хатынының айлык күреме булган килеш аны талак кылды. Шуннан соң (әтисе) Гомәр бин әл-Хәттаб расүлебездән ﷺ бу хакта сорагач, пәйгамбәребез ﷺ болай дип әйтте: ***«Әйт аңа, хатынын кире кайтарсын һәм бу күремнән пакьләнгәннән соң икен-***

***че айлык күреме килеп аннан да пакьләнгәч теләсә үзендә калдырсын, ә теләсә аның белән йоклаганчыга кадәр талак кылсын. Аллаһ тәгалә талак кылырга кушкан хатыннарның гыйддәсе (билгеле вакыты) шушыдыр».***

Хәдистән аңлашылганча, ибен Гомәр ﵁ хатынын хайд вакытында талак кылгач, пәйгамбәребез ﷺ аны кире кайтарырга кушты. Талак вакытындагы күреме узып пакьләнгәч, икенче айлык күреме килеп, аннан да пакьләнгәч, теләсә ул хатынны үзендә калдыра, яки инде аның белән йоклаганчы аера. Ләкин ошбу вакыт эчендә ул хатыны белән йокламаска (якынлык кылмаска) тиеш.

Шулай ук, икенче риваятьтән билгеле булганча, хайд вакытында бирелгән талак бер талакка санала.

Ире хатынын хайд (айлык күрем) вакытында талак кылса, ул аны кире кайтарып алырга тиеш дидек. Инде күремнән пакьләнгәч талак кыласы килсә, аның икенче күреме җитеп аннан да пакьләнгәнен көтәргә тиешме, әллә шул талак биргән күремнән пакьләнгәч та талак бирә аламы дигән мәсьәләдә гыйлем әһелләре төрле карашларга бүленделәр. Бохарида килгән 5258нче хәдистә пәйгамбәребез ﷺ ибен Гомәргә талак биргән хайд (айлык күрем каны) узып пакьләнгәч теләсәң, аера аласың диде. Шушы риваятьләргә карап гыйлем әһелләре дә төрле карашка килде. Бу мәсьәләдә без Мустафа әл-Гадавийнең карашын алабыз. Ул инде ике хәдис белән дә гамәл итү йөзеннән, икенче хайдтан (күремнән) пакьләнүне көтү мөстәхәб диде. Бу шулай ук Әбү Хәнифә һәм Әхмәд бин Хәнбәлнең карашы.

**§ Талак әс-сүннәһ (сөннәт буенча кылынган талак):** Коръән һәм сөннәткә муафикъ булган талак «талак әс-сүннәһ», — дип атала.

Мисалы: Хатын-кыз күремнән соң пакь булган вакытта ире аның белән якынлык кылмыйча талак кылса, сөннәт буенча кылынган талак була. Шулай ук, хатын-кызның балага узганлыгы билгеле булгач кылынган талак

сөннәт буенча дип әйтелде. Кайберәүләр талак кылганда ике шәһиднең булуы тиешле дип өстәделәр. Бер талактан соң гыйддә вакытында ир хатынын кире кайтарып аласы килсә, яңа мәһер дә, хатынның да, вәлинең дә ризалыгы кирәк түгел. Кайтарып алганнан соң шушы ук тәртиптә тагын ике талак кылса (барысы өч талак була), ире хатынын кире кайтарып ала алмый, иллә-мәгәр ул хатын икенче иргә кияүгә чыгып, ул ир аны аерып гыйддә вакыты узганнан соң гына беренче ир яңадан аңа никахлана ала (яңа никах белән).

**§ Талак әл-бидга (бидгать талак):** Коръән һәм сөннәткә туры килмәгән талак «талак әл-бидга», — дип атала.

Мисалы: Әгәр дә хатын-кыз хайд (айлык күрем каны килгән) вакытында ире аны талак кылса, бидгать талак була.

Икенче мисал: Хатыны күремнән пакь вакытында ире аның белән якынлык кылган булса, һәм шул пакь вакытта аны талак кылса, шулай ук бидгать талак була. Алда әйткәнебезчә бу төрле талак хәрам, ләкин талактан санала.

## Әгәр дә әтисе улына хатынын (ягъни киленен) талак кылырга кушса?

Әгәр дә изге-салих булган ата-ана яхшылыкны эстәп улларыннан киленнәрен (диндә кимчелеге яки начар холыклы булганга) талак кылырга кушсалар, бу вакытта уллары аларга буйсынып, хатынын талак кылырга тиеш. Әлбәттә, изге ата-ана начарлыкка вә бозыклыкка өндәми. Ә инде фәсикъ булган ата-ана, яки бер сәбәпсез киленнәрен яратмаган өчен генә талак итүне сорасалар, бу вакытта талак кылырга тиеш түгел, ә бәлки аларга күркәм холык белән аңлатырга тырышырга тиеш.

٥١٣٨ - عَنْ حَمْزَةَ بْنِ عَبْدِ اللَّهِ بْنِ عُمَرَ عَنْ أَبِيهِ قَالَ: كَانَتْ تَحْتِى امْرَأَةٌ وَكُنْتُ أُحِبُّهَا وَكَانَ عُمَرُ يَكْرَهُهَا فَقَالَ لِى: «طَلِّقْهَا» فَأَبَيْتُ فَأَتَى عُمَرُ النَّبِىَّ صلى الله عليه وسلم فَذَكَرَ ذَلِكَ لَهُ فَقَالَ النَّبِىُّ ﷺ: «طَلِّقْهَا» [ سنن أبي داود، صحيح ]

Мәгънәсе: Ибен Гомәр ﵄ әйтте: *«Минем хатыным бар иде, һәм мин аны бик ярата идем. Ләкин Гомәр (әтисе) аны күрә алмый иде (бәлки ул хатынның динендә кимчелеге булганга) һәм миңа: «Талак кыл аны», — диде, мин кире кактым. Шуннан соң Гомәр пәйгамбәребез ﷺ янына барып моны хәбәр итте. Расүлебез ﷺ әйтте:* ***«Талак кыл!».***

## Исерекнең яки ачулы хәлдә яки уйнап кына бирелгән кешенең талагы дөресме?

**§ Исерекнең талак бирүендә гыйлем әһелләренең ике карашы бар:**

**1)** Исерек кешенең талак бирүе кабул ителә (дөрес була). Бу караш Галидән, ибен Габбас, Мугавия, Сәгыйд бин әл-Мүсәйб, Гата, Мүҗәһид, әл-Хәсән, ибен Сирин, әш-Шәгъбий, Ибраһим ән-Нәхәгый, әз-Зүһрий, Мәймүн бин Миһран, әл-Хәкәм бин Гутәйбә, Әбү Хәнифә, Әбү Юсуф һәм Мөхәммәд, Мәлик, әс-Сәүрий, әл-Әүзәгый, Шәфигый бер риваятендә (дөресрәге), Әхмәд бин Хәнбәл бер риваятендә, ибен Шүбрумә, Сөләймән бин Хәрбләрдән риваять ителде.

**2)** Исерек кешенең талак бирүе кабул ителми (дөрес булмый). Бу караш Госманнан, Гомәр бин Габдулгазиз, әл-Касим бин Мөхәммәд, Тауус, Рабийга, Яхъя әл-Әнсарий, әл-Ләйс, әл-Ганбәрий, Исхак, Әбү Сәүр, әл-Мүзәний, хәнәфиләрдән Тахауий, әл-Кәрхий, Әхмәд бин Хәнбәл (бер риваятендә) һәм шулай ук ибен Тәймияләрдән риваять ителде.

**Кыскача:** Әгәр дә кеше бик нык исереп гакылы китсә һәм нәрсә сөйләгәнен белмәсә, ул вакытта талагы дөрес булмый. Ә инде нәрсә сөйләгәнен белеп талак кылса, ул вакытта дөрес була. Аллаһу әгъләм.

**§ Ачулы хәлендә талак биргән кешене ибен Тәймия өчкә бүлде:**

**1)** Әгәр дә бик нык ачулы кешенең гакылы китеп, нәрсә эшләгәнен белмәс дәрәҗәдә булса, талак дөрес булмый.

**2)** Әгәр ачуы гади дәрәҗәдә булып сөйләгән сүзләрен аңлый торган булса (шулай ук хатынына ачуланып, аны куркытырга яки акылга утыртырга теләсә) бу вакытта талак дөрес була.

**3)** Әгәр дә бик нык ачуланып гакылы үзендә булса, ләкин үзен кулда тота алмаса, бу вакытта гыйлем әһелләренең иҗтиһәденнән тора. Аллаһу әгъләм.

**§ Уйнап кына бирелгән талакта гыйлем әһелләре шулай ук ике карашка бүленделәр:**

**1)** Мәлики һәм Хәнбәлиләрдә уйнап яки шаярып әйтелгән талак саналмый.

**2)** Хәнәфи һәм Шәфигыйларда уйнап яки шаярып әйтелгән талак санала, һәм алар ошбу хәдисне китерделәр:

٢١٩٥ - عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ ﵁ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ قَالَ: «ثَلاَثٌ جِدُّهُنَّ جِدٌّ وَهَزْلُهُنَّ جِدٌّ النِّكَاحُ وَالطَّلاَقُ وَالرَّجْعَةُ» [ سنن أبي داود، تحقيق الألباني: حسن ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Өч нәрсә җитди әйтелсә дә, уйнап яки шаярып әйтелсә дә дөрес була: никах, талак һәм раҗга (талак кылганнан соң кире кайтарып алу)».***

Бу хәдиснең дөреслегендә гыйлем әһелләре арасында төрле карашлар бар. Берәүләр дөрес дисә, икенчеләр бу хәдиснең иснәдендә килгән Габдуррахман бин Хәбиб сәбәпле хәдис зәгыйфь диделәр. Ән-Нәсәи аның хәдисе мәтрүк, яки кабул ителми диде. Ибен Хиббән үзенең “әс-Сикат” китабында аны искә алып хәдисләре кабул ителә

дигәнне аңлатты, шулай ук, әл-Хәким. Ибен Хиббән белән әл-Хәкимне риваять кылучыларны йомшаклык белән хөкем итәләр дисәләр, ән-Нәсәи каты хөкем итү белән билгеле булды. Шәйх әл-Әлбәний бу хәдисне “Сахих сүнән Әбий Дауыд”та хәсән дисә дә, “Ирүә әл-Галил”дә тәнкыйтьләп узды. (“Тәһзиб әл-Кәмәл”, “Лисән әл-Мизән”, “Тәкрыйб әт-Тәһзиб” һ.м. башка хәдис гыйлемендәге китапларны кара).

Мулла Галий әл-Карий “Миркату-л-мафатийх”та, бу хәдиснең шәрехендә болай дип әйтеп узды: *«Әгәр дә никахласа, яки талак кылса, яки хатынын кире кайтарса һәм шуннан соң: «Мин уйнап яки шаярып кына әйттем», — дисә, бу аңа бер файда да бирмәс... (ягъни аның әйткән сүзләре кабул ителеп, шул хөкем булыр)».*

Әгәр дә ир-ат хатынына: «Син талак иншәАллаһ», — дип «иншәАллаһ» сүзен өстәсә, бу мәсьәләдә гыйлем әһелләре шулай ук ике караштa булдылар. **1)** Мәлик һәм Әхмәдтә талак санала. **2)** Әбү Хәнифә һәм Шәфигыйда талак саналмый. Шәйх ибен Тәймиядән бу хакта соралгач, ул болай дип җавап бирде: *«Бу очракта талак саналмый...».* (Мәҗмугъ әл-Фәтәвә 33/238). Аллаһу әгъләм.

## Хульга

**Хульганың шәргый мәгънәсе:**

Әгәр хатын-кыз иренә акча, мал яки башка нәрсә биреп, үзен аеруны сорый икән, һәм ир дә шуңа риза буып, аны аера икән, **бу хульга дип атала**.

Мәсәлән: Талакта без әйттек, ир-ат бер-бер төрле сәбәп буенча хатынын талак кылып аера. Ә монда хатын-кыз ирнең нинди дә булса дин ягыннанмы, яки начар холыклы булу, яки аны яратмау сәбәплеме (һ.б.) иренә акча-мал (яки мәһерне кире кайтарып, яки мәһер хакыннан арттырып) биреп никах килешүен бозуны һәм аны азат итеп аерып җибәрүне сорый.

﴿فَإِنْ خِفْتُمْ أَلا يُقِيمَا حُدُودَ اللَّهِ فَلا جُنَاحَ عَلَيْهِمَا فِيمَا افْتَدَتْ بِهِ﴾ البقرة: ٢٢٩

Мәгънәсе: **«Әгәр икесе дә Аллаһ чигендә каим булудан (шәригатьне саклаудан) курыксагыз, мәсәлән: ир хатынын яратыр, әмма хатын ирен яратмас, ир хатынны талак кылырга теләмәс, хатын торырга теләмәс, яки ир хатынын хаксыз җәберләп тотар, шундый хәлдә хатын ирдән алган мәһерне яки башка малын биреп, үзен аерып җибәрүне сорар...».**

٥٢٧٦ - عَنْ ابْنِ عَبَّاسٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُمَا قَالَ: جَاءَتْ امْرَأَةُ ثَابِتِ بْنِ قَيْسِ بْنِ شَمَّاسٍ إِلَى النَّبِيِّ ﷺ فَقَالَتْ: يَا رَسُولَ اللهِ مَا أَنْقِمُ عَلَى ثَابِتٍ فِي دِينٍ وَلا خُلُقٍ إِلا أَنِّي أَخَافُ الْكُفْرَ، فَقَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «فَتَرُدِّينَ عَلَيْهِ حَدِيقَتَهُ؟» فَقَالَتْ: نَعَمْ، فَرَدَّتْ عَلَيْهِ وَأَمَرَهُ فَفَارَقَهَا [ البخاري ]

Мәгънәсе: Ибен Габбас ﷺ әйтте: *«Пәйгамбәребез ﷺ янына Сәбит бин Кайс бин Шәммәснең хатыны килде һәм әйтте: «Йә Расүл Аллаһ! Мин Сәбитнең дине (динендә кимчелеге булганы) өчен дә, холкы (начар холыклы булганы) өчен дә аның белән аерылышасым килми, ләкин мин көферлектән куркам (ягъни, аның белән яшәсәм, көферлеккә илтә торган гамәлдән куркам)». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Сиңа (мәһергә) биргән бакчасын аңа кире кайтарып бирәсеңме?».*** *Ул хатын әйтте: «Әйе», һәм бакчасын иренә кире кайтарып бирде. Пәйгамбәребез ﷺ Сәбиткә хатынын аерырга кушкач, ул аны аерып җибәрде».*

Хульга хатын-кызны иреннән азат итә һәм барча хакы аның үз кулында була. Ире аны бер яки ике талактан соң кайтарып ала алган кебек кире кайтарып ала алмый. Чөнки, бер яки ике талактан соң гыйддә вакыты узганчы, ире мәсәлән: «Мин хатынны кире кайтардым», — дисә, хатыны иренә кайтырга мәҗбүр, һәм аның бер ихтияры да юк. Ә хульга хатынны ихтиярлы итә, һәм ир аны кире кайтару белән мәҗбүр кыла алмый, иллә-мәгәр ул хатын риза булса, яңа никах килешүе белән генә кайтара ала.

## Хульга никах килешүен гамәлдән туктатып юкка чыгарумы (фәсех), әллә талакмы?

Бу мәсьәләдә гыйлем әһелләре берничә карашка бүленделәр.

**1)** Күпчелек галимнәр Әбү Хәнифә, Мәлик, Шәфигый (яңасында) һәм Әхмәд бер риваятендә, ирнең хатыны икенчегә кияүгә чыгып, аннан да аерылмыйча торып беренче ире кире кайтарып ала алмый торган талак (ягъни өч талак хөкемендә) диделәр.

**2)** Ибен Габбас, Тауус. Гыйкримәһ, Шәфигый (кадимдә), Әхмәдтән билгеле булган мәшһүр риваять һәм ибен Тәймияләр фәсех, ягъни никах килешүен гамәлдән туктатып юкка чыгару диделәр.

**3)** Имам Шәфигыйның бер риваятендә талак та, фәсех тә түгел диде.

Бу мәсьәләдәге фикер каршылыгының җимеше булып менә нәрсә тора.

Кемнәр хульга өч талак хөкеме диде, алар хатын-кыз хульгадан соң талак кылынган хатын-кызга тиешле гыйддә вакыты (өч күрем каны вакыты яки кемнәрдер өч күрем канынннан соң килгән өч пакь вакыт диде) узып һәм икенче иргә кияүгә чыгып, ул ирдән аерылганнан соң шулай ук гыйддә вакыты узгач кына беренче иренә яңа никах белән кире кияүгә чыга ала диделәр.

Ә кемнәр хульга фәсех ягъни никах килешүен гамәлдән туктатып юкка чыгару диде, алар ул хатын-кызның гыйддәсе бер күрем каны узганчы диделәр. Шулай ук, беренче иренә кире кайтасы килсә, икенче иргә кияүгә чыгып аерылырга кирәк түгел, бәлки яңа никах белән кире кайта диделәр. Яки талак кылынган хатын-кызга тиешле булган өч күрем гыйддә вакыты да, икенче иргә кияүгә

чыгып аерылу да кирәк түгел. Бу карашны без дөресрәк вә көчлерәк дип табабыз, чөнки Әбү Дауыдта (2229, 2230) ән-Нәсәидә (3487-88) әт-Тирмизидә (1185) ибен Мәҗәһдә (2058)нче саннар белән килгән сахих риваятьләрдә хульга кылынган хатын-кыз бер күрем вакыты узуын көтәргә тиеш икәнлеге ачык бәян ителә.

**Нәрсә ул гыйддә?**

Гыйддә — ул, хатын-кызның ире үлгәннән соң, яки аерылганнан соң икенче иргә кияүгә чыкканчыга кадәр шәригать белән билгеләнгән вакытны көтеп тору. Ире үлгәннән соң дүрт ай ун көн, авырлы булса бала тапканчыга кадәр көтә. Талак кылынганнан соң авырлы булса — бала тапканчыга кадәр, авырлы булмаса — өч куруу (куруу — өч күрем каны вакыты яки аннан соң килгән өч пакьлек вакыты), ә инде күрем күрми торган булса (зур яшьтәге кебек) — өч ай вакыт узганын көтеп тора.

## Хатын-кыз сәбәпсез талак яки хульга кылуны сорау хакында

٣٤٦١- عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ عَنِ النَّبِىِّ صلى الله عليه وسلم أَنَّهُ قَالَ: «الْمُنْتَزِعَاتُ وَالْمُخْتَلِعَاتُ هُنَّ الْمُنَافِقَاتُ» [ سنن النسائي، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«(Ирләреннән сәбәпсез) хульга (һәм талак) сораучы хатын-кызлар — монафикълар».***

٢٢٢٦ - عَنْ ثَوْبَانَ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم «أَيُّمَا امْرَأَةٍ سَأَلَتْ زَوْجَهَا طَلاَقًا فِى غَيْرِ مَا بَأْسٍ فَحَرَامٌ عَلَيْهَا رَائِحَةُ الْجَنَّةِ» [ سنن أبي داود، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Сәүбән бин Бүҗдәд (Җәхдәр)дән ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә хатын-кыз сәбәпсез иреннән талак сорый икән, ул хатынга Җәннәт исе хәрам булыр».***

## Әгәр ир хатынына караганда, яки хатын иренә караганда берсе алданрак Исламны кабул итсә?

Әгәр ир дә һәм хатын да Исламны бергә кабул итсәләр, алар элекке өйләнү килешүе белән калалар. Ягъни, Исламны кабул иткәч, аларга яңадан никах яңартырга кирәкми. Чөнки, пәйгамбәребез ﷺ вакытында Исламны кабул иткән сахәбәләрдән, никахны яңарту билгеле түгел.

Ә инде әгәр хатын Исламны кабул итеп, ире кабул итмәсә, бу вакытта аларның арасы аерыла, чөнки Аллаһ тәгалә Коръәндә бу хакта болай диде:

(فَإِنْ عَلِمْتُمُوهُنَّ مُؤْمِنَاتٍ فَلا تَرْجِعُوهُنَّ إِلَى الْكُفَّارِ لا
هُنَّ حِلٌّ لَهُمْ وَلا هُمْ يَحِلُّونَ لَهُنَّ) الممتحنة: ١٠

Мәгънәсе: **«Әгәр ул хатыннарны хак мөэминнәр дип тапсагыз, аларны мөшрикләргә кайтарып бирмәгез, чөнки алар мөшрик булган ирләренә хәләл түгелләр һәм ул мөшрикләр Ислам динен кабул иткән хатыннарына хәләл түгелләр».**

Шуннан соң, Ислам кабул иткән хатын кәфер иреннән аерылгач, гыйддә вакыты көтәргә тиешме һәм күпме дигәнгә күпчелек гыйлем әһелләре өч күрем вакыты көтә диделәр. Шушы гыйддә вакыты узганчы әгәр дә кәфер булган ире Исламны кабул итә икән, бу вакытта ул ирнең хакы аны кайтарып алырга әүвәлрәк, һәм аларга яңа никах кирәк түгел. Ә инде әгәр гыйддә вакыты узганчы Исламны кабул итмәсә, бу вакытта ул хатын гыйддә вакыты узгач та кияүгә чыга ала, яки тели икән беренче иренең Ислам кабул иткәнен көтә. Әбү Хәнифә хәзрәтләре буенча андый хатынга бер күрем вакыты һәм шуннан соң килгән пакьлек вакыты узуын көтсә җитә. Алар моны Бохарида 5287нче сан белән ибен Габбастан килгән әсәр белән дәлилләделәр. Аллаһу әгъләм.

# Ире югалган хатын-кыз хакында

Бу хакта пәйгамбәребездән ﷺ килгән сахих хәдис юктыр.

عَنِ الْمُغِيرَةِ بْنِ شُعْبَةَ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ: «امْرَأَةُ الْمَفْقُودِ امْرَأَتُهُ حَتَّى يَأْتِيَهَا الْخَبَرُ» [ سنن الدار قطني ٣/٣١٢ ضعيف ]

Мәгънәсе: Әл-Мугыйра бин Шүгъбәдән, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ире югалган хатын-кыз ачык вә дөрес хәбәр булганчыга кадәр шул иренеке санала».*** (Зәгыйфь хәдис)

Шулай булса да бу, хакта сахәбәләрдән кайбер сахих әсәрләр билгеле:

١٢٣١٧ - عن ابن المسيب أن عمر وعثمان قضيا في المفقود أن امرأته تتربص أربع سنين، وأربعة أشهر وعشر بعد ذلك، ثم تزوج، فإن جاء زوجها الاول، خير بين الصداق وبين امرأته. [ مصنف عبد الرزاق، صحيح ]

Мәгънәсе: Сәгыйд бин әл-Мүсәйбтән риваять ителә: *«Гомәр һәм Госман ире югалган хатын-кыз хакында болай хөкем иттеләр:* ***«Дүрт ел көтә, шуннан соң дүрт ай һәм ун көн гыйддә вакытын уздыра, аннары кияүгә чыга ала. Әгәр дә икенче иргә кияүгә чыкканнан соң беренче ире кайтса, тели икән хатынын кайтарып ала, тели икән хатынын икенче ире белән калдырып, мәһерен кире ала».***

عن سعيد بن المسيب أن عمر بن الخطاب رضي الله عنه قال: «أيما امرأة فقدت زوجها فلم تدري أين هو، فإنها تنتظر أربع سنين، ثم تعتد أربعة أشهر و عشرا ثم تحل» [ الموطأ ١٢٤٩ تحقيق الشيخ خليل شيخا ]

Мәгънәсе: Сәгыйд бин әл-Мүсәйбтән риваять ителә, Гомәр әйтте: ***«Әгәр дә хатын-кыз ирен югалта һәм аның кайда икәнен белми икән, дүрт ел көтә, дүрт елдан соң да билгеле булмаса дүрт ай һәм ун көн гыйддә вакытын көтә, шуннан соң ул хатын теләсә, кияүгә чыга ала».***

Ире үлгән хатын-кызның гыйддә вакыты дүрт ай ун көн, шуңа да дүрт елдан соң хәбәр булмаса, ире үлгән саналып, дүрт ай ун көн гыйддә вакытын көтә.

عن علي قال : «تتربص حتى تعلم أحي هو أو ميت» [ مصنف عبد الرزاق ]

Мәгънәсе: Гали әйтте: ***«Иренең тере яки үлгән икәнлеге билгеле булганчы көтә».***

Шулай ук, бу хакта башка әсәрләр билгеле, без аларның барсына да тукталып тормыйбыз.

**– Әгәр ир-ат хатынын талак кылса һәм шуннан соң ул хатын икенче иргә кияүгә чыгып, ул да аны талак кылса, беренче ир бу хатынга яңадан өйләнсә, аның бу хатынга алдан биргән талаклары саналамы?**

**1)** Әгәр дә ир хатынын өч талак белән аерып җибәргән икән, һәм аннан соң ул хатын икенче иргә кияүгә чыгып, ул да (икенче ир) аны талак кылганнан соң бу хатын беренче иренә яңадан кияүгә чыкса, беренче ирнең өстендә яңадан өч талак була. Ягъни, алдан биргән өч талагы юкка чыгып, яңа өйләнгән кешегә хас булган өч талак аңа да хас була. Бу хәлдә гыйлем әһелләренең бердәм карашы билгеле булды. Аллаһу әгъләм.

**2)** Әгәр дә ир хатынын бер яки ике талак белән аерып җибәрсә, һәм гыйддә вакыты узып, ул хатын икенче иргә кияүгә чыкканнан соң ул ире дә аны талак кылса, бу хатын беренче иренә кире кайтса, ул ир аңа биргән талаклар шул килеш каламы әллә юкка чыгып, яңа өйләнгән кешеләр кебек яңадан тагын өч талак буламы дигән мәсьәләдә гыйлем әһелләре каршылыклы фикерләргә килделәр:

**А)** Әгәр ир алдан бер генә талак биргән икән, бу очракта беренче ирнең тагын ике талагы гына кала, ике талак биргән икән бер генә талагы кала, һәм моннан соң ул хатын аңа хәрам була. Бу Гомәр һәм Шәфигыйларның карашы.

**Б)** Әгәр дә хатын беренче иргә кире кайта икән, ул ирнең өстендә яңадан өч талак була. Чөнки икенчегә кияүгә чыгып беренче ирнең алдан биргән талаклары юкка чыга. Бу Габдуллаһ бин Габбас, ибен Гомәр, Әбү Хәнифә һәм Әбү Юсуфларның карашы.

## Кием һәм зиннәт хакында

(قُلْ مَنْ حَرَّمَ زِينَةَ اللَّهِ الَّتِي أَخْرَجَ لِعِبَادِهِ وَالطَّيِّبَاتِ مِنَ الرِّزْقِ قُلْ هِيَ لِلَّذِينَ آمَنُوا فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا خَالِصَةً يَوْمَ الْقِيَامَةِ كَذَلِكَ نُفَصِّلُ الْآيَاتِ لِقَوْمٍ يَعْلَمُونَ ۞ قُلْ إِنَّمَا حَرَّمَ رَبِّيَ الْفَوَاحِشَ مَا ظَهَرَ مِنْهَا وَمَا بَطَنَ وَالْإِثْمَ وَالْبَغْيَ بِغَيْرِ الْحَقِّ وَأَنْ تُشْرِكُوا بِاللَّهِ مَا لَمْ يُنَزِّلْ بِهِ سُلْطَانًا وَأَنْ تَقُولُوا عَلَى اللهِ مَا لَا تَعْلَمُونَ) الأعراف: ٣٢-٣٣

Мәгънәсе: **«Әйт: «Аллаһ тәгалә бәндәләренә биргән зиннәтле киемнәрне һәм ризыктан пакь, ләззәтле булганнарын кем хәрам кылды?» Әйт: «Ул зиннәтле киемнәр вә хуш булган ризыклар дөньяда вакытта иман китергән мөэминнәргә (шулай ук дөньяда вакытта кәферләр дә файдалана), ә Кыямәт көнендә мөэминнәргә генә». Әнә шулай аятьләребезне ачык аңлатабыз хакны белгән кешеләр өчен. Әйт: «Раббым ачык эшли торган фәхеш эшләрне дә, яшерен эшли торганын да хәрам кылды. Янә гөнаһлы эшләрне, хаксыз золым итүне хәрам кылды. Аллаһка ширек кылуны, һәм Аның хакында белмәгәнне сөйләүне хәрам кылды».**

٤١٧٠ - عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ قَالَ: «لُعِنَتِ الْوَاصِلَةُ وَالْمُسْتَوْصِلَةُ وَالنَّامِصَةُ وَالْمُتَنَمِّصَةُ وَالْوَاشِمَةُ وَالْمُسْتَوْشِمَةُ مِنْ غَيْرِ دَاءٍ» [ سنن أبي داود، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Ибен Габбас ﵁ әйтте: ***«Чәч ялгаучы вә ялгатучы (парик), каш йолкучы вә йолкытучы һәм тәнгә чәнчеп язучы яки рәсем ясатучы (татуировка) ләгънәт кылындылар, әгәр дә бер төрле чирдән дәвалану өчен булмаса».***

Бу хакта Бохарида (4886, 5931-5948), Мөслимдә (2125) һәм башка хәдисләр килде.

٣٥٩٥ - عَنْ عَلِي بن أَبِى طَالِب، قال: أَخَذَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى الله عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ حَرِيرًا بِشِمَالِهِ وَذَهَبًا بِيَمِينِهِ ثُمَّ رَفَعَ بِهِمَا يَدَيْهِ فَقَالَ: «إِنَّ هَذَيْنِ حَرَامٌ عَلَى ذُكُورِ أُمَّتِى حِلٌّ لِإِنَاثِهِمْ» [ سنن ابن ماجه، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Ибен Габбас ﷺ әйтте: *«Пәйгамбәребез ﷺ уң кулына ефәк алды, ә сул кулына алтын алды һәм әйтте:* ***«Бу ике нәрсә минем өммәтемнең ир-атларына хәрам кылынды, хатын-кызларга хәләл булды».***

٥٨٨٥- عَنْ ابْنِ عَبَّاسٍ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمَا قَالَ: «لَعَنَ رَسُولُ اللهِ ﷺ الْمُتَشَبِّهِينَ مِنْ الرِّجَالِ بِالنِّسَاءِ وَالْمُتَشَبِّهَاتِ مِنْ النِّسَاءِ بِالرِّجَالِ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Ибен Габбас ﷺ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ хатын-кызларга охшарга теләгән ирләрне һәм ир-атларга охшарга теләгән хатын-кызларны ләгънәт кылды».***

Шәригатебездә билгеле булганча, ир-ат хатын кызга, ә хатын-кыз ир-атка киемдә дә, бизәнү зиннәтләрендә дә, йөрешендә дә, тавышында да һәм башка барча ирләрнең яки хатыннарның үзләренә генә хас булган кыланышларда да бер-берсенә охшарга тырышырга тиеш түгелләр, ягъни хәрам.

**§ Хатын-кыз киеменең шартлары:**

Шәйх әл-Әлбәний үзенең «Җилбәб әл-Марәа әл-Мөслимә» китабында хатын-кыз киеменә тиешле булган сигез шартны искә алып узды:

**1)** Кайбер чыгармадан чыгарылган урыннардан башка (кул һәм бит кебек) бөтен тәнне дә капларга тиеш.

**2)** Ул кием күзләрне җәлеп итә торган зиннәт кииеме булырга тиеш түгел.

**3)** Кием калын булырга тиеш. Юка булып үтә-күренә торган булырга тиеш түгел.

**4)** Кием иркен вә киң булырга тиеш. Тар һәм кысык булып хатын-кызның тәнен тасвирларга тиеш түгел.

**5)** Кием хушбуйлар белән хушландырылган булырга тиеш түгел.

**6)** Хатын-кызның кииеме ир-атлар киеменә охшарга тиеш түгел.

**7)** Мөселман хатын-кызының киеме кәфер хатын-кызларыныкына охшарга тиеш түгел.

**8)** Шөһрәт киеме булырга тиеш түгел.

Бу шартларның кайберсе ирләр киеменә дә кагыла. Ә азаккы өч шарт хатын-кызның өйдә кия торган киеменә дә һәм өйдән тыш кия торган киеменә дә кагыла.

# Йомгаклау

Әлхәмдүлилләһ, Аллаһның теләге һәм ярдәме илә хәерле вә изге гамәлләр тәмамлана. Пәйгамбәребезгә ﷺ вә аның әһле бәйтенә, сахәбәләренә һәм аңа Кыяматкә кадәр ияргән барча мөэминнәргә салават вә сәламнәребез булсын!

Аллаһ Раббыбыз барча кимчелек вә хаталарыбызны ярлыкап, тәүбәләребезне кабул итсен! Һәммәбезне дә файдалы гыйлем, тәкъва, ихласлык вә саф йөрәклелек илә зиннәтләсен!

Хөрмәтле укучылар! Шушында без китабыбызны тәмамлыйбыз. Бу китаптагы мәсьәләләргә карата кемнәрнең дә булса башка фикерләре бар икән, аларны безгә язма рәвештә җиткерсәгез, без бик тә шатланып кабул итәрбез.

Вә ахыргы сүзебез: ***«Барча мактау галәмнәрнең Раббысы Аллаһка!».***

# Кулланылган кайбер китаплар


1. Коръән
2. Җәмигъ әл-бәян фи тәфсир әл-Куръән — (әт-Табарий)
3. Тәфсир әл-Куръән әл-Газыйм — (ибен Кәсир)
4. Җәмигъ ли әхкәм әл-Куръән — (әл-Куртубий)
5. Мәгалим әт-Тәнзил — (әл-Бәгауий)
6. Фәтх әл-Кадийр — (әш-Шәүкәний)
7. Зәд әл-Мәсир — (ибен әл-Җәүзий)
8. Әйсәр әт-Тәфәсийр — (әл-Җәзәирий)
9. Тәйсир әл-Кәриймм әр-Рахмән фи тәфсир кәләм әл-Мәннән — (әс-Сәгъдий)
10. Әхкәм әл- Куръән — (әл-Җәссас)
11. Сахих әл-Бохари
12. Фәтх әл-Бәрий — (ибен Хәҗәр)
13. Гумдә-түл-Карий — (әл-Гайний)
14. Фәйд-ул-Бәрий — (Мөхәммәд Әнүәр әл-Кәшмирий)
15. Сахих Мүслим
16. Әл-Минһәҗ — (ән-Нәвәвий)
17. Сүнән Әбий Давыд
18. Гаун-үл-Мәгъбүд — (Шәмсулхак әл-Газыйм Әбәдий)
19. Бәзл-үл-Мәҗһүд — (Хәлил әс-Сәһәранфурий)
20. Сүнән әл-Тирмизий
21. Түхфә-түл-Әхуәзәй — (әл-Мүбәракфурий)
22. Сүнән ән-Нәсәий
23. Зәхира-түл-Гукъбә фи шәрех әл-Мүҗтәбә — (Мөхәммәд бин Гали бин Адәм)
24. Сүнән ибен Мәҗәһ
25. Хәшия әс-Синдий галә сүнән ибен Мәҗәһ
26. Әл-Муатта — (имам Мәлик)

27. әт-Тәмһид — (ибен Габд-ул-Бир)
28. Мишкә-түл-Мәсабийх — (әт-Тибризий)
29. Силсилә әл-Әхәдис әс-Сахиха — (әл-Әлбәний)
30. Силсилә әл-Әхәдис әд-Дагыйфә — (әл-Әлбәний)
31. Шәрех Мәганий әл-Әсәр — (әт-Тахауий)
32. Әл-Мусаннаф — (ибен Әбий Шәйбәһ)
33. Әл-Мусаннаф — (Габ-ур-Раззак)
34. Әл-Мүснәд — (Әхмәд бин Хәнбәл)
35. Сүнән әл-Дәр Кутний
36. Мүстәдрак галә әл-Сахихайн — (әл-Хәким)
37. Ирүә әл-Галил — (әл-Әлбәний)
38. Тәһзиб әл-Кәмәл — (әл-Миззий)
39. Тәкрыйб әт-Тәһзиб — (ибен Хәҗәр)
40. Сияр әгъләм ән-Нүбәлә — (әз-Зәһәбий)
41. Лисән әл-Мизән — (ибен Хәҗәр)
42. Мәүсугъа гулүм әл-хәдис үә фүнүниһи — (Сәйид әл-Гаурий)
43. Сүбүл әс-Сәлам — (әс-Санганий)
44. Әл-Мәбсут — (әс-Сәрхасий)
45. Бәдәигъ әс-Санаигъ — (әл-Кәсәний)
46. Фәтх-үл-Кадийр — (ибен әл-Һүмәм)
47. Радд-үл-Мүхтәр — (ибен Габидәйн)
48. Мухтәсар әл-Кудурий — (Әбү әл-Хүсәйн Әхмәд әл-Кудурий)
49. Әл-Мәдхәл илә мәзһәб әл-имам Әбий Хәнифә ән-Нүгъмән — (Әхмәд Сәгъыйд әл-Хәүүә)
50. Әл-Мәҗмугъ — (ән-Нәвәвий)
51. Әл-Мугъний — (ибен Кудәмә)
52. Фикһ әс-Сүннәһ — (Сәйид Сәбикъ)
53. Җәмигъ Әхкәм ән-Нисәә — (Мустафа әл-Гадавий)

54. Рахмә-түл-Үммәһ фи-хтиләф әл-әиммәһ — (Әбү Габдулла Мөхәммәд бин Габдуррахман)

55. Җилбәб-үл-Мәрәа-түл-Мүслимә — (әл-Әлбәний)

56. Әхкәм әл-Зиүәҗ — (әл-Әшкар)

57. Нидә әл-Райян — (Сәйид әл-Гаффәний)

58. Фәтәүә әл-Мәрәа әл-Мүслимә — (Мөхәммәд бин Ибраһим Әли әш-Шәйх, Габдуррахман әл-Сәгъдий, Габдулла бин Мөхәммәд бин Хүмәйд, ибен Бәәз, ибен Гусаймийн, Салих бин Фәүзән, Габдулла бин Җибрийн)

59. Фәтәүә әл-Һиндия — (Низамуддин әл-Бурһәнбурий һәм башкалар)

60. Мәҗмугъ Фәтәүә ибен Тәймия

61. Әхкәм әһл-үз-Зиммәһ — (ибен Кайим әл-Җәүзия)

62. Әт-Тәгърифәт — (әл-Җүрҗәний)

63. Әл-Камүс әл-Мүхыйт — (әл-Фәйрузәбәдий)

64. Лисән әл-Гарәб — (ибен Мәнзур)

65. Ән-Ниһәяһ фи гарийб әл-хәдис үәл-әсәр — (ибен әл-Әсийр) һ.б.

## Эчтәлек

Кереш сүз....................................................................3

**ГОМУМИ МӘСЬӘЛӘЛӘР..........................................7**

Хатын-кызларга карата яхшы мөгамәлә..........................8

Ир яки кыз бала тууы хакында.......................................14

Хатын-кызларны сөннәт-ләү (хитән яки хафд).............17

**ТАҺӘРАТ КИТАБЫ.................................................19**

Хатын-кыз кулы белән җенес әгъзасына тиеп китсә таһәрате бозыламы?......................................................20

Хатын-кызның бизәнүе..................................................22

Күкрәк сөте имә торган кыз бала сидегенә кагылышлы м әсьәлә.............................................................................23

Хатын-кызның киеменә күкрәк сөте тисә?.........24

Мәзи.............................................................................24

Хатын-кызларның җенес әгъзасыннан чыккан сыекча-лар...............................................................................25

Хатын-кыз мәниенең сыйфаты (төсе) һәм төшләнсә госел коену тиешлеге хакында.......................................25

Ир һәм хатынның бергә госел коенуы..........................26

Хатын-кыз ире белән якынлык кылганнан соң госел коенгач, бераз вакыттан соң аннан иренең мәние чыкса, нишләргә тиеш?...........................................................27

Әгәр ире хатынын якынлык кылырга чакырса, ә хатыны госел коенырга иренеп, яки су юк дип, аны инкяр итсә, дөрес буламы?..............................................................28

Госел коенганда хатын-кыз чәч толымын сүтәргә тиешме?.....................................................................29

Хатын-кыз хайд вакытыннан соң госел коенганда хуш-буй куллануы хакында..................................................30

Күремнән соң госел коенуның кыскача тәртибе..........31
Хатын-кызның җенес әгъзасыннан чыга торган канның т өрләре.....................................................................................31
Хайд (күрем) мәсьәләсе................................................31
Хайд, Аллаһның Адәм кызларына язган тәкъдире.......32
Ошбу аять белән бәйле кайбер мәсьәләләр...................34
Аятьнең иңү (төшү) сәбәбе...........................................34
Бу аятьтә «Әйт: Ул (күрем каны) иза чиктерә», — дигәннең мәгънәсе.......................................................................35
Хайд хәлендә булган хатын-кыз белән якынлык кылуның хәрамлыгы...................................................................36
Хайд вакытында рөхсәт ителгән нәрсәләр хакында.......37
Әгәр мөселман китап әһеленә (яһүд яки насарага) өйләнсә, ул хатыны белән якынлык кылыр өчен, аны госел коенырга мәҗбүр итәргә тиешме?...............................................40
Әгәр хатын-кыз хайд башланыр алдыннан сары яки болганчык сыекчаны күрсә, нишләргә тиеш?........................42
Хатын-кыз ифада тавафын кылган булса, һәм соңыннан хайд башланса, аңа саубуллашу тавафы кирәк түгел.........43
Хайд вакытында хатын-кыз намаз укыймы һәм ураза тотамы?..........................................................................43
Әгәр дә ире хатынын күрем вакытында (җенес әгъзасына) якынлык кылырга чакырса?............................................45
Коръән китабын тотмыйча яки яттан, хайд яки җөнеб вакытында хатын-кызга Коръән укырга ярыймы?.............46
Хайд хәлендә хатын-кызга яки таһәратсез булган кешегә Коръән тотса ярыймы?.................................................47
Йөкле (балага узган) хатын-кызның күреме буламы?...49
Истихада мәсьәләсе.......................................................50
Истихада булган хатын-кызның мәчеттә игътикәф кылуы?................................................................................53
Нифәс мәсьәләсе...........................................................53

**НАМАЗ КИТАБЫ.................................................55**

Пәйгамбәребез ﷺ вакытында мәчеттә хатын-кызларның җәмәгать намазында булуы хакында..................................56

Хатын-кызларга мәчеткә барырга рөхсәт итү хакында..56

Хатын-кыз мәчеткә барганда хушбуй кулланмавы хакында.......................................................................................57

Пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисен кабул итмәгән кешегә нәфрәт белдерү хакында..................................................58

Хатын-кызның мәчеттә нәфел намазы укуы, һәм шулай ук гыйбадәттә үз-үзен азапламавы хакында.......................59

Хатын-кызның өйдә намаз укуы хакында......................60

Хатын-кызлар үзләре генә намаз укыганда араларыннан берсе имам булуы хакында..................................................60

Намаз укыганда баланы кулга алу хакында....................63

Ир һәм хатын бер-берсен төнге намазга уятулары хакында.......................................................................................63

Җомга намазы хатын-кызларга фарызмы?.....................64

Хатын-кыз намаз укучы ир-ат алдыннан узып китсә, намаз укучының намазы бозыламы?......................................65

Хатын-кыз узып китсә намаз бозыла диючеләрнең кайбер дәлилләре.................................................................65

Хатын-кыз узып китсә намаз бозылмый диючеләрнең кайбер дәлилләре............................................................66

Кияүгә чыккан хатын-кыз әти-әнисенең өенә кунакка сәфәр кылса, намазын кыскартамы?..................................67

**ҖЕНАЗА БҮЛЕГЕ.............................................................68**

Кайгы килгәндә сабыр булу хакында..............................68

Кемнең дә булса бик нык яраткан кешесе үлеп, ул ошбу авырлыкны ныклы иман вә Аллаһтан әҗер өмет итеп сабырлык күрсәтү хакында............................................69

Мәетләр өчен кычкырмыйча елауның рөхсәт ителүе хакында....................................................................................70

Хатын-кыз үлгәч, аны госел коендыру хакында............72

Хатын-кызларга җеназа артыннан ияргә ярыймы?....74

Мөселманның китап әһеленнән булган хатыны балага узган килеш үлсә, кайда күмелә?..............................75

Хатын-кызларга каберләрне зиярат кылырга ярыймы?.77

Хатын-кызларга каберләргә зиярат кылуны тыючыларның кайбер дәлилләре........................................77

Хатын-кызларга каберләргә зиярат кылуны рөхсәт итүчеләрнең кайбер дәлилләре........................................78

**УРАЗА КИТАБЫ..........................................................81**

Рамазан кичләрендә иргә хатыны белән йокларга рөхсәт ителүе хакында..........................................................82

Бу аятьнең төшү сәбәбе...................................................82

Ураза хәлендә ир-атка хатынын кочакларга вә үбәргә рөхсәт ителүе хакында...................................................83

Хатын-кыз ураза хәлендә ашарга пешергәндә ризыкның тәмен белер өчен кабып караса, шулай ук балага ризыкны чәйнәп бирсә ярыймы?.................................................87

Рамазанда хатын-кыз ураза хәлендә килеш ире белән якынлык кылса, йолым (кәффәра) тиешме?......................88

Нәрсә ул йолым яки кәффәра?.........................................89

Авырлы һәм күкрәктән бала имезүче хатын-кыз Рамазанда уразасын тотмыйча калдыра аламы?..............................90

Хатын-кыз нәфел уразасына иреннән рөхсәт сорау хакында....................................................................................92

Уразада гаиләнең хакы барлыгы турында......................92

Ураза хәлендә һәм башка вакытларда да гайбәтләрдән саклану хакында..............................................................93

**ИГЪТИКӘФ БҮЛЕГЕ..................................................95**

Рамазанның соңгы ун көнендә ир кеше үзенең гаиләсен төнге гыйбадәткә уяту хакында..........................................95

Шәригатебездә хатын-кызларга игътикәфнең рөхсәт ителүе хакында..................................................................95

Хатын-кызның игътикәф кылырга иреннән рөхсәт сора-вы хакында..................................................................96

Хайд хәлендә булган хатын-кыз мәчеттә игътикәф кыла-мы?...........................................................................98

Хайд хәлендә булган хатын-кызның игътикәф кылуы дөрес яки дөрес түгеллеге ике мәсьәләгә бәйле................98

Хайд хәлендә булган хатын-кызның игътикәф кылуы дөрес диючеләрнең дәлилләре...........................................101

**ХАҖ һәм ГУМРА.................................................103**

Хаҗның ирләргә дә, хатын-кызларга да фарызлыгы ха-кында.............................................................................104

Хатын-кызларның иң хәерле җиһәде — хаҗ................104

Хатын-кыз хаҗга барыр өчен иреннән рөхсәт сорарга ти-ешме?.............................................................................105

Хатын-кызның мәхрәмсез яки ирсез сәфәргә чыгарга ярамаганлыгы хакында кайбер хәдисләр.........................107

Хаҗга ихрамланган хатын-кызга никаб яки бияләй кебек нәрсәләр кияргә ярыймы?..............................................108

Хаҗда хайд һәм нифәс хәлендә булган хатын-кызлар ха-кында.............................................................................109

Әгәр дә хатын-кыз тәмәттугъ хаҗын ниятләп ихрамга кергәннән соң таваф әл-ифада кылганчы күреме башланып, Гарәфә көне җитеп хаҗны калдырудан курыкса, нишләргә тиеш?.............................................................................110

Таваф кылыр өчен таһәратле (вудулы) булу шарт булып торамы?..........................................................................110

Таһәрат шарт диючеләрнең кайбер дәлилләре.............111

Таваф кылырга таһәратле булу сөннәт диючеләрнең кайбер дәлилләре....................................................112
Хатын-кыз тавафта рамл, һәм сәгыйдә ике яшел билге арасында кызу атлап йөгерергә тиешме?..........................113
Хатын-кыз чәчен кыскарту хакында..............................114

**НИКАХ КИТАБЫ.....................................................115**

Никахлану һәм изге-салих балалар сорау хакында......118
Коръән аятьләре..........................................................118
Хәдисләр....................................................................120
Сахәбәләрдән кайбер әсәрләр........................................122
Мүхәррамәт яки өйләнергә тыелган хатын-кызлар......123
Беркайчан да һәм бервакытта да өйләнергә ярамаган хатын-кызлар үзләре өч төрлегә бүленәләр.......................123
Вакытлыча өйләнергә ярамаган хатын-кызлар...........126
Өйләнгәндә гыйффәтле кызларны сайлау хәерлерәк...130
Никахка килешенгән кызга икенче егетнең тәкъдим ясавы хакында..........................................................131
Әгәр егет кызга тәкъдим ясаса, ләкин кыз ризалыгын да, кире кагуын да әйтмәсә яки уйлыйм әле дисә, бу вакытта аңа икенче егет тәкъдим ясый аламы?............................132
Икенче яки өченче яки дүртенче хатын булып кияүгә чыгучы хатын-кыз көндәшен талак итүне сорый алмый.....133
Мәһер һәм аның хөкеме..............................................134
Мәһернең күләме.......................................................134
Кем ул никахтагы вәли?..............................................136
Дүрт мәзһәб буенча никахтагы вәлинең тәртибе.........141
Кәфер илендә яшәгән һәм вәлие булмаган хатын-кыз ничек кияүгә чыга?....................................................142
Никахта шәһидләр мәсьәләсе.......................................143
Никахка бәйле кайбер хәдисләр...................................145
Кайбер әдәпләр хакында.............................................148

**ТАЛАК КИТАБЫ........................................................151**

Талакның шәргый мәгънәсе..................................................152

Әгәр дә әтисе улына хатынын (ягъни киленен) талак кылырга кушса?..........................................................................156

Исерекнең яки ачулы хәлдә яки уйнап кына бирелгән кешенең талагы дөресме?..................................................157

Хульга..................................................................................159

Хульга никах килешүен гамәлдән туктатып юкка чыгарумы (фәсех), әллә талакмы?.............................................161

Хатын-кыз сәбәпсез талак яки хульга кылуны сорау хакында..................................................................................162

Әгәр ир хатынына караганда, яки хатын иренә караганда берсе алданрак Исламны кабул итсә?..............................163

Ире югалган хатын-кыз хакында......................................164

Әгәр ир-ат хатынын талак кылса һәм шуннан соң ул хатын икенче иргә кияүгә чыгып, ул да аны талак кылса, беренче ир бу хатынга яңадан өйләнсә, аның бу хатынга алдан биргән талаклары саналамы?...........................................165

**Кием һәм зиннәт хакында...............................................166**

Хатын-кыз киеменең шартлары.......................................167

**Йомгаклау.........................................................................169**

**Кулланылган кайбер китаплар........................................170**